Кызганычка, бүгенге көндә милләт хатын-кызларының яртысы катнаш никахларда, ә Татарстаннан читтә, Урал аръягында бу сан 80-90 процент тәшкил итә. Бу татар хатын-кызлары үзләре дә ана телләрен белми, Ислам динен тотмый, урыстан туган балалары исә үзләренең татар икәнлекләрен дә яшерәләр. Болар милләт өчен юк инде. Татар бугазыннан Урал тауларына кадәр булган борынгы татар җирләрендә инде өченче буын татарлар үзара русча аралаша, руслар белән никахлаша, нәселе шул милләткә күчә.

Үз-үзебезне алдамыйк – анда татар милләте юк инде, аерым татарлар гына бар. Милләт шунда бар – кайда аның милли китаплары языла һәм укыла, кайда аның тарихы саклана, кайда аның милли белгечләре әзерләнә, читтә болар инде юк дәрәҗәсендә. Ни кызганыч, шушы ук фаҗига Идел-Урал татарларына да яный, чөнки халыкта милли аң шактый түбән, татарлыкның кадерен белү юк, Ислам милләт тормышына үтеп керә алмады. Татар милләте инкыйраз юлына чыкты, ашыгыч чаралар күрелмәсә, аны юкка чыгу көтә.

Әлбәттә, монда гел халыкның үзен, бигрәк тә хатын-кызларны гына гаепләү дә дөрес булмас иде, милләтнең юкка чыга баруында тышкы, объектив сәбәпләр дә бар. Үз дәүләтең булмау, биш гасырга якын чит тел, чит дин, чит халык басымы һәм тәэсире астында яшәү, дәүләтнең гасырлар буе урыслаштыру һәм христианлаштыру сәясәтен алып баруы милләтебезнең нигезләрен какшатты, рухын сындырды, өметсезлеккә төшерде. Әмма дәүләт алырлык һәм дәүләт тотарлык ир-атларны да хатын-кыз тәрбияли бит, димәк, татар хатын-кызлары үз балаларына, үз нәселләренә милли рух, Ислам тәрбиясе бирә алмаганнар, дигән сүз!

Татар хатын-кызларына, аларның оешмаларына урыннарда бөтен көчне милли рух тәрбияләүгә һәм Ислам әхлагын торгызуга бирергә кирәк. Боларны гаиләләр аша эшлисезме, мәктәпләр яки аерым милли һәм дини оешмалар аша тормышка ашырасызмы – һәркем мөмкинлегеннән чыгып эш итсен. Ахыргы нәтиҗә – сез милли рухлы, иманлы татар кешесе тәрбияләргә тиешсез. Бу һәр татар хатын-кызына кагыла. Нәрсә генә эшләсәгез дә, башта ике сорауга җавап бирегез – бу гамәлегез Аллаһка каршы килмиме һәм милләткә зыянга түгелме? Хәзерге татар оешмаларының бөтен эше диярлек җыр-биюгә һәм җыелып күңел ачуга кайтып кала. Бу иң җиңел юл, әмма очсызлы алым, акыллы милләтләр сәясәттә дә ат уйната, фәндә дә әйдәп бара, диндә дә нык тора. Татар милләтенә дә, аның милли оешмаларына да башка югарылыкка күтәрелер вакыт җитте инде.

Урыннарда чын татар тарихы язылмаган, бу сезнең дә эш, татар хатын-кызлары! Яшьләрдә бөек татар тарихы аша милли рух тәрбияләгез, алардан зур галимнәр, милли язучылар әзерләгез! Үзегез дә урыннардагы архивларда эшләргә өйрәнегез, аларда әле ачылмаган татар тарихы ята! Урыннарда татар тарихы түгәрәкләре, клублар оештырып җибәрегез, газета-журналлар ачыгыз, үзегез дә языгыз, башкаларны да шуңа дәртләндерегез! Урыннарда милли музейлар оештырыгыз, дәүләт музейларында татар бүлекләре ачтыруга ирешегез, әмма аларда гармун белән галош тормасын, ә татарның бөеклеген һәм матурлыгын күрсәтә торган экспонатлар булсын!

Бала күңеленә иман орлыклары салу – татар хатын-кызларының изге бурычы, милләтебезнең Ислам дине сәбәпле исән калуын онытмыйк! Динне тарату, дәгъвәт – ул дин әһелләренең генә эше түгел, ә һәрберебезнең өстендә торган фарыз. Бүген укытучыларның һәм табибларның 70-80 проценты – хатын-кызлар. Мәктәптә укытучы үзенең укучыларына дөньяның яратылышы Аллаһ эше икәнлеген әйтергә тиеш, табиб үзенең авыруларына кешенең

яратылышы Аллаһ эше икәнлеген аңлатырга тиеш, ана үзенең баласына Аллаһтан килеп, Аллаһка китәсебезне төшендерергә тиеш. Аллаһны таныган кеше милләтен дә таный, милләтен таныган кеше башкаларның да хәлен аңлый. Милләтебез, телебез, гомеребез – Аллаһтан амәнәт, һәм без бу амәнәтне заман ахырына кадәр кадерләп сакларга тиешбез!

Мөслимәләр оешмалары да үзләренең эш алымнарын үзгәртергә тиешләр. Бу бигрәк тә Татарстанга кагыла, чөнки Ислам дине иң зәгыйфь урын да – Татарстан. Биредә авылы-авылы, урамы-урамы белән намаз укымыйлар, җомгаларда мәчетләрдә нибары 4-5 бабай... Аллаһ ничек бу динсез татар авылларын сакласын?! Мөслимәләребезгә дә төркем-төркем булып татар авылларына таралырга, халыкны дингә өндәргә вакыт җитте. Югыйсә, бу оешмалар бассейннарда йөзү, кием модалары күрсәтү белән артык мавыгып киттеләр, ә аларның төп эше – Ислам дәгъвәты, халыкны дингә өндәү булырга тиеш бит!

Урыннарда хатын-кыз оешмаларына социаль мәсьәләләргә дә игътибар бирә башларга вакыт. Югыйсә, читтә картлар йортлары ялгыз татар бабайлары белән тулган, ятимнәр йортларында да татар балалары күп, төрмәләрдә, больницаларда караучысыз татарлар шактый. Ярый да Татарстанда социаль ярдәм структуралары бар, алар эшләп тора, читтә безнең татарлар ул игътибарны күрми бит! Мин ялгыз калган татарларга ярдәм итү мисалын Сахалинда күреп-белеп кайттым. Анда төрмәдә берәр татар үлсә дә, хастаханәгә беркеме булмаган ялгыз татар килеп эләксә дә, татар оешмасы җитәкчесе Зәкия Вәлитовага шалтыраталар, «Тут ваш татарин умирает», дип хәбәр итәләр. Зәкия ханым үзенең әбиләре белән ул больницаларга, картлар йортларына, төрмәләргә, ятимнәр йортларына барып, бәхетсезлеккә дучар булган ул татарларга булыша, үлсәләр, аларны мөселманча юып, Сахалиндагы бердәнбер татар зиратына алып барып күмәләр. Шушы изге үрнәктә, Татарстаннан читтә булган башка хатын-кызлар оешмалары да ятим татарларга ярдәм итсеннәр иде.

Инде татар хатын-кызларына сәясәттә катнашыргамы-юкмы, дигән сорауга да җавап биреп үтим. Русия һәм БДБ илләре кебек демократия булмаган илләрдә сайлауларда катнашудан мәгънә юк, чөнки монда халыкны һәм хаклыкны түгел, хакимиятне яклаган кешеләр генә депутатлыкка үтә ала. Ә менә Европада, Балтыйк буе илләрендә яшәүче татар хатын-кызларына мин сайлауларда катнашырга, парламентларга үтеп керергә тәкъдим итәр идем. Европарламентта да безнең үз татарларыбыз булырга тиеш, алар мондагы хәлләр-проблемалар турында дөнья дәрәҗәсендә сүз алып барырга тиешләр. Шулай ук Европадагы татар хатын-кызлары хокук яклаучылар рәтләрендә дә булырга тиеш, милләт хокукларын дөнья дәрәҗәсендә алар якларга тиеш.

Бүген дөньяда һәр милләт үзе исән калу өчен тырыша, үз теле һәм дине өчен көрәшә, күпчелек сугышлар да дәүләтләр арасында түгел, милләтләр арасында бара. Нәтиҗәдә, көчле рухлылар һәм нык иманлылар җиңә. Татар халкына бу тормыш мәйданында урын каралганмы – үзебездән дә, бигрәк тә хатын-кызлардан да күп нәрсә тора. Безгә бу болганчык елларда аякта калырга, булганын саклап калырга кирәк. Үзебез татарча сөйләшсәк, татарча яшәсәк, милләтнең кадерен белсәк, безне беркем туктата алмаячак! Үзебез иманлы булсак, дин тотсак, балаларыбызга да Ислам нигезләрен биреп калдырсак, безне беркем тыя алмаячак! Үзебез дәүләтле булырга теләсәк, милли дәүләтебезне торгызу өчен көрәшсәк, безне беркем җиңә алмаячак! Бу дөньяда көрәшкән милләт кенә исән кала, көрәшкән милләт кенә җиңә. Татар милләте шул җиңүчеләр рәтендә булсын иде, татар хатын-кызлары дәүләт алырлык милләт тәрбияләсен иде!

ПИСЬМО В НОМЕР

# ДЕТИ ДОЛЖНЫ ИМЕТЬ ВОЗМОЖНОСТЬ ИЗУЧАТЬ РОДНОЙ ЯЗЫК

## Уважаемая редакция журнала “Самар татарлары”!

Прошу вас обратить внимание на одну из острых проблем нашей современности, а именно на отсутствие получения этнокомпонентного образования детьми, чей родной язык в данной местности не имеет статус государственного.

Каждый родитель мечтает, чтобы сын или дочь выросли достойными своих предков. Прежде всего ребенок должен владеть родным языком, так как неповторимость и самобытность каждого народа проявляется в его языке, и он важный составляющий духовного наследия, передаваемого ребенку как необходимый фактор жизнеобеспечения данного этноса.

Человечек рождается в определенной среде, группе, относящейся к той или иной народности. У человека всегда присутствует «зов крови», может «двойной» зов, если ребенок родился от смешанного брака. По существующему закону, у нас в стране человек обязан по полной программе изучить государственный язык. А как быть неруссским народам с негосударственным родным языком в данной местности? Допустим, в той же Москве? Или в Тюмени? Проблема есть, для родителей очень важная. Но попробуйте подойти к школе с предложением учить детей желающих петь на том или ином нерусском языке? Сразу найдут много причин для отказа. Самая ходовая из них –

"наций здесь много, и мы статистику не ведем". Школа кивает в сторону социальных культурных заведений, где могут научить рисованию, пению, языку, истории и многому другому. Но... к сожалению, такие заведения проблему не решат, так как их работа базируется на энтузиазме отдельных лиц. И таких по стране не так много... А люди, которые по службе обязаны решать данные проблемы, часто кивают в сторону родителей, мол, это их забота – научить ребенка разговаривать на родном языке, учить родную историю, песнопение и т.д. К сожалению, данный подход также неустойчив, так как родители заняты работой, с детьми мало общаются. В современной жизни связь поколений прервано, не принято жить с дедушками и с бабушками вместе. Кроме того, сегодняшнее поколение слишком прагматично относится к подобным мероприятиям. Первый аргумент – "а понадобится ли мне он – язык предков"? Дети, или их родители, выбирают, кроме школьных уроков, занятия спортом, рисование, музыку, хореографию. Детям зачастую "некогда" учить родной язык, если даже родители готовы оказать посильную помощь, хотя последние чаще всего по ряду причин сами лишены элементарных знаний о родном языке и о родном народе. Считаю, что в сфере образования Российской Федерации имеется огромный пробел, недосмотр данной проблемы: нерусским детям в лучшем случае самим с помошью родителей или репетиторов остается изучить родной язык, в худшем же, и она реальность – идет тихая ассимиляция народов. Возникает вопрос: почему государство не заботится о получении ребенком образования по этнокомпонентам? Тем самым дети поставлены в неравные условия развития: детям с "государственным" родным языком в данной местности везет, они тщательно изучают данный язык, историю, т.е. получают полный набор образования с этнокомпонентами. А другие дети, понятное дело, чувствуют себя ущемленными, второсортными. Закладывается тем самым реальная основа для напряженности: человек всю жизнь чувствует себя второсортным, ущемленным в правах: ему нечего передать своим детям, разве что чужую культуру.

Считаю, что пора исправить данную ситуацию. По Конституции РФ каждый ребенок имеет право учить родной язык, историю, культуру. Разве не логично, что это право должно обеспечить государство? Мне кажется, изучение ребенком родных "этнокомпонентов" – это серьезный шаг к воспитанию гармоничного человека, а это в свою очередь залог избавления (оздоровления) человеческого общества в стране от таких явлений как ксенофобия, шовинизм и т.д., поэтому государство должно обеспечить вышеназванное право ребенка. Многие могут возразить: детей мол, много, около двухсот национальностей в стране. Это хорошо, что много, главное, никого не обделить. Значит, надо создать структуры, занимающиеся данной проблемой в городе, области, не говоря о районах , то есть должны быть охвачены все школы. Это тоже забота о гражданах страны. Где бы ребенок не учился, должен работать механизм, обеспечивающий ему доступ в получении образования с "этнокомпонентом". Надо поручить разработать методику для образовательной деятельности по этнокомпонентам. Уверена, в наш век сотовых телефонов и интернета проблема легко разрешима и, возможно, методов достаточно много. Например, известно, что, с одной стороны, существует дистанционное обучение предметам, языку, песням (их можно послушать и выучить), с другой стороны, современные школьники оснащены компьютерами, значит, подключить ребенка к получению этнокомпонентного образования не является задачей невозможной. Надо создать базу данных таких программ для существующих языков в Российской Федерации и обеспечить доступ и обучение. Не думаю, что данная задача требует огромных финансовых затрат. Верю, дети, получив данное образование, будут как минимум знакомиться с родным языком, осилят самый простой барьер по общению на родном языке, ознакомятся с историей родного народа, литературой, культурой обычаями, национальными героями.

При приеме детей пора школ обязать поставить перед ребенком задачу: обязательное изучение родного языка (или языков) со всеми национальными компонентами (родная литература, история, народные песни, ознакомление с национальными традициями) с последующей сдачей экзаменов. Для этого, как вариант, данной школе необходимо и достаточно было бы дать заявки в роно местного муниципального образования, а последние должны "выдать" полный набор – методов, по которым ребенок смог бы получить этнокомпонентное образование, в том числе, может быть, с привлечением национально-культурных автономии.

Финансирование должно идти за счет государства. И это справедливо. Наши дети не лучше и не хуже детей, ежедневно изучающих родной язык, литературу, историю своего народа в полном объеме! Ведь дети – будущее нашей страны. Забота о духовном развитии ребенка есть вклад в гармоничное развитие ребенка и в конечном итоге общества в целом. Надеюсь, данное письмо, дополненное многочисленными фактами о необходимости поддержки данной идеи, подкрепленное материалами об обоснованности и подписанное многими представителями народов Российской Федерации, дойдет до депутатов Госдумы, которые учредят – таки закон, восстанавливающий конституционное право ребенка на гарантированное изучение родного языка, закладывающий фундамент на сохранение национальной идентичности представителя каждого народа в РФ.

Есть мнение, что изучение родного языка можно было бы организовать через факультативы при школах. Ведение факультатива зависит от энтузиазма отдельных людей, тем самым получение образования по национальным компонентам для каждого нерусского ребенка стопроцентно не гарантируется.

Фирдаус ГАЛЕЕВА,
Москва

# Роберт МИННУЛИН. В ПОЭЗИИ — ПОЛИТИК, В ПОЛИТИКЕ — ПОЭТ



***На вечер поэзии, который самарское татарское общество «Туган тел» проводило во второй раз, согласился приехать известный татарский поэт, политик, депутат Государственного Совета Республики Татарстан Роберт Миннулин. Это известие с быстротой сарафанного радио облетело всю татарскую общественность, и народ стал собираться в Доме Дружбы народов для того, чтобы встретиться с поэтом, взять автограф, послушать стихи, а главное, узнать о результатах поездки делегации Государственного Совета Татарстана в Крым. Ведь он буквально только что вернулся оттуда, где был в составе делегации Татарстана.***

*Эльмира ШАВАЛИЕВА*

Народ, конечно, волновался – как все пройдет, каков этот человек в общении, как оценит общественную жизнь татар Самарской области... И вот в зал заседаний входит известный поэт. Улыбаясь с порога и мимоходом оглядывая нарядно одетых женщин, как бы про себя произносит: «Если бы знал, что здесь будет столько красивых женщин, надел бы костюмчик получше». Обстановка сразу разряжается, слышатся смешки и возгласы: «Вы нам и в этом костюме очень нравитесь!» Поэт, довольный тем, что и в Самаре его любят и знают, садится во главу стола…

– Спасибо за приглашение на праздник поэзии, - такими словами начал свое выступление Роберт эфенди. – У нас, татар, есть своя страна, история и политика. Но татары живут не только Татарстане, но и в России. Поэтому и ее мы считаем своей страной, а себя здесь ощущаем равными среди равных. В этой стране у нас есть свое место и мы знаем этому цену.

Татары никогда не считали себя низшей расой. Если мы будем думать, что нас мало, язык наш пропадает, нация растворяется и скоро нас не станет совсем, то, возможно, это так и будет. Но ведь наши предки, даже когда не имели своей государственности, никуда не пропали, дожили довольно благополучно до сегодняшнего дня. И это говорит о том, что мы сильная нация и у нас есть свое лицо и свое будущее.

Пока существует Республика Татарстан, татары есть и будут существовать. Возможно, через века, что-то и изменится. Татары будут говорить на русском или на английском языках, но нация не пропадет, будет еще очень долго проявлять себя так или иначе. Это главное, о чем я хотел вам сказать сегодня.

Я уверен, что вы хотите знать о нашей миссии в Крыму – возведении мостов между Россией и крымскими татарами. Еще когда и речи не было о присоединении Крыма к России, группа депутатов Государственного Совета Татарстана отправились с официальным визитом в Крым. Тогда мы должны были вручить крымским татарам обращение, принятое нами на внеочередной сессии.

Так как мы не были знакомы с



обстановкой на полуострове, несколько дней не могли попасть в Верховную Раду Крыма. Только спустя некоторое время мы смогли тайно встретиться с председателем Госсовета Республики Крым Владимиром Константиновым. По-другому уже было нельзя – Рада была окружена вооруженными людьми, и кроме депутатов туда никого не пускали.

Нам разрешили получасовое выступление на Крымском телевидении. Его содержит олигарх Исламов, проживающий в Москве. Нам задавали много не очень приятных вопросов, и мы, исходя из своих дипломатических возможностей, отвечали на них. Возможно, они кому-то и не понравились. От тех земляков, которые видели наше выступление по спутниковому телевидению, пришлось услышать слова критики. Но многие с нами соглашались, чему мы были искренне рады.

Тогда же мы встретились и с представителем Милли меджлиса Рифатом Чубаровым. В Крыму, так же как и в Самаре, много татарских общественных организаций. Однако Милли меджлис является самой одиозной. Это организация образовалась еще в Советское время и с тех пор ее руководителем является Мустафа Джемилев. Защищая права крымских татар, ему не раз пришлось сидеть в тюрьмах. Он даже вывел на Красную площадь людей. И теперь он не верит российским властям, так как эту страну считает продолжением Советского Союза. Оно и понятно, ведь до сих пор (эта встреча проходила еще в апреле) нет закона о реабилитации крымских татар. Но президент обещает, что крымские татары будут восстановлены в правах.

Остальные крымско-татарские общественные организации относятся к России лояльно. Это мы видели и по результатам референдума в Крыму.

Но проблем в Крыму хватает не только у татар. Когда едешь по Крыму диву даешься неухоженным территориям, лет двадцать не видевшим ремонта дорогам и домам. А инфраструктура, оставшаяся в наследство с Советских лет, требует капитального ремонта.

Но вот референдум в Крыму прошел, и крымчане ждут больших перемен. Те, что коснутся Крымских татар, надеюсь, найдут применение и по отношению к волжским татарам. Татарстан напрямую участвовал в присоединении Крыма к России, и теперь мы паны или пропали.



**Ривгат ХУЗИН, председатель городской национально-культурной автономии татар:**

– Считают ли крымские татары нас сородичами?

– Говоря по правде, большая часть крымских татар считает себя людьми отличной от нас нацией. И это так. Они говорят по-другому, живут по-другому и у них другая история. Они выходцы не из Азии, а Европы. И по внешнему виду они европеиды.

Но у нас еще есть и общая история. В Казанском ханстве ханом мог быть только крымский татарин. Нас разделяет и советское прошлое. Когда крымских татар грузили в вагоны и отправляли в ссылку, сопровождать их приставили почему-то волжских татар. Поэтому у них сложилось о нас определенное мнение.

Но если заглянуть в архивы, то можно увидеть, что Сталин готовил репрессии и по отношению к волжским татарам. Только это очередное злодейство Сталин не успел совершить.



**Азат НАДИРОВ, член общества «Туган тел»:**

– Возможно ли пользуясь службой «Книга – почтой» получать книги на татарском языке от издательства «Китап»? И решается ли в Татарстане вопрос о сдаче ЕГЭ на родном языке?

– По-моему, во времена интернета это не проблема. Вы можете зайти на сайт издательства и увидеть, какие книги готовятся к печати, заказать дополнительный тираж для Самарской области и поехать забрать.

А что касается ЕГЭ, это наш самый больной вопрос. Ребенок должен одинаково хорошо знать и родной, и русский язык. В других странах этот вопрос решается как-то безболезненно. А у нас родители считают, что их ребенку лучше учиться только на русском языке, чтобы лучше сдавать экзамены в институты. Этим они еще больше отдаляются от родного языка.

В странах Европы молодые люди свободно говорят на 3 – 4 языках. А у нас не то методика плоха, не то родители недопонимают чего-то. Но отмазка найдена, и дети совершенно не хотят учить татарский язык.

**Азат НАДИРОВ:**

– Как вы смотрите не то, что правительство страны ведет политику ликвидации автономных республик?

– Конечно, эти слова не родились на пустом месте. Государство начало с того, что предложило подобрать вместо слова «президент» другое, более подходящее слово. Московская пресса, например, давно уже именует Рустама Минниханова «Главой Республики Татарстан» А башкиры уже переименовали, и пост президента у них теперь называется «башлык». Но Татарстан еще думает. У нас есть еще год, и за это время мы придумаем достойную замену слову «президент». Мы хотим чтобы оно звучало одинаково и на русском, и на татарском языках.

А когда не станет президентов, – наверное возьмутся за республики. Мы думаем, что существует такая угроза. Но пример Крыма эту ситуацию должен изменить.



**Данияр САЙФИЕВ, редактор журнала "Самар татарлары":**

Крымским татарам обещаны места в правительстве Республики Крым. А Татарстан обращался с подобным предложением о выделении квот в Федеральном Собрании Российской Федерации?

– Никогда не возникало подобных ситуаций. Наоборот, часто сетуют на то, что слишком много татар в правительстве Татарстана. Но Федеральное Собрание Татарстана в основном представляют русские фамилии. Но тут есть своя хитрость – там есть люди, живущие в смешанных браках и сменившие свою фамилию на русскую.

**Данияр САЙФИЕВ:**

– Не трудно ли разрываться между политикой и поэзией? Одно другому не мешает? Вы кем себя считаете в большей степени?

– Кто-то уже говорил: «Роберт Миннуллин в поэзии политик, в политике – поэт». Вот уже 25 лет я являюсь депу-

татом Государственного Совета Татарстана. Всякое было – и трудностей повидали, и веселого наслушались. Но вот что важно: у поэта, близкого к политике, и стихи звучат совсем по-другому. Что называется – на злобу дня. Национальные поэты не могут быть просто поэтами. Он должны вести за собой.

Например, если бы Тукай не родился в свое время, когда шел подъем национального самосознания, смог ли он стать настолько великим поэтом? Ему было суждено родиться в это время и блеснуть всеми гранями своего таланта. Так и другие поэты и политики приходят на землю каждый со своей миссией.



**Шамил ГАЛИМОВ, исполнительный директор областной национально-культурной автономии, историк:**

– В Крыму живут 13 процентов татар, в Ульяновской области – 13, Оренбургской – 16. Везде примерно одинаково. Если дадут крымским татарам отличные от других права, как на это посмотрят остальные народы. И не дадут ли обратный ход этим правам?

– Пусть сначала дадут, а там посмотрим. Если им дадут, значит, должны и другим дать.

**Шамил ГАЛИМОВ:**

– Вы в одном из своих стихов писали: «Форма и содержание должны совпадать». В 1996 году Российской Федерацией был принят Закон «Об автономиях». Это совпало со временем вступления России в Совет Европы. Прошло 18 лет, а закон до сих пор не работает. Вы как депутат как думаете, почему этот закон не работает? И что нужно сделать, чтобы он заработал?

– Да, действительно, закон очень хорош, но вот беда – не обеспечен деньгами. Это его единственный недостаток. А, как известно, без денег нынче ничего не сделаешь. Поэтому-то воз и ныне там, как говорится.



**Раиля САФИНА, руководитель отдела культуры Камышлинской районной администрации.**

– Спасибо правительству Татарстана за предоставляемые квоты для поступления в высшие учебные заведения Татарстана, за места в общежитиях. Хотелось бы еще получать от вас учебники татарского языка для национальных школ.

– Учебники в Татарстане обновляются каждые пять лет. Как я уже говорил выше, от вас нужна только заявка на дополнительный тираж.



**Радик ГАЗИЗОВ, директор татарской школы “Яктылык”:**

– Учебники и для нас большая проблема. В нашей школе еще пользуются учебниками выпуска 1988 года. Потому что министерство образования Самарской области не закладывает в свой бюджет покупку книг на родном языке. Поэтому мы вынуждены обращаться в правительство Татарстана.

– Да, над этим следует подумать.



**Разия АЮПОВА, хозяйка кафе “Татарская кухня”:**

– Вот в газете «Бердэмлек» прочитала статью про вас. Там написано: «Молчанием убиваю оппонентов». А на вид вы очень скромный, миролюбивый человек. Думаем, и врагов у вас не должно быть.

– Ну, наверно, у успешного человека всегда есть злопыхатели. Только я их никогда не переубеждаю, в спор с ними не вступаю. Только мои стихи звучат для них ответом. Вот перед вами лежит моя новая книга «Татарларым». Вступительное слово к ней написал сам Минтимер Шаймиев. Это большая честь для меня. Хочу на прощание прочесть одно стихотворение из этой книги

**Үз җирендә**

Үз җирендә яшәү бәхеттер ул,
Үләне дә аның бәрхеттер ул.
Бәхеттер ул үз көеңне көйләү,
Рәхәттер ул үз телеңдә сөйләү…
Гомер узды кеше көен көйләп,
Гомер узды башка телдә сөйләп.
Рәхәттер ул газиз үз көеңнең,
Рәхәттер ул газиз үз илеңнең
Капкаларын ачып керүләре,
Үз көнеңне үзең күрүләре.
Моңланабыз һаман чит телләрдә,
Үзләребез һаман чит илләрдә.
Үз җирендә яшәү бәхеттер ул,
Тупсасы да аның тәхеттер ул.



# АЧ, ШИГЪРИЯТ, СЕРЛӘРЕҢНЕ!

*Самар өлкә "Туган тел" татар җәмгыяте икенче тапкыр шигырь укучылар бәйгесен уздырды.*

*Римма НУРЕТДИНОВА,*
*Әнәс МИНГАЛИЕВ фотосурәтләре*



Апрель – Тукай ае. Ә Тукай ул – туган тел, туган ил, шигърият дөньясы. Табигать яңарган көннәрдә күңелләрдә үзеннән-үзе шигъри юллар туа, аларны кемгәдер сөйлисе, хисләр белән уртаклашасы килә.

Халыклар дуслыгы йортының тамаша залына апрельнең матур бу көнендә шигъриятькә мөкиббән төрле яштәге кешеләр һәм төрле һөнәр ияләре җыелды. Бәйрәмгә күренекле татар шагыйре, сәясәтче, Татарстан Республикасының Дәүләт Советы депутаты Роберт Миңнуллин да чакырылган иде. Олы башын кече итеп, ерак юлны якын итеп килгән Роберт әфәнде чарага кадәр ике сәгать буе төбәгебезнең милли-мәдәни тормышы активистлары белән аралашты, күптән түгел Кырымга арадашчы булып барганда алган тәэсирләрен уртаклашты, күпсанлы сорауларга җавап бирде.



Шигърият кичәсен "Туган тел" оешмасы әгъзалары - чараны үткәрүгә күп көч куйган Фәрхәт һәм Альбина Мәхмүтовлар башлап җибәрделәр. Бәйгедә, яшьләре буенча дүрт төркемгә бүленеп, 44 конкурсант катнашты. Һәммәсе дә бөтен осталыкларын җигеп, шигырьләрне интонация, паузалар белән, сәнгатьле итеп укырга тырыштылар. Репертуар да бик бай иде: татар классикларының иҗат җимешләреннән башлап үзләре язган шигырьләргә кадәр.

Роберт Миңнуллин да чыгыш ясады. Ул үзенең шигырьләрен укыганда тәннәр чымырдап китте, газиз татар халкыбызның киләчәге өчен борчу уянды.

Бәйгедә катнашучыларның осталыкларын жюри әгъзалары – Роберт Миңнуллин, өлкә "Туган тел" татар җәмгыяте президенты Ильяс Шәкүров, "Бердәмлек" һәм "Сәлам" газеталары хезмәткәрләре Эльмира Шәвәлиева һәм Фәрит Ширияздданов, «Самар татарлары» мәгълүмат порталы редакторы Римма Нуретдинова бәяләделәр.

Ниһаять, бәйгедә җиңүчеләрнең исемнәре билгеле булды. Кечкенәләр төркемендә беренче урын 6 яшьлек Нурия Хөснелгатинага бирелде. Ул "Минем бабам - гармунчы" шигырен сөйләп, залны әсир итте. Ильяс абыйсының кулыннан бүләк алганда: "Аллаһының рәхмәте яусын", – дип әйтеп, спонсорның күңелен бөтенләй эретеп җибәрде. Бу номинациядә Самарның «Яктылык» мәктәбе укучылары Илмаз Гарипов (укытучысы – Галия Тупасова) – икенче урынга, Рената Турсунова (укытучысы – Нурзидә Фәйзуллина) өченче урынга лаек булдылар.

Ун-унөч яштәге балалар төркемендә "Яктылык" мәктәбе укучысы Юлия Закирова (укытучысы – Нурзидә Фәйзуллина) җиңеп чыкты. Камышлы мәктәбе укучысы Линар Раянов (укытучысы – Тамара Хисмәтова) Роберт Миңнуллинның «Туган телемә» һәм «Яктылык» мәктәбе укучысы Гүзәлия Шәкүрова (укытучысы – Нурзидә Фәйзуллина) Гөлшат Зәйнашеваның «Җиңү бәйрәме – изге бәйрәм» шигырьләре белән икенче-өченче урыннарны алдылар.

14-17 яштәге балалар арасында Камышлы мәктәбе укучысы Роза Абсаттарова (укытучысы- Гөлчәчәк Гарипова) Нәҗар Нәҗминең «Татар теле» шигырен укып, беренчелекне яулады. Иске Ярмәк мәктәбе укучылары Лилия Шәйхетдинова Зыя Ярмәкинең "Юкәле тау", ә Алисә Бәдретдинова (укытучылары – Әлфия Баһаутдинова) Габдулла Тукайның "Китап" шигыре белән икенче-өченче урыннарга чыктылар.

Олы яштәге шигырь сөйләүчеләр арасында Иске Ярмәк авылында туыпүскән, Яңа Усман авылында гомер кичерүче Илһамия Гарипова биел үзе иҗат иткән «Улыма хат» шигыре белән тамашачыны нык дулкынландырды һәм беренчелекне яулады. Ә аның кызы Гөлназ Биксалиева (үткән елда энисенең шигырен укып, Гран-при яулаган иде) быел Муса Җәлилнең «Вәхшәт» шигыре белән икенче урынны алды. Айсылу Мостакаева Роберт Миңнуллинның "Беләм мин үзем генә" шигыре белән өченче урынга чыкты.

«Яктылык» мәктәбе укучысы Эльмира Мәҗитованың (укытучысы – Фәния Гыйләҗева) шигырь уку осталыгы, аның тел чисталыгы жюри әгъзаларын әсир итте һәм аңа Гран-при бирелде. Иң зур приз – киң экранлы телевизор да аңа хаклы рәвештә тапшырылды.

Бәйрәмне оештыручылар һәм жюри әгъзалары җиңүчеләрне тәбрикләп, барлык катнашучыларга да рәхмәтләрен белдерделәр. Шигырь бәйрәмендә катнашучы бер генә кеше дә игътибардан читтә калмады, барысына да истәлекле бүләкләр тапшырылды.

Имам – хатыб Центральной мечети Наиль Гайнетдинович Гиматдинов, открывая торжественное мероприятие, выступил с приветственным словом и рассказал об истории этого храма. Затем учащиеся Теплостанского филиала Елховской школы выступили со стихотворениями известного татарского поэта Габдуллы Тукая и мунажатами (от арабского - «религиозный гимн, псалом», поэтические произведения религиозного характера в литературах стран Востока и некоторых тюркоязычных народов, в частности, татар), которые были ими разучены специально для юбилейного мероприятия на уроках родного (татарского) языка и литературы при сотрудничестве сельской библиотеки с. Теплый Стан.



# МЕЧЕТЬ В СЕЛЕ ТЕПЛЫЙ СТАН ОТМЕТИЛА 110-ЛЕТИЕ

***17 мая Центральная, или, как ее называют, Каменная мечеть села Теплый Стан отпраздновала свое 110-летие. На торжественное мероприятие съехались гости со всей Самарской области и гости из соседней Ульяновской области.***

***Р.Р. ЗАКИЕВА.***
*Фото* ***Али-хазрата СУЛЕЙМАНОВА***

С приветственным словом и поздравлениями выступил Муфтий Самарской области Талип-хазрат Яруллин, который отметил вклад Центральной мечети не только в религию, но и в культурное наследие села Теплый Стан, муниципального района Елховский, а также всей Самарской области.



Глава района В. Н. Дементьев поздравил всех присутствующих с юбилеем мечети, отметив, что даже в годы советской власти, когда религия была под запретом, здание мечети не было разрушено, а стало сначала школой, а затем сельской библиотекой. Даже в те тяжелые времена это здание было храмом, храмом знаний, для сельских жителей.

Строительство Центральной мечети в с. Теплый Стан началось ещё в далеком 1873 г., первоначально была построена деревянная мечеть, которая сгорела в результате пожара в 1893 г., а в 1895 г. жители села начали строительство мечети из кирпича или камня, как его называли простые крестьяне (отсюда и закрепившееся название - Каменная мечеть).

Здание было построено силами жителей села, без какой-либо помощи от кого-либо, крестьяне засеивали отдельно поля, выручка от продажи урожая которых шла только на строительство.

Нынешнее здание было достроено в 1904 г., но недолго Каменная мечеть была храмом религии. В первой половине 1930 г. здание было передано государству, а минарет убрали 7 ноября этого же года.

После этого в здании мечети открыли начальную школу, а после постройки и открытия нового двухэтажного здания школы в 1969 г. в этом здании стал работать спортивный зал для начальной школы. Через некоторое время сюда перевели сельскую библиотеку.

И только в 1992 г. храм заработал как мечеть, и в этом неоценима заслуга односельчан, которые приложили неимоверные усилия для восстановления храма, помогали



все, кто чем мог. Кто стройматериалами и доставкой этих материалов, кто ремонтно-строительными работами. Их имена навеки останутся в исторической летописи мечети. Это М.В. Харисов, Г.Н. Мустафин, М.З. Сабиров, Р.Х. Ягудин, он оказал содействие при доставке купола с полумесяцем, Т.Т. Хузин, Р.Т. Хузин, Р.А. Насыров, С.И. Шакуров, М.М. Мустафин, Д.В. Шарапов, И.Л. Латыпов и другие. Для успешной работы мечети внесли свой вклад Н. В. Мустафин, Х.М. Летфуллин, Л.Г. Латыпов, Т.В. Хузин, Я.Г. Абдуллов, Р.В. Усманов, М.М. Хисматуллин, Т.В. Давлетшин.





Председатель махалли Центральной мечети Р. В. Харисов принял активное участие в организации этого праздничного мероприятия.

Сегодня мечеть, несмотря на свое 110-летие, представляет собой светлое, отвечающее всем санитарным и пожарным требованиям здание, и, конечно же, его можно причислить к историческому и культурному наследию Самарской области.

Более 150 человек мужчин, женщин, детей, молодых и пожилых жителей Самарской и Ульяновской областей объединило это событие, имеющее не только религиозное, но культурное и историческое значение.




# НЕ ЗАБУДЬТЕ ПОДПИСАТЬСЯ!

ПРОДОЛЖАЕТСЯ ПОДПИСКА НА ГАЗЕТЫ И ЖУРНАЛЫ НА 2014 ГОД

В почтовых отделениях Самарской области вы можете подписаться и на журнал **«САМАР ТАТАРЛАРЫ» («САМАРСКИЕ ТАТАРЫ»).** Подписной индекс издания **72675.**

Стоимость подписки на **3 месяца** составляет 212 рублей 3 копейки, на **6 месяцев** – 424 рублей 6 копеек.

Напомним, что полноцветный глянцевый журнал «Самар татарлары» выходит с декабря 2012 года периодичностью один раз в квартал. Издание рассказывает об истории, культуре, современной жизни самарских татар. 15 октября 2013 г. журнал получил свидетельство о регистрации средства массовой информации в Управлении Федеральной службы по надзору в сфере связи, информационных технологий и массовых коммуникаций по Самарской области.

ПОДПИСАТЬСЯ НА ИЗДАНИЕ МОЖНО
**В ЛЮБОМ ПОЧТОВОМ ОТДЕЛЕНИИ!**




ОАО Агентство «Роспечать»

**АБОНЕМЕНТ** на ~~газету~~ / журнал **72675** (индекс издания)

**Самар татарлары**
(наименование издания) Количество комплектов:

на 201_ год по месяцам:

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | |

Куда ______ (почтовый индекс) ______ (адрес)

Кому ______ (фамилия, инициалы)

ПВ | место | литер

на ~~газету~~ / журнал **72675** (индекс издания)

**Самар татарлары**
(наименование издания)

| Стои-мость | подписки | руб. коп. | Количество комплектов |
|---|---|---|---|
| | переадресовки | руб. коп. | |

на 201_ год по месяцам:

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | |

Куда ______ (почтовый индекс) ______ (адрес)

Кому ______ (фамилия, инициалы)




*Минем кулда вакыттан саргаеп, таушалып беткән немец телендәге ниндидер язу бланкалары. Аларның кире ягында каләм белән язылган, “Фашизм коллыгында. Башымнан үткән хәлләр турында кечкенә хикәя” дип аталган, авылдашым Сабир Ярулла улы Сафиуллинның истәлек язмалары.*

*Сабир абый Бөек Ватан сугышының беренче көннәреннән үк фронтның алгы сызыгында хезмәт иткән. Сугышка барып керүгә алты ай була дигәндә, бик каты яраланып, госпитальгә җибәрелә. Аннан соң аңарга туган Яңа Ярмәк авылына кайтып, тугыз ай дәваланырга, яраларын төзәтергә бирәләр. 1942 елның октябреннән, терелеп беткәннән соң, Сабир абыйны кабат фронтка җибәрәләр, һәм аңа инде иң канкойгыч бәрелешләрдә - Сталинград сугышында катнашырга туры килә.*

*1943 елның язында Сабир Ярулла улы Сафиуллин хезмәт иткән хәрби часть Белгород өлкәсендәге Төньяк Донец елгасы янында оборона тотуда катнаша. Әлеге бәрелештә Сабир абый әсирлеккә эләгә. Концлагерьдан азат ителгәч, 1945 елның март аенда Польшаның Цехотинек шәһәрендәге шифаханәләрнең берсендә дәваланганда язган Сабир Ярулла улының истәлек язмалары минем кулга килеп эләкте дә инде. Бу кыйммәтле язуларны миңа 1976 елда вафат булган Сабир абыйның тормыш иптәше Мөсәвәрә апа: “Бүгенге яшьләр сугыш афәтен күрмәсен, тик аларның бәхетле тормышы өчен кан койган кешеләрне дә онытмасыннар иде”,- дип кулыма тоттырды.*

*Әлеге язмалар белән укучыларыбызны таныштыруны үземнең бурычым, дип саныйм.*

*Алия Арсланова*



***Сабир Ярулла улы Сафиуллин.***
*Польша, Цехотинек шәһәре.*
*18.03.1945 - 23.03.1945*

# ФАШИЗМ КОЛЛЫГЫНДА

***Яшьлек гомрем минем шундый кыска,***
***Шундый кыска булып тоелды.***
***Кичен чәчәк аткан булды, ә таңында,***
***Ә таңында инде коелды...***
*(Һ. Такташтан)*

Май ае үтү белән, безне Яңа Товалжанка авылына күчерделәр.

Бу зур авылның күп өлеше Төньяк Донец елгасының көнчыгыш ягына урнашып, зур булмаган өлеше генә Көнбатыш ярга утырган. Донец елгасы, елан кебек, кәкере-бөкере булып, үзенең комлы ярларын ашый-ашый, барып җитәсе җире бар кебек, кайдадыр ашыга. Елга ярларыннан башлап, көнчыгышка иге-чиге булмаган тигезлек сузыла, анда кайчандыр дулкынланып торган иген басулары, яшәреп яткан чөгендер кырлары булса, хәзер ул урыннарда, сугыш аркасында чәчелми калганлыктан, чүп үләннәре дулкынланып тора.

Ә көнбатыш ярыннан тар гына болыт сузыла да аннан елганың бөтен буена кинәт биек булып таулар китә. Тауларның безгә караган битләре куе урманлык.

Елганың ике як яры буйлап урнашкан алма бакчаларының тәмле исләре июль аеның җылы төннәрендә бөтен тирә-якка таралып, таң алдыннан искән җылы җилләр шул тәмле исләрне борыннарга китереп бәрә дә, күңелләр әллә ни эшләп китә. Сугышка кадәр яраткан (сөйгән) кызларың белән йөргән Сок буеның җәйге матур төннәрен искә төшерә. Гүя үзеңне шунда итеп сизәсең.

Тик елганың аргы ягыннан аткан пулемет тавышлары һәм баш өстеннән очкан утлы пулялар гына төннең тынлыгын бозып, кинәт искәртеп җибәрә дә төрле уйлар баштан тарала.

Озакламый көнчыгышта сызылып таң ата, әкрен генә искән таң җилләре, шаян кызлар кебек, битләрне сыйпап үтәләр. Күп тә үтми, ерак таулар артыннан елмаеп кояш күтәрелә, аның алсу нурлары иң элек шушы тау битендәге алма бакчаларына төшә.

Июль аеның соңгы көннәре иде. Көн кызу. Кояш нәкъ баш өстендә үзенең җылы нурларын сибеп яна.

Авыл тын. Бер кеше дә юк диярлек, йортларның яртысыннан күбесе янып беткән. Биредә гаскәри кешеләрдән башка кеше йөрегәне күренми. Бакчаларда чәчелгән арышлар, вакытында урмаганлыктан, саргаеп, җиргә егыла башлаганнар. Бу авылны бер күру белән үк монда кайчандыр көчле сугыш уты уйнаганын белергә була.

Мин ике атналар чамасы комендат взводында булганнан соң, миңа отделение белән киредән иске урынга, үзебезнең оборонага кайтырга приказ булды. Күп тә үтмәде, 31 июль көнне,

кичкә таба, безнең ротага төнлә Донецны үтеп, авылның елга аръягындагы өлешеннән немецларны бәреп чыгарырга сугышчан приказ булды.

Барлык нәрсәләрне житештердек, өстәмә рәвештә патроннар, гранаталар алып, караңгы төшкәч, күкрәктән су ерып, елганы үттек. Төн караңгы иде. Елганың шаулавы аркасында дошман безнең үткәнне сизмәде. Биек ташлы ярны үрмәләм мендек.

Безнең взвод, билгеләнгән урынга барып, дошманның пулеметы урнашкан өйләрне уратып алды. Ике арада гранаталар белән сугыш башланды. Коеп яңгыр ява, төн караңгы. Күзгә китереп төртсәләр дә, күрерлек түгел.

Хәзер дошман безнең килгәнне белеп, ракеталар белән яктыртып, төрле яктан ут ачты. Шулай итеп, ике арада таңга кадәр каты бәрелешләр барды.

Яктыра башлагач, бу хәлне күреп, дошман күп санда көч салып, безгә һөҗүм итә башлады. Дошманның күп мәртәбәләр артык көч белән килгәнен күргәч, безгә елгага таба чигенергә приказ булды.

Кырыемда гына бертуктаусыз пулемет атып тора, мин дә шунда ук ятып, автоматымнан дошманга ут ачтым. Шул чакта яныма граната килеп төште. Сикереп торып, күршедәге чокырга ташландым, ләкин өлгерә алмыйча калдым. Бер-ике адым атлавым белән шартлау яңгырады, һәм мин чалкан аудым. Ничектер йөзтүбән әйләнеп, аркага киелгән капчыкны салдым да артка таба үрмәли башладым. Пулеметтан атучылар да яраланган иде. Аларның берсе миңа ярдәм итәргә тырышты. Без икәү берничә метр шуыштык микән, минем күз аллары караңгыланып, артык бара алмас булдым. Иптәшем миңа:

- Әйдә, шуыш, моннан ерак түгел окоп бар, шунда ятып, яраларыбызны бәйләрбез, - диде.

Мин башкача бара алмаганымны әйткәч, ул мине өстерәп, шул окопка алып барды да чалбар балакларын кисеп, бер аякка жгут салды. Көч-хәл белән күземне ачтым. Карасам, бөтен җиремдә кан, тәнем, куллар, үлгән кешенеке кебек, сапсары, авызым кипкән, үлеп эчәсем килә. Исән калырмын дип уйламыйм да инде. Иптәшемә: "Әгәр үлә калсам, өйгә хәбәр итәрсез. Адресымны кесәдән ал да, артка кит. Мөмкинлек булса, санитарлар белән кич килеп алырсыз", - дип әйткәнем исемдә, аннан соң аңымны югалтканмын.

Күпме вакыт үткәндер, белмим, ниндидер кычкырган ят тавышка күземне ачып җибәрдем. Окоп өстендә, автоматларын миңа төзәгән ике немец басып тора. Йөрәгем жу итеп, тәнемә салкын су сипкәндәй булды.

– Рус капут? Рус ком? – дип кычкыралар болар.

Минем селкенәргә дә хәлем юк, кан эчендә ятам.

Бер немец үзенчә сүгенә-сүгенә кулларымнан тотып, өстерәп чыгарды да, капчык аскандай итеп, үз якларына таба өстерәп китте. Окоплары янына җиткәч, аркылы-торкылы яткан үлгән немецларны күрдем.

Соңыннан мине носилкаларга салып, 1-2 км чамасы бер авылга илтеп, ниндидер өй янына ташладылар.

Алар китү белән, яныма авыл халкы җыелды. Алар миңа ашарга, эчәргә китерделәр. Ләкин миндә ашау кайгысы түгел иде. Салкыннан калтырап торганымны күргәч, хатын-кызлар әйберләр алып килеп, астыма җәйделәр, өскә яптылар.

Кичкә таба ике немец килеп, мине арбага салдылар һәм 8 км чамасы ераклыктагы башка авылга алып киттеләр. Минем белән тагын ике яраланган кызылармеец бар иде. Безне бер чыланга ябып куйдылар. Төнлә безнең самолетлар килеп, бомбалар ыргытып киттеләр. Безне бикләгән өй янына да бомба килеп төште. Бер солдат үлде, икебезне яралады. Минем башка да, кулга да кыйпылчыклар эләкте.

2 нче август көнне Харьковка озаттылар. Фронттан бары 60 км гына идек. Кич бер зур йортка китереп, бер бүлмәгә япканнарын гына беләм, шуннан арып йокыга киткәнмен.

Күземне ачканда бик матур көн иде. Ниндидер зур якты бүлмәдә ятам. Тирә-як тып-тын. Хәлем бик авыр. Бөтен тәнем авырта, эчем яна. Авызым кипкәнлектән, телемне дә селкетә алмыйм. Шулвакыт бер яшь кенә кыз идән себерергә керде. Бар көчемне җыеп, аңардан эчәргә сорадым. Су эчеп, хәл алгач, аның безнең кеше икәнен белеп, аңардан бу кай җир булуын һәм бүген нинди көн икәнен сорадым. Ул миңа бу җирне Полтава шәһәре булуын һәм бүген 8 август икәнен әйтте.

Бераз яткач, аякларымны хәрәкәтләтеп карыйм, тик нигәдер бер аякның икенчесенә бәрелгәнен тоймыйм. Нигә болай икән дип, одеялны ачып карасам, уң аяк бөтенләй юк!

Димәк, мин берәр атна аңсыз булганмын! Яраларым төзәлмичә, гангрена башланган һәм аягымны кисеп алганнар.

Мин ике айдан артык чирләп яттым. Температура 39-40 градустан төшмәде. Бик нык ябыгып, кипкән сары яфракка охшап калдым. Йөздән кеше төсе китте. Дөньяда яшәү өмете өзелде.

Бу чакта миңа үлем куркыныч түгел иде инде. Тик үлгән кешеләрнең эт үләксәсе сыман аяк астында аунап ятуларын күреп, үлсәм, мин дә шулай ятармын, күмүче булмас, дип уфтандым. Әнкәй үлгәнче улын көтәр, минем кайгыдан вакытсыз үләр, малаеның үлеп, инде туфрак булып ятканын әйтүче булмас, дип уйлый идем.

***"Бар үткәнем минем озын төн күк,***
***Шундый авыр, кайгы-сагышлы...***
***Яңгырлы көз, йә көртле кыш кебек***
***Үлем белән озак тартыштым..."***

Неман елгасыннан көнбатышка таба 80 чакрымнар чамасы ераклыкта артык зур түгел Сувалки исемле поляк шәһәре бар. Баскыч-баскыч булып күтәрелгән тау битләрендә тезелешеп утырган авыллар ерактан күренеп торалар. Шәһәрнең төн ягына таба озын тигезлек сузылган. Ә аннан соң тагын урманнар башланып китә.

Менә шул шәһәр белән урман арасындагы кайчандыр ашлык кырлары булган тигезлектә фашистлар хәрби әсирләр лагере төзеп куйганнар. Аның тирә-ягы биек, кош та очып үтә алмаслык итеп, чәнечкеле тимерчыбык белән уратылган. Почмакларында - биек башнялар. Анда автоматлар, пулеметлар белән коралланган сакчылар куелган. Алар бер-бер артлы лагерь тирәсендә әйләнеп йөриләр.

Лагерьның эче әле тагын

чәнечкеле тимерчыбыклар белән унга якын өлешкә бүленгән. Шуларның һәрберсендә яисә землянкаларда меңгә якын әсир тотыла. Ә сугышның беренче елларында, торыр урыннары булмаганлыктан, әсирләр кышын да, җәен дә ачык һавада ятарга мәҗбүр булганнар. Шуңа да йөзләгән, меңләгән кеше бу вәхшилеккә түзә алмыйча, үлемгә дучар ителгән. Андыйлар күмелгән урман алдындагы каберлектә инде куе үлән үсеп утыра.

Мине дә шушы лагерьга китереп япкач, күңелем әрнеп, түбәндәге шигъри юллар туды:

***Еллар үтәр...***
***Минем кайдалыкны беркем белмәс,***
***Һичкем алмас мине исенә.***
***Язгы матур алсу таң атканда***
***Кошлар сайрар каберем өстендә.***

Мин килеп эләккәндә, лагерьда тору урыннары берникадәр эшләнгән булса да, яшәү, әгәр моны яшәү дип атап булса, бик тә авыр, ашау начар иде. Иртән һәр әсиргә ярты литр кәбестә яисә шалкан суы бирелә. Якшәмбе көннәрендә иртәнге аш дигән нәрсә бөтенләй юк, ә төшкә - бары тик тозлы су гына. Кичен кеше башына ярты литр чәй һәм 300 грамм ипи кисәге эләгә. Ипи дигәннәре йә агач, йә кыргый каштан оны кушып пешерелгән була иде. Киемнәр аламаланып бетеп, тишекләреннән тән күренеп тора. Ашау җитмәүлектән кеше тиз арада нык ябыгып, хәлсезләнә дә, ниндидер бер чир эләгеп, үлеп тә китә. Кайберәүләр чирләмичә, йөргән урыннарында ятып үләләр. Үлгәч тә, күмелмичә, йортта озак аунап ятучылар күп очрый иде.

Кайбер атналарда якын-тирәдәге авыллардан поляк хатын-кызлары әсирләргә төрле вак-төяк, тәмәке алып киләләр. Тик әсирләргә бернәрсә дә бирергә ярамый. Безне җәлләп, бер читтәрәк елашып басып торалар да, күз яшьләрен яулыкларына сөртәсөртә кире китеп баралар.

Бик нык сакласалар да, барыбер лагерьдан качучылар көн саен диярлек булып тора иде. Шуңа күрә кич җитүгә һәр блокка икешәр, өчәр эт җибәрелә. Ялгыш кына бараклан чыгасың икән, этләр баштан киемнәреңне, аннан тәннәреңне өзгәләп бетерәчәкләр. Шулай этләрдән талатып, күп кешенең башына җиттеләр бирелә.

Көн саен бер мәртәбә һәр бараклагы кешеләрне санап чыгалар һәм шуның буенча ипи һәм аш өләшәләр. Бер хәл әлегедәй исемдә. Июль азакларында безнең бараклагы бер карт әз генә авырып ятты да үлеп китте. Санитарлар аның үлгәнен сиздермичә, өстенә сәләмә әйберләр ябып куйдылар: янәсе йокларга яткан. Санау вакыты җитүгә бер немец барагыбызга керде дә башкалар белән беррәттән шушы үлгән картны да санады. Кич белән аның өлешенә тигән ипи сыныгын ничек бүләргә дип тавыш күтәрелде. 300 грамм кыерчыкны бараклагы сиксән кешегә бүлгәч, бер кабырлык та булмаячагын аңлагач, шуны тәмәкегә алыштырырга булдылар. Нәтиҗәдә ун төрерлек тәмәке эләкте. Бу да безнең өчен бәйрәм иде.

Август урталарында фронт сызыгы Сувалки шәһәренә якынлашты. Безнекеләр аткан туплар лагерь өстеннән очып үтеп, шәһәргә төшеп шартлый башладылар. Моны күреп, немецларның тылдагы частьлары тәртипсез рәвештә качарга керештеләр. Тиздән лагерь тирәсендә каравылда торучылар гына калды.

Безнең Кызыл Армия частьләренә шәһәргә дүрт-биш чакрым гына килеп җитмичә, тукталырга туры килә. Ә лагырьда хәл тагын да кискенләшә төшеп, ипи бирүне бөтенләй кистеләр. Кайчакта гына 1 килограмм 800 грамм күләмендәге ипине утызлап кешегә бүлеп бирәләр иде. Ипи урынына еш кына чи бәрәңге тараталар, шул берничә бәрәңгене пешерү өчен лагерь уртасына учак ягыла һәм, бөтен тирә-юньне куе төтен басып, ул чегән табырына охшап кала иде.

Ашарга булмаганлыктан, лагерь эчендәге бар үләнне ашап бетерделәр, бер немец солдаты алып килгән ике этне дә суеп ашадылар. Ачлык шулкадәрлегә җитте ки, хәтта үлгән кешеләрнең итен ашау очраклары да булгалады.

Көннәрнең берсендә фронтның бер урында таптануыннан файдаланып, лагерьны ташлап киткән түрәләр әйләнеп кайттылар да, әсирләрне вагоннарга төяп, башка урынга алып киттеләр.

Поездда берәр тәүлек барганбыздыр. Шуннан соң бер станциядә тукталыш ясап, озак машина көттерделәр. Кайсы җир, нинди урын икәнен дә белмибез. Бөтен сәләтемне, белемемне җыеп, сакта торучы фрицтан немецчәләп сорадым:

– Wie heist deser orf hier? - мәйтәм. (Как называется это место?)

– Торн, - диде ул тешен кысып кына. Шунда мин үзебезнең Висла елгасы буендагы Торн шәһәре янында икәнлегебезне белдем.

Монда безне, башка лагерьларга караганда да, мөшкелрәк хәлләр каршы алды: иртәнге аш бөтенләй бирелми, төшкә кадәр тормыйча одеял яисә алама шинелең белән башыңнан капланган килеш ятасың да, сәгать 11-12 тирәсендә литрга якын кәбестәбрюква суын эчәсең һәм тагын бөкрәеп ятуны дәвам итәсең.

Кичен немец сакчысы санап чыга да, ипи китерәләр. Шуннан аны үлчәп бүлү башлана. Һәр порциягә номерлар куеп, шундый ук санны бүреккә салып бутыйлар, син тыгылып өлешеңә тигәнен аласың. Ипине бер-ике кабуга ашап та бетерәсең. Чәй бирүләрен дә көтеп торып булмый. 1 килограмм 800 грамм авырлыгындагы ипине 6-7 кешегә бүлгәч, 250-300 граммлап тия.

Көннәр салкынайганнан салкыная бара. Җылырак вакытта инвалидлар барагыннан чыгып, бераз йортта аксый-туксый йөри идек әле. Хәзер, салкыннар башлангач, бөтенләй урыннардан тормас булдык.

Юп-юка түбә такталары төнге салкыннан карланып туңалар да, көндезләрен кеше сулышыннан тамчы булып эреп, бертуктаусыз өскә тамып торалар.

Өшүгә чыдый алмыйча, кайвакытларда, сакчыларга күрсәтмичә, буш агач караватларны ватып яккалый идек. Моны немец күреп алса, таяк белән кыйнап, иртәгесен ашарга бөтенләй бернәрсә дә бирми иде.

Менә шундый хәлләр белән интегеп, караңгылыкта көн саен үлем көтеп торганда, кинәттән сызылып таң атты.

1945 елның 23 январында безнекеләр килеп, коллык богауларын салдырып, безне фашизм әсирлегеннән азат иттеләр. Без, әсирлектә ничәмә еллар газап чигүчеләр, чәнечкеле тимерчыбыкларны өзеп чыктык та, коткаручыларыбызны кочаклап, туйганчы елаштык. Соңыннан аларга уңышлар һәм исәнлек теләп, көнчыгышка бара торган киң юл белән алга, туган илгә таба атладык.

Безнең өстә үзенең ирек нурларын чәчеп, коммунизм кояшы яна иде.



# ВЕТЕРАНЫ ВОЙНЫ – ВЕЗДЕ ЖЕЛАННЫЕ И ПОЧЕТНЫЕ ГОСТИ

Пока крымские татары находятся в ожидании исполнения указа В. Путина о реабилитации, на самом острове происходят не поддающиеся логике события. Незадолго до даты проведения уже ставшего традиционным митинга крымских татар в память о жертвах сталинской депортации новые власти Крыма неожиданно запретили до 6 июня проведение любых массовых мероприятий, ссылаясь на якобы неспокойную обстановку на юго-востоке Украины. (Впрочем, там обстановка была даже более неспокойной, но не помешала проводить митинги и шествия по поводу включения Крыма в состав РФ). Следующий шаг, вызвавший волну возмущения коренных жителей – запрет на въезд на территорию Крыма Мустафы Джемилева. 3 мая его не пропустили через пограничный пост, а тысячи его соотечественников, прибывших встречать, были подвергнуты административному наказанию.

М. Джемилев – ветеран советского и российского правозащитного движения. За «антисоветскую деятельность» провел в тюрьмах и ссылке в общей сложности около 15 лет. В середине 1970-х, после возбуждения очередного уголовного дела против него, в знак протеста объявил голодовку, которая при принудительном кормлении через зонд продолжалась десять месяцев. Его часто сравнивают с Нельсоном Манделой. Дважды различными организациями он представлялся на Нобелевскую премию мира. В 2009 году кандидатуру Джемилева выдвигал на получение Нобелевской премии президиум Организации наций и народов. В организации считают, что глава меджлиса «проявил силу характера и незаурядную стойкость» в ненасильственном восстановлении прав крымских татар».



*Мустафа Джемилев*

Комментируя данное событие, и.о. главы Республики Крым, председатель Совета министров Сергей Аксенов заявил, что Джемилев якобы направлялся в Крым «с целью дестабилизировать обстановку». И, как водится, нашел «подстрекателей»: «Не вызывает сомнений, что данному человеку западными спецслужбами дана задача дестабилизировать ситуацию», – заявил Аксенов. По его мнению, «Джемилев пытается толкать свой народ на неадекватные действия, которые могут плохо закончиться для представителей всех национальностей». А сам Джемилев считает, что самопровозглашенные власти Крыма делают все, чтобы отвернуть от себя крымских татар.

Председатель Меджлиса крымскотатарского народа Рефат Чубаров призывает российские власти определиться, когда они искренни в отношении крымских татар: когда они говорят, что защищают их права, или когда запрещают проведение митингов.



**ТИМУР БУЛГАКОВ: – Посему, и в новом Крыму открываются большие возможности для национального развития. В частности, крымско-татарский язык впервые за многие десятилетия объявлен государственным, а это значит, что о поддержании и развитии языка будет заботиться не только частный бизнесмен Линур Ислямов, открывший 2 телеканала и другие энтузиасты, издающие литературу на крымско-татарском языке, но и, теперь уже и государство**

Он высказал возмущение попытками заглушить вертолетами проведение митинга. «Вертолеты, облетающие мирный митинг, где люди молятся о душах сотен погибших в годы тоталитарного режима – у нас по этому поводу возникает очень много вопросов», – отметил председатель Меджлиса. По его мнению, это показывает «что и как думают они о нас». «Вертолет – это был достойный ответ на многие ожидания крымских татар», – подчеркнул Чубаров. «Мы услышали о том (от российских властей), что будут восстанавливаться наши права. Это было с одной стороны. И при этом мы имеем проблемы с проведением вообще мемориальных мероприятий в память жертв депортации крымскотатарского народа. У нас хотели уничтожить память. Ни один народ не может существовать без своей исторической памяти, тем более, если речь идет о сотнях тысяч жертв в недавнем прошлом», – сказал председатель Меджлиса.

О том, что запрет властей Крыма на проведение массовых мероприятий был направлен именно против митинга памяти крымских татар, говорят такие факты. В Крыму в конце мая начался фестиваль казачьей культуры «Крымские тулумбасы-2014». Пресс-секретарь Совмина Крыма Н. Полончук высказалась, что это не является нарушением подписанного ранее указа, т.к. фестиваль проводится в закрытых помещениях.

23 мая также должна была состояться торжественная церемония награждения победителей

ежегодной научной премии «Мир Бекира Чобан-заде». Церемония также должна была проходить в помещении, однако его проведение запретили. Член комиссии премии Айдер Эмиров не понимает истинной причины запрета:. «Это неправильно, что одни мероприятия можно проводить, другие – нет. Но что может сделать благотворительный фонд Бекира Чобан-заде – небольшая общественная организация? Мы, как законопослушные




граждане, решили не нарушать этих правил», – сказал представитель фонда.

Пресс-секретарь «правительства» Крыма не смогла объяснить причины такого избирательного подхода. «Точно не могу сказать. Наверное, существуют какие-то определенные критерии массовых мероприятий», – сказала пресс-секретарь «Совета министров Крыма».

Когда случаются в эшелонах власти такие «проколы» – пора искать «стрелочника». И, кажется, уже нашли. Это – бывший журналист Григорий Иоффе, дослужившийся до зама спикера и приобретший, согласно его прошлогодней декларации о доходах, миллионное



**РУСТАМ АРИФДЖАНОВ: – Главное – народы Крыма – русские, украинцы и крымские татары получили свою автономную республику. В Российской Федерации присутствует множество национальных автономий с различным соотношением коренного национального населения и русских и накоплен большой опыт существования федеральных образований.**



состояние. «Погорел» он на стратегической ошибке – его рекомендации вступили в противоречие с официальной публичной политикой России и лично Путина. Это по совету Григория Адольфовича были подготовлены документы об освобождении с должности только назначенного вице-премьером Ленура Ислямова, которые были вовремя отложены. А Сергей Аксенов, следуя его рекомендациям, ввел совершенно неоправданный и ненужный запрет на массовые мероприятия в Крыму с 16 мая до 6 июня, что снизило «авторитет» власти – крымские татары траурный митинг все равно провели с неменьшим успехом, только не на привычном месте. Запрет вызвал отчуждение у крымских татар, обвинение в двойных стандартах и вынудил идеологов Совмина оправдываться.

Крымские татары на траурном митинге, посвященном 70-й годовщине депортации народов из Крыма, снова заявили о желании создать на полуострове собственную национально-территориальную автономию. В резолюции митинга указано, что создание в Крыму крымско-татарской национальной автономии основано на «нормативно-правовых актах международного права», в том числе – декларации ООН о правах коренных народов. Крымские татары будут выступать за возвращение исторических названий населенным пунктам и географическим объектам, которые переименовали после депортации. Также они собираются добиваться более широкого представительства крымских татар в органах власти Крыма. Квоты для татар и представителей других национальностей в органах власти Крыма вводить не планируется, все должности будут заниматься исключительно на профессиональной основе, заявил врио главы Крыма, председатель Совета министров республики Сергей Аксенов.



Некоторые требования митингующих далеки от реалий, но это можно отписать на счет популизма, присущего и крымским политикам. Но все больше звучат трезвые и вполне осознанные мысли. Но отнесем все это к «болезням роста», а, если хотите, – к пережиткам советского строя.

Перед крымскими татарами стоит задача интеграции в российское пространство, но времени на это катастрофически мало, говорит Нариман Джелялов, заместитель председателя Меджлиса крымско-татарского народа, руководитель информационно-аналитического управления. – Крымские татары хотят определить свой новый статус в составе России и решить национальные проблемы.



# ПОЧЕМУ КРЫМ НЕ СТАЛ КАЛИФОРНИЕЙ?

***Вся послереволюционная история Крыма могла бы стать прекрасным сюжетом для политического детектива. Здесь скрестились интересы не только наций, но и целых государств. Достаточно сказать, что в 1917 году в Крыму проживали представители 34 национальностей, по-разному относившиеся к революционным событиям, примыкавшие к различным течениям и движениям. Вскоре после февральских событий, 25 марта состоялось общее собрание мусульман Крыма, утвердивший состав Временного крымскотатарского (мусульманского) Исполнительного комитета. Дважды в годы гражданской войны в Крыму провозглашалась социалистическая республика, второй раз – 6 мая 1919 г. после изгнания с полуострова немецких войск и англо-французских интервентов. Но советская власть в Крыму окончательно утвердилась в ноябре 1920 года после победы над Врангелем.***

**Евгений Вольский**

8 октября 1921 г. ВЦИК принял положение «О Крымской Советской Социалистической Республике», но уже через десять дней этот же орган объявил об образовании Крымской АССР. В отличие от других появившихся в те годы автономных образований (например, Татарская, Башкирская, Бурятская и т.д.), в названии республики отсутствовал национальный компонент, хотя надпись на гербе Крымской АССР была исполнена на двух языках – русском и крымскотатарском.

Драматически развивались события с первых же лет образования Крымской АССР. В начале 20-х годов при активном содействии американской еврейской благотворительной организации «Джойнт» были предприняты попытки переселения в Крым евреев из РСФСР, Украины и Белоруссии с последующим созданием там еврейской автономии. В 1923 г. один из деятелей «Джойнта» Розен через Л. Каменева передал советскому правительству проект автономии, который занимал бы, кроме северной части Крыма, Одессу, Херсон и все Черноморское побережье до Сочи и Абхазии – более миллиона гектаров. Авторы проекта обещали за это содействие американских и международных еврейских организаций в получении СССР кредитов и оказать влияние на правительство США в признании СССР. В Политбюро ЦК ВКП(б) и правительстве этот проект активно поддержали Троцкий, Бухарин, Зиновьев, Каменев, Рыков, Цюрупа, Сосновский и Чичерин. Но Народный комиссар по делам национальностей Сталин настоял на том, чтобы не спешить с реализацией проекта, ограничившись для начала созданием комитета по землеустройству евреев во главе со Смидовичем.

Решением ЦИК СССР в августе 1924 г. был образован Комитет по землеустройству еврейских трудящихся (КомЗЕТ). Предполагалось в течение 10 лет переселить в Крым 100 тысяч еврейских семей. В Крымской АССР образовали два национальных еврейских района – Фрайдорфский и Лариндорфский и 32 еврейских национальных сельсовета. Для еврейских переселенцев в 1927 году выделили 115,2 гектаров земли и предоставили немалые льготы. Так начиналось осуществление странного проекта, получившего название «Крымская Калифорния». Странный потому, что в Крым по разрешению Советского правительства уже возвратились из Болгарии и Румынии более 200 тысяч крымских татар, вынужденных в свое время покинуть родину из-за национального гнета, а степные районы были обжиты 50 тысячами немцев. Отторжение части Крыма для переселения евреев могло вызвать серьезную межэтническую напряженность. Это прекрасно понимало руководство Крымской АССР, которое активно сопротивлялось осуществлению проекта. Председатель КрымЦИКа Вели Ибраимов лично разворачивал эшелоны с еврейскими переселенцами. Этого ему не простили, 9 мая 1928 года по приговору большевистского суда он был расстрелян; далее в ходе кампании по разоблачению т.н. «велиибраимовщины» было репрессировано 3,5 тысячи крымскотатарского руководства автономии. Еврейское переселение в Крым продолжилось.

Проект «Крымской Калифорнии» упорно продвигался его разработчиками: членом коллегии Наркомата финансов Ванштейном, заместителем завагитпропом ЦК Диманштейном, членом правления Госбанка Канцельбогеном, наркомом торговли Шейнманом. Наркоминдел Чичерин на встрече в Берлине с еврейскими финансистами подтвердил, что Советское правительство «весьма серьезно



*Калифорния. Сталин, Рузвельт*

относится к «Крымскому проекту». О нескрытом интересе определенных кругов говорит и тот факт, что обсуждение «Крымского проекта» было включено в повестку дня Еврейского конгресса Америки в Филадельфии, на котором присутствовали будущие президенты США Г. Гувер и Ф. Рузвельт, к делегатам которого обратились представители двухсот богатейших семей Америки. Председатель Комитета по землеустройству евреев в СССР Смидович от имени правительства Советского Союза заявил: в обмен на кредиты в СССР будет проводиться колонизация Крыма евреями. На эти цели через «Джойнт» выделялось 15 миллионов долларов.



*Тип еврея-переселенца. Начало 1920-х гг. Калифорния*

Договор о предоставлении займа был подписан 19 февраля 1929 года. По этому строго секретному договору СССР получал в виде займа по 900 тысяч долларов ежегодно в течение десяти лет под 5% годовых. Правительство СССР выпустило и передало организации «Джойнт» облигации на всю сумму займа с процентами (20 миллионов долларов), которые раскупались по подписке среди самых богатых людей Америки. Владельцами облигаций стали, в частности, такие магнаты, как Рокфеллер, Маршалл, Варбург и даже будущие президенты Г. Гувер и Ф. Рузвельт. По условиям договора Советский Союз обязан был завершить выплаты на всю сумму займа с процентами в течение 1954 года.

Сталин предлагал американской стороне заключить новое соглашение о займе до полной реализации «Крымского проекта», но получил отказ. Это стало одной, но не единственной причиной охлаждения к проекту в СССР. В начавшейся кампании по разоблачению «врагов народа» под «сталинскую гребенку» попали и были репрессированы практически все инициаторы и проводники «Крымского проекта». В 1938 году переселение евреев было прекращено, а КомЗЕТ – ликвидирован постановлением ЦК ВКП(б) как «притон для всяких контрреволюционных элементов». Еврейские районы и сельсоветы были упразднены. 7 мая 1934 года взамен несостоявшейся Еврейской автономной республики в Крыму на Дальнем Востоке в составе Хабаровского края была образована Еврейская АО. Однако желающих переселиться на этот край земли среди евреев оказалось очень мало. Там и сейчас их число не превышает 1 процент от общего населения.

Наивно было бы полагать, что у «акционеров» «Крымской Калифорнии» пропал интерес к заманчивому проекту, в который они



***1 – директор АгроДжойнта Розен, 2 – секретарь АгроДжойнта Хаймэн на встрече с еврейскими коммунарами в Крыму, 1928 год***

вложили свои миллионы. Когда В 1943 году в США прибыла делегация советского Еврейского антифашистского комитета во главе с С. Михоэлсом (что должно было продемонстрировать благожелательное отношение к евреям в СССР и повлиять на американские корпорации по ускорению поставок по ленд-лизу), им напомнили о советских долгах.

И «тонко» намекнули, что «Джойнт» при условии возвращения к Крымскому проекту готов не только «простить» 20-миллионный долг, но даже предоставить новый кредит в 10 миллиардов долларов! В феврале 1944 года С. М. Михоэлс, Ш. Эпштейн и И. Фефер направили «Записку о Крыме» с предложением о создании еврейской социалистической республики на территории Крымского полуострова. В условиях тяжелой, разрушительной войны И. Сталин быстро среагировал на эти предложения. 14–15 февраля 1944 г. он подписывает два постановления, касающиеся судьбы Крыма и его коренного народа – «О выселении крымских татар» и «О создании Еврейской Автономной Советской социалистической республики».

Но вскоре на его стол ложится стенограмма заседания учредителей «Джойнта», раздобытый советской разведкой. Там речь шла уже не о еврейской автономии в Крыму, а о создании Еврейской республики как самостоятельного государства, о выставлении требований к СССР вывести Черноморский флот из акватории Черного моря. Крым по планам «Джойнта» должен был стать фешенебельным курортом, способным приносить в год 2 млрд долларов. Это изменило отношение руководства страны к коварному проекту. Сталин, как относительно независимая фигура мировой политики, понимал несостоятельность планов создания Крымской еврейской республики, поэтому не хотел, чтобы его имя фигурировало в этой авантюре. Уже к осени 1945 года Сталин дал понять своим американским партнерам по проекту «Крымская Калифорния», что он потерял к нему интерес. Неоднократные попытки министра торговли США А. Гарримана получить аудиенцию по данному вопросу Сталина оказались безуспешными.



*Обед в семье переселенца. Середина 1920-х гг. Калифорния*



Итоги Второй мировой войны в корне перекроили политическую карту мира. Изменилась и вся геополитическая обстановка. Отношения с преемником Рузвельта Трумэном у Сталина не сложились. В 1948 году в Фултоне Черчилль провозгласил холодную войну против СССР.

США не только не отказались от претензий по займу, заключенному с «Джойнтом» в 1929 году, но и пытались использовать этот договор для оказания давления на советское правительство, поставив условием включения СССР в сферу действия плана Маршалла реализацию «Крымского проекта». В 1947 году решение ООН о создании еврейского государства в Палестине автоматически сняло с повестки дня вопрос о создании Еврейской республики в Крыму. Советское правительство поддержало создание государства Израиль.

Весьма оригинальным способом решился вопрос о выплате Союзом многомиллиардного долга «Джойнту», срок расчетов по которому истекал в 1954 году. Сталина тогда уже не было в живых; СССР, еще не оправившийся после кровопролитной и разрушительной войны, вряд ли смог рассчитаться по облигациям. Ни одна из сторон при этом не хотела огласки причин появления долга, но все могло обернуться громким и нежелательным скандалом.

И тут Н. Хрущев сделал «ход конем»: он уговорил украинское руководство принять Крым «в дар» по случаю 300-летия присоединения Украины к России, решив тем самым вопрос невозвращения долга. Вот и думай сейчас: подарил Никита Сергеевич Крым украинцам или… избавился от Крыма? Крым так и не стал Калифорнией. Однако, по вполне достоверным слухам, его уже пророчат в черноморский Лас-Вегас или Монте-Карло.

*«Мәгъруф» исеме гарәп телендә «шөһрәтле, атаклы, хезмәте белән танылган» дигән мәгънәгә ия. Язмамның герое Зәйнулла улы Мәгъруф Гыйльмияров белән аралашкач, бу кешенең, чыннан да, никадәр җисеме исеменә туры килүен аңладым.*

**Әңгәмәдәш – Миләүшә Газимова.**



# “Тормыш юлымны лаеклы үттем...”

Мәгъруф әфәнде гомеренең 64 елын медицина хезмәтенә, кешеләрнең тәнен һәм җанын дәвалауга багышлаган.

Ул Башкортостан Республикасының Карайдел районында куе урманнар белән капланган биек таулар арасында, Карайдел (русча аны Уфимка дип йөртәләр) елгасы буенда урнашкан ике генә урамлы бик кечкенә Түргәнәй авылында 1934 елның 29 июнендә дөньяга килә.

Җидееллык авыл мәктәбен тәмамлап, Уфадагы медицина училищесына укырга керә. Татар авылында туып-үскәнгә, гел татарча гына сөйләшкән егет үзенең хезмәт юлын Карайдел районындагы Дәвеш авылында фельдшер-акушер вазифасыннан башлап җибәрә һәм киләчәктә медицина өлкәсендә югары уңышларга ирешә!



*Уфа медучилищесын тәмамлаганнан соң. 1954 ел.*

Аннан соң Совет Армиясе сафларында хезмәт итә, Башкортостан дәүләт медицина институтында укый. Кайда гына булса да, үзен төпле белемле табиб, актив гражданлык позициясендә торучы шәхес итеп таныта. Шуңа мединститутның профком рәисе, ә инде Уфада 13нче хастаханәдә невропатолог булып эшләгәннән соң, биредә Калинин районының сәламәтлекне саклау бүлеге мөдире вазифаларын башкара ул.

1962 елда тормыш юллары героебызны Куйбышев шәһәренә китерә. Шушы чорда аңа фельдшер, невролог (невропатолог), психотерапевт, баш табиб (врач) булып эшләргә туры килә.

Үз вакытында Самарның (Куйбышевның) 9нчы хастаханәсендә, Чкалов исемендәге шифаханәдә, 5нче шәһәр поликлиникасында бердәнбер татар баш табибы булуы белән горурлана Мәгъруф абый.

Бүгенге көндә ул «Яхшы хезмәте өчен» медале, «Сәламәтлекне саклау отличнигы» билгесе һәм күпсанлы Мактаунамәләр белән бүләкләнгән югары категорияле табиб-психотерапевт. Аның үзәк һәм җирле матбугатта, төрле медицина журналларында язмалары да басылып чыккан.

Мәгъруф әфәнде бик ачык, гади, аралашучан кеше булып чыкты. Әңгәмәдәшемнең күпкырлы белем иясе булуына, акылына, тормыштагы казанышларына исем китте минем.

Июньдә Мәгъруф ага Гыйльмияровка 80 яшь тулачак. Шушы олуг юбилее һәм Медицина хезмәткәрләре көне алдыннан без аның белән әңгәмә үткәрдек.

***– Мәгъруф әфәнде! Медицинага Сез нинди юллар белән килеп кердегез? Балачак хыялы идеме ул, әллә берәр кеше киңәш бирдеме Сезгә?***

– Дөресен генә әйткәндә, мин кечкенәдән тарих укытучысы булырга хыялландым. Мәктәптә укый башлаганнан бирле халкыбызның ничек, кайдан барлыкка килүе, аның тарихы, ни сәбәпле Уралда төпләнүе белән кызыксынып, бик күп тарихи мәгълүматлар укыдым.



*Уфа медучилищесы студентлары. 1952 ел.*


Туып-үскән җирләрдә. 1999 ел.


Бертуганнар белән кече ватанда очрашу.

Бөек Ватан сугышыннан соң Каюм Насыйриның «Әбүгалисина» («Авиценна») дигән әсәре дөнья күрде. Без, дустым Мөгаллим белән, аны укып чыккач, медицина белән кызыксынып киттек. Шулай итеп, мин табиб булырга карар кылдым. Шулай ук авылыбыздагы фельдшер Мансур абый Садыйковның фидакарь хезмәтенә сокланып, кешеләрнең аның ярдәменә никадәр мохтаҗ булуларын, аны хөрмәт итүләрен күреп, аңарга охшарга тырышуым да зур роль уйнады, дип уйлыйм.

***– Хезмәтегездә ниләр хәтерегездә уелып калды?***

– Авылыбызда махсус урта уку йортын тәмамлаган, югары медицина уку йорты дипломын алган беренче кеше булдым. Мин моның белән дә горурланам.

19 яшемдә Дәвеш авылында фельдшер-акушер булып эшли башлагач, бер ай эчендә җиде хатын-кызга бала табарга ярдәм иттем. Менә шушы хәл исемдә калган. (Дәвештә мин дөньяга килергә булышкан шул балаларның алдагы язмышлары ничек булганын күрәсем килә).

1968 елда Куйбышев шәһәренең ташландык хәлдәге 9 нчы хастаханәсенең баш табибы булып эшли башладым һәм аны югары дәрәҗәгә җиткерер өчен бар көчемне куйдым.

Шулай ук, беренчеләрдән булып, инсульт, инфаркт суккан авыруларны реабилитацияләү белән шөгыльләнә башладым. 1978 елда Чкалов исемендәге шифаханәнең баш табибы буларак (Советлар Союзында икенчеләрдән булып!), бирердә инфаркт кичергән авыруларны дәвалау (реабилитацияләү) бүлеген ачтым.

Тагын хәтергә уелып калган хәлләрдән шуны әйтә алам: шәһәребездә беренчеләрдән булып, 5 нче район поликлиникасында психотерапия кабинетын ачтым һәм монда 25 елдан артык хезмәт иттем. Кызганыч ки, 2000 елларда бөтен Россиядәге поликлиникаларда мондый профильле кабинетларны яптылар. (Шуңа бу төр ярдәмгә мохтаҗ булган кешеләргә психотерапевт ярдәмен хәзер психодиспансерда яисә зур хастаханәләрдә генә алырга мөмкин). Шуннан мин «Волга» хәрби шифаханәдә психотерапевт булып эшкә урнаштым. Хәзерге вакытта мин эшләгән психотерапевтик кабинет шәһәребездә иң яхшы кабинетлардан санала.

***– Атаклы шәхес булыр өчен кеше нинди сыйфатларга ия булырга тиеш?***

– Тырыш, үз Ватанын яратырга, актив тормыш позициясендә торырга, мәрхәмәтле, гадел, шәфкатьле булырга тиеш, дип саныйм.

***– Тормыш иптәшегезнең кайсы сыйфатларына сокланып яшисез?***

– Хатыным Нурзидә – акыллы, чибәр, талантлы, аралашучан, күпкырлы белем иясе. Ул татар халык авыз иҗатын, татар әдәбиятын, татар халкының тарихын тирәнтен белә. Бик күп татар җырларын моңлы итеп җырларга ярата. Мин аңа сокланып яшим.

***– Гаиләдә ыгы-зыгы килеп чыкканда кем алдан юл куя?***

– Гадәттә, андый бәхәсле чакларда мин дәшмичә торам. Шуннан соң бу бәхәс үзеннән–үзе юкка чыга. Тик, дөресен әйткәндә, бу бары тик бәхәсле хәлләр барлыкка килгәндә генә, чөнки безнең бер дә сүзгә килгәнебез юк, Аллага шөкер!

***– Тормышта кемнән үрнәк алып яшисез?***

– Минем өчен һәрвакыт әле 1860 елда туган карт атаем – Гыйльмияр бабам үрнәк. Кая барса да, ул мине үзеннән бер дә калдырмыйча, ияртеп йөртә иде. Карт атаем бик хәрәкәтчән, тырыш, уңган кеше иде. Минем аның бер генә минут та эшсез, тик утырганын күргәнем булмады. Йорттагы төрле физик эшләрне башкарганда ул миңа үзенең тормышы, гомумән, шул чорларда татар халкының үткәндәге авыр тормышы турында күп нәрсәләр сөйли иде.

Аның авылдашлары арасында да дәрәҗәсе зур булган, шуңа алар аны авыл старостасы итеп тә сайлаганнар.

Үз авылларында җир аз булганга күрә, ул күрше рус авылларында яшәүчеләрнең җирләрен арендага алып, анда арыш, бодай үстергән. Гомер буе Гыйльмияр бабам умарталар тотты, яздан көзгә чаклы елгада саллар агызды. Бу соңгы эше аны хәтта үлемнән дә коткарып калган. Шулай бервакыт 1919 елда үзенең тырышлыгы, булдыклылыгы, үз хезмәте аркасында материаль яктан нык яшәгән бабамнан көнләшкән авылдашлары: «Ул – халык дошманы, кулак, аны атарга кирәк», – дип, аның өстеннән волостька шикаять (жалоба) язганнар. Шуңа карт атайны кулга алалар һәм волостька атарга алып киләләр. Атар алдыннан бу


Чкалов исемендәге шифаханәнең баш табибы. 1974 ел.


«Волга» хәрби шифаханәдә эш урынында.


Мәгъруф әфәнде хатыны Нурзидә Фәйзуллина белән.

турыдагы карарга комиссар кул куярга тиеш була. Ул исемлектә аңа таныш булган Гыйльмияр Ардуанов фамилиясен күргәч, бу кешене үз янына алып килергә куша. Каршында басып торучы бабамны күргәч, комиссар шакката. Бу бит ничәмә еллар аның белән бергә сал агызучы хезмәттәше – Гыйльмияр була!

«Нинди халык дошманы, кулак булсын ул! Мин аны атарга рөхсәт бирмим!» – дип ачулана ул. Шулай итеп, минем Гыйльмияр бабам исән калган.

Ә ничек матур, моңлы итеп җырлый иде ул! Исләрең китәр! Карт атай җырлаганда, бөтен авыл халкы эшләрен ташлап, аны тыңлый торган булган.

Мине тышкы кыяфәтем белән дә, холкым белән дә бабама охшаган, диләр. Тик менә Аллаһы тәгалә моң гына бирмәгән үземә.

***– Татар җыр сәнгатендә кемнәргә мөккибән Сез?***

– Мин кечкенәдән авылда тальян моңын тыңлап үстем. Карт атаем бик матур җырлый иде, абый-апаларым да – моңлы кешеләр. Араларында оста гармунчылар да юк түгел. Шулай итеп, мин һәрвакыт татар моңына, татар музыкасына төренеп яшәдем. Авылымның биек таулары, Карайдел елгасы, гомумән, туган якның искиткеч матур табигате дә моңлы җырларга илһамландыра иде мине.

Бигрәк тә Илһам Шакировның җырлавын яратам. 1958 елда армиядән кайтып, инде Уфада мединститутта укыганда, мин аның җырлавын беренче тапкыр радиодан ишеттем. Шуннан бирле мин – аның иҗатына гашыйк кеше.

Шулай ук хәзерге җырчылардан Флера Сөләймановaның, Зөһрә Сәхабиеваның җырлауларын яратып тыңлыйм. Яшь башкаручылардан Филүс Каһиров, Ришат Төхвәтуллин исемнәрен атап үтәсем килә. Алар барысы да татар җырларын моңлы итеп башкаралар. Безгә иң мөһиме моң бит.

***– Соңгы биш елда укыган китапларыгыз нинди?***

– Мин көн дә укыйм. Хәзер мине күбрәк тарихи, сәяси материаллар кызыксындыра. Татар һәм урыс телендә басылган бик күп гәҗитләрне укып барам. Интернетта татарча басылган мәкаләләрне дә укырга вакыт табам.

Чыңгыз Айтматовның, Мостай Кәримнең әсәрләрен яратам. (Соңгысы белән мин хәтта якыннан таныш та идем.)

Уфада укыганда мин еш кына «Кызыл таң», «Кызыл Башкортстан» гәҗитләре редакцияләренә дә барып йөрдем.

Туфан Миңнуллинның әсәрләрен, Дамир Исхаковның, М.Зәкиевнең татар халкының тарихы турындагы материалларын, тарихи әсәрләрен яратып укыйм. Гомумән, кечкенә чагымнан китап укырга яраттым мин. Балачакта авылыбыз һәм мәктәп китапханәсендә булган бөтен китапларны укып чыктым.

Әле 5 нче сыйныфта белем алганда ук мин инде үзлегемнән «дарвинизм теориясе»н, Отто Шмидтның «Кояш системасы»н үзләштердем.

Шул уңайдан бер кызыклы хәлне искә төшерәсем килә. 1947 елда Башкортостанда «ахырзаман була икән», дигән шомлы хәбәр таралды. Ул, әлбәттә, безнең авылга да килеп җитте. Шуннан мин, 5 нче сыйныфта укучы малай, укып чыккан материаллар нигезендә доклад әзерләдем һәм авыл клубында халык алдында чыгыш ясадым.

«Ахырзаман булырга тиеш түгел! Бу хәл галәмдә кояш сүнгәч кенә булырга мөмкин. Ә шул вакытка кадәр галимнәребез кояш урынына башка бирер яктылык һәм җылылык чыганагы уйлап табачаклар. Шуңа күрә тормыш әле дәвам итәчәк», – дидем мин.

***– Тормышта Сез акыллыларгамы яисә матурларгамы өстенлек бирәсез?***

– Акыллы кеше һәрвакыт матур була ул. Аның йөзеннән нур балкый.

***– Яшь чагыгызда «бәхет» төшенчәсен ничек күз алдына китерә идегез һәм, олыгайгач, ул «бизмән» үзгәрдеме?***

– Мин – коммунистик тәрбия алган кеше. Безне дәүләткә, гаиләгә файдалы булырга, актив тормыш позициясендә торырга, якыннарыңа ярдәм итәргә өйрәттеләр. Шушы сыйфатларга ия булу минем өчен зур бәхет иде. Мин үземне һәрвакыт бәхетле кеше итеп хис иттем.

Еллар үтү белән дә минем бу карашларым үзгәрмәде. Мин бүгенге көндә бик бәхетле, чөнки үземне пациентларыма, минем психологик ярдәмемә мохтаҗ булганнарга, хатыныма, туганнарыма, якыннарыма кирәкле кеше итеп хис итәм. Гомумән, мин үз тормышым белән бик канәгать, чөнки тормыш юлымны лаеклы үттем, дип саныйм.



# ДӘҮЛӘТКОЛЫМ — газиз туган җирем

*Бөек Тукаебыз язып калдырган шушы шигъри юлларны укыгач, һәрберебезнең туып-үскән авылына карата тирән ихтирамы, чиксез яратуы, зур хөрмәте кузгала.*

*Нурсинә ХӘКИМОВА,*
*Денис авылы, Шенталы районы*

Бер танышым: “Озакламый татар авыллары бетә инде”, – дип әйтергә ярата. Ә мин аның белән тирән бәхәскә керми генә: “Җир йөзендә татар халкы бетмәгән кебек, аның авылы да беркайчан да бетмәячәк, яшәячәк әле ул!” - дип җавап бирәм.

Хәзерге язмам нәкъ менә шушы тарихи, замана үзгәрешләренә карамастан, һаман да яшәп килүче татар авылларының берсе – Камышлы районындагы Дәүләткол авылы турында булыр.

Шушы авылга барып кергәндә, һәр юлаучының игътибарын авылдан чит җирләргә чыгып киткәндә, үз фатихасын биреп, озатып калучы газиз әнкәйләрне искә төшергәндәй

“Сагындыра туган як,

Исән йөреп, имин кайт!” - дип колга башындагы язма җәлеп итә. Ә авыл исә җәннәт почмагында урнашкандай, кап-кара шомырты, кып-кызыл өлгергән баланы, чикләвеге, хуш исле мәтрүшкәсе, бөтнеге, салкын кышларда мунчада рәхәтләнеп чабынып, тәнеңә генә түгел, җаныңа да шифа алырлык себеркеләр әзерләрлек данлыклы агачлары, кышларын кояш нурында күз чагылырлык ап-ак кар өстендә эз калдырып үткән, киекләргә бай булган куе урман белән әйләндереп алынган. Ул түбәсеннән челтерәп агып төшкән салкын, шифалы сулы чишмәләр җырын яңгыратучы биек тауларга сыенып утыра.

Хәзер язылачак төп сүзем: авыл тарихы, аның кабатланмас бөек шәхесләре турында булыр.

1919 елда Камышлы авылында зур янгын чыга. Сәбәбе: биредәге өйләрнең, каралты-кураларның артык якын итеп төзелүендә була. Янгыннар еш булып торгач, йортсыз-җирсез калган кешеләр башка җиргә күчеп, авыл булып оешып, яшәүне хуплаганнар. Менә шундый зур җыелыштан соң, Әбугали Шәвәлиев Самар шәһәренә барып, рөхсәт кәгазе алып кайта. Аннан соң көзен өлкәннәр яңа авыл урынына килеп, Камышлы елгасы буенда, казан асып, аш пешерәләр һәм намаз, “Коръән” укып, биредә яшәргә Аллаһыдан хәерле, бәрәкәтле, мул тормыш сорап, дога кылалар.

Менә шулай итеп, яңа авылга җир бүлеп бирелгәч, бирегә 23 хуҗалык килеп, беренче нигез ташын сала. Аннан соң тагын башка кешеләр күчеп килеп, тормыш корып җибәрәләр һәм яңа җирдә яшәү дәвам итә. Авылга “Дәүләткол” дигән исем бирелә. Аңа шушы исемне бирү бигрәк кызык. Мәрьям апа Шәвәлиева сөйләвенә караганда, Дәүләткол “колагында” (арткы ягында) икмәк бик уңа торган булган. Шуңа күрә шушы җир кишәрлеген бай, дәүләтле “колак”, дигәннәр. Шуннан чыгып, авылга Дәүләткол, дип исем биргәннәр булып чыга.



*Мөдәррис ага Гыйззәтов – Камышлы авылы халык театрының һәвәскәр артисты*

Ә Камышлы авылында яшәүче өлкәннәр исә болай дип аңлата: Камышлы авылындагы нык тормышлы бер ир кеше - Дәүләт - озак еллар шушында җир биләгән булган. Дәүләнең улы Мөхәммәт, аның улы Абзалетдин, аннан соң нәсел чылбырын дәвам итүчеләр Исламнур, Әбүзәр, соңгысы – Әхсән исемле кеше бүгенге көндә Дәүләтов фамилиясен йөртә. Менә шушы Дәүләт бабай исеме авылга бирелгән, дип фаразлаучылар да бар.

Яңа авылда нигез корып яши башлаган халык Камышлыда гомер иткәндә ут казасыннан зур бәла-каза күреп яшәгәнлектән, биредә өр-яңа өйләр төзеп, каралты-кура яңартып, тынычлыкта, рәхәтләнеп яши башлыйлар. Авыл халкы үз көче белән бура

бурап, өч ел эчендә мәчет төзи. Тарихи чыганаклар ярдәмендә бирелә кемнәр акчалата, кемнәр терлек, күпмедер пот ашлык биреп, шушы изге, саваплы эштә ярдәм итүчеләрнең исемнәрен әле дә барлап була. Соңрак Әбделгазиз Гарифов яшьләргә дин сабагы укыта башлый. Тик, кызганычка, шушы рәхәт тормыш бик озакка бармый шул. 1921 елның язы Идел буенда яшәгән татар авылларына бик зур корылык алып килә. Билгеле, ул Дәүләткол авылын да читләтеп үтми. Яз айларыннан алып, көзге айларга кадәр ник бер тамчы яңгыр тамсын! Әгәр дә башыңны югары күтәреп, кояшка карасаң, аның рәхимсез кыздыруына хәлең китеп егылырдай буласың. Чәчкән иген кыры, аяк астындагы яшел чирәм, алай гынамы соң әле, Дәүләткол авылының куе урманнары саргаеп кибеп китә! Тик чокыр-чакыр, сулы, уйсу җирләр генә яшелләнеп тора. Башка терлекләр белән беррәттән, авылда эт, мәче ише хайваннар калмый, ашалып бетә. Ачлыктан интеккән кешеләр, бигрәк тә сабый балалар, урманга ташланалар. Алар анда төрле үләннәр, аларның тамырларын казып алып ашарга керешәләр. Өлгергәнрәкләре кышлыкка киптереп кую җаен да таба. Ә кайберәүләр тәрәзәләренә аркылы-торкылы такта кадаклап, гаиләләре белән, аркаларына биштәр асып, ризыклы урын эзләп, Урал артына, Себергә һәм башка җирләргә чыгып китәргә мәҗбүр булалар. Авылда кышкы айларда салкыннан өшеп, ачлыкка түзә алмый, интегеп үлгән кешеләр дә булгалый.

Кешелек дөньясы шушы авыр вакытларны үтеп, янә тарих белән бергә алга атлый. Аллаһының рәхмәте димә инде, икенче елның язы матур табигате белән кошлар моңына күмелеп килә. Ул елны вакытында шифалы яңгырлар явып, басудагы алтынсу иген кыры ат дугасы биеклегендә үсеп, талгын җилдә тибрәнеп, кояш җылысында башак туплый. Ә үткән авыр елда атсыз калган кешеләр уңыш үстереп алу шатлыгыннан мәхрүм булсалар да, аптырап калмыйлар, урак өстендә Богырыслан якларына китеп, үз утарында хуҗа булып, тормыш алып баручы, Пилюгин фамилияле бояргa ярдәм итеп, күп кенә икмәк алып кайталар. Озакламый НЭП планының тормышка ашуы да кешеләргә яхшылык алып килә. Базарларда ризык, кием-салым барлыкка килә. Хәтта авылда Зәкиулла Галимуллин кибет ачып җибәрә. Акчалары булмаганнар читкә китеп, акча эшләп кайтырга мәҗбүр булалар. Аннан соң үзләренә кирәк-яракларны юнәтәләр.

Авылда элекке татарча алфавит нигезендә яңача укыту башлана.

Ә 1928 елда бирелә кооператив оешма барлыкка килә. Анда сатучы булып Әбделгазиз Гарипов эшли башлый. Аннан соң авылда 16 хуҗалыктан торган ярлылар комитеты төзелә. Алар авыл халкы арасында колхозга керү турында агитация эшләре алып бара башлыйлар. Менә алар кемнәр: Әбделгазиз Гарифов, Нигъмәтулла Сафиуллин, Абдулла Гәрәев, Нурулла Галимуллин, Дәүләтша Фарукшин, Мөхәммәтвәли Хуҗиев, Мәгърүфә Җәләева, Мәсрүрә Бәдретдинова һәм башкалар. Һәрхәлдә, тормышның мондый юнәлеш алуы беркемгә дә ошамый. Ә районнан һәм югары органнардан басым ясау дәвам итә. Нәтиҗәдә, Дәүләткол авылында яшәүче урта хәлле крестьяннар "кулак" дип аталган исемлеккә теркәләләр. Әбүнәгыйм Шәймәрдәнов, Фәләхетдин Рәфәгыйтдинов, Нәбиулла Әһлиуллин, Харис Сафуанов, Зәки Зыятдинов, Ибраһим Юнысов, Хәлим Шәвәлиев һәм башка кешеләр авыр язмыш сынавына дучар булалар. Бичаралар үз куллары белән эшләп, төзегән йортларыннан бер әйберсез урамга куалап чыгарылалар. Әрнүләре берничә нәселгә җитәрлек шушы кешеләрне тарих соңрак аклый. Бераз алга китеп әйтәм, бик күп еллар үткәч, монысы да аңлашылды: димәк, озак елларга сузылган Сталинның һәм аның булышчыларының бер гөнаһсыз кешеләргә нәхак бәлаләр тагып, талау, гаделсезлек күрсәтеп, төрмәләргә ябып кую рәвешендә, илебездәге булачак репрессияләү галәмәте шушы елларда ук баш калкыткан булган инде. Әлбәттә, шундый каты, шәфкатьсез чаралар кумәкләштерүне тизләтә. "Кызыл көч" колхозының беренче җитәкчесе итеп авылның акыллы, тапкыр кешесе – Мөхәммәтвәли Хуҗиев сайлап куела. Аның тырышып эшләве игътибарсыз калмый, районда һәм өлкәбездә генә түгел, яхшы җитәкче буларак, даны башкалабыз Мәскәүдә дә билгеле була. 1935 елда аңа



*Рәфис Гыйззәтов үзе ясаган машина белән җир эшкәртә*



*Авыл мәчете һәм аның каршысында Бөек Ватан сугышында һәлак булган авылдашлар хөрмәтенә куелган һәйкәл*

колхозчы Шәһидә Гарипова белән бергәләп Мәскәүдә үткәрелгән Икенче Бөтенсоюз колхозчы ударниклар съездында катнашу бәхете насыйп була.

Менә шулай итеп, әкрен генә авылда тормыш, яшәү шартлары җайлана. Бирегә 4 еллык мәктәп (соңрак ул 7 еллыкка әверелдерелә), медпункт, Мәдәният йорты салына. Китапханә ачыла, радио кертелә. Терлекчелек, кошчылык фермасы, умартачылык шөгыле барлыкка килә. Алма бакчасы үстерелә. Соңрак колхозчыларга хезмәт хакы түләнә, иң яхшы эшче дип табылганнарына премиягә ашлык, бозау, сарык бирелә башлый.

Әйе шул. Яңа системага күнеп, ияләшкән дәүләтколлылар хәзер инде заманнан артта калырга тырышмагандай, авыл китапханәсеннән төрле китаплар яздырып алып, ял вакытларында төрле әсәрләр укып, бәйрәм көннәрендә Мәдәният йортында үзешчән сәнгать осталары тарафыннан куелган спектакльләр, концертлар карап, тормышның ямен-тәмен тоеп яши башлыйлар. Бигрәк тә укытучылар коллективына зур көч куярга туры килә: алар бер чарадан читтә калмыйлар, мәктәптә балаларга белем бирү өстендә генә утырмыйлар, язгы чәчү, урып-җыю эшләре вакытында басуларга барып, укучылары белән махсус концерт программалары күрсәтәләр. Агитация эшләре алып баралар.

Наилә Насыйрова, Кәшиф Мансуров, Мирза Сәгыйров, Зифа Хәсиәтуллина, Заһит Каюмов, Әфидә Сафиуллина, Зәйнәп Әһлиуллина, Мәдинә Шатдинова, Сәхия Шәвәлиеваларның укытучылык хезмәтләре төрле елларга туры килсә дә, аларның даны, хезмәтләренә күңел биреп, тырышып эшләүләре бүгенге көндә дә онытылмый, авыл кешеләре күңелендә тарихи ядкәр булып саклана бирә.

Тагын шуны әйтеп үтәсем килә. Колхозда "Ударник", "Алга", "Колхоз таяны" кебек газеталар колхоз тормышын, уңган эшчеләрне мактап яки тәнкыйтъ утында тотып язылган мәкаләләре белән мактаулы урында тора. Бик күп еллар үтеп китсә дә, шушы авылда туып-үскән, мәктәптә җиденче сыйныфта укыганда, хәзерге көндә Самар өлкәсендә нәшер ителүче "Бердәмлек" газетасының баш мөхәррире Рәфкать Нәбиулла улы Әһлиуллин тарафыннан язылган шигъри юллар әле дә сакланган:

"Тынгысыз карт колхозчы".
Битләргә ал төс кертә,
Үзәкне өзә салкын.
Җиһан әби ике күзләп
Көтә тынгысыз картын.
Изрәп китте (картлык инде),
Суына аш, дип уфырды.
Әнә, соң гына булса да,
Карты кайтты, ахыры.
Җиһан әби биеп йөри,
Йокысы инде качты.
Җырлап торган ак самовар
Өстәлгә менеп басты.
Куелды кәрәздәй коймак,
Шулай ук чиста бал да.
Әби шунда иплән кенә
Картын да әрләп алды:
- Яшь кеше җитмешне куа,
Ял да итми бит хәтта.
Җибәрмим бүтән, боерса,
Алай эшләми ат та!
– Тукта әле, карчык, тукта!
Бу бит җиңел каравың,
Бәхет ул колхозда эшләү,
Әлегә исән, арымабыз.



*Фәрит Гыйләҗев улы Фирдәүс белән*

Минем эшем яхшы карчык,
Илгә дуңгыз симертәм,
Янымдагы яшьләрне дә
Намуслы эшкә өйрәтәм.
Битләргә ал төс кертә,
Үзәкне өзә салкын.
Җиһан әби, горурланып,
Көтә колхозчы картын!

Авыл халкы яңача яшәү системасына җайлашып, хәзер инде рәхәтләнеп яшәрбез, дип уйлый башлаган вакытта ил өстенә ачы сугыш хәсрәте килеп баса. Көтмәгәндә илебез халкының тынычлыгын бозып, чикне җимереп, фашист илбасарлары бәреп кергәч, Дәүләткол авылының ватанпәрвәр ир-егетләре яуга күтәрелә. Алар белән беррәттән ир йөрәкле хатын-кызлар да фронтка китеп баралар. Минсәһвәһ Гарифуллина Мәскәүдә НКВД частенда, Закирә Шатдинова белән Минҗиһан Сафина – зенитчылар булып хезмәт итәләр. Шушы кешеләр сугышка киткәч, авыл өстенә кара пәрдә япкандай, ул боегып, сагышка батып калгандай тоела. Авылда әби-бабайлар, хатын-кызлар, көчләре көчкә җереп бетмәгән, буй җитеп килүче яшүсмерләр генә кала. Күп кенә хатын-кызларны окоп казырга, урман кисәргә озаткач, хәлләр тагын да мөшкелләнә төшә. Берничә ел барган сугышны икмәк белән тәэмин итәр өчен авыл халкы "Барысы да - Бөек Җиңү өчен", дип аталган лозунг астында көнне төнгә ялгап хезмәт итә башлый. Камилә Бәдретдинова, Гыйльменур Әһлиуллина, Разыя Хәйбрахманова, Миңнур Сәгыйдуллина, Хәдичә Вафина, Гыйшкия Шәвәлиева кебек хатын-кызларга һәйкәл куярлык. Ә хәзер шундый сорау туа: ул вакытта кемгә генә ансат булды икән соң?! Шушы авырлыкларга түзә-түзә яшүсмер балалар күзгә күренеп


*Дәүләткол авылы мәдәният йорты*



*Дәүләткол зиратында өмә көне*

олыгаялар, аларның матур, гамьсез, шатлыклы яшьлек еллары, җиткән кызларның тормыш корып, үз тиңнәре белән яратышып, сабыйлар тудырып үстерер чаклары сугыш сөреме эчендә югалып кала. Немец илбасарларының кылган җинаятьләреннән, күрсәткән явызлыкларыннан кешеләрнең тән ярасы гына түгел, җан ярасы төзәлер өчен генә дә күпме вакыт кирәк булгандыр?!!

Ниһаять, кешелек дөньясына зур сынаулар китергән сугыш тәмамланып, Бөек Җиңү көне килеп җитә. Дәүләткол авылыннан киткән 77 кеше арасыннан, ялгышмасам, 42 се фронт кырларында ятып кала. Ә хәзер фронт юлларын тулысынча үткән Газизнур Шәкүров турында шуны искәртеп үтәсем килә. Ул гади солдаттан гвардия капитаны дәрәҗәсенә тикле күтәрелә. Сугышта күрсәткән батырлыклары өчен "Кызыл Йолдыз", "Кызыл Байрак", "Бөек Ватан сугышы" орденнары һәм медальләр белән бүләкләнгән. Ул авылга кайткач, икмәк үстерү фронтында да озак еллар тырыш хезмәт куя.

Алда язылып үткән сүзләремә килгәндә, фронттан исән кайтучы кешеләр икенче көнне үк колхозга эшкә чыгалар. Чөнки икмәк саклагыч амбар-келәтләр бушап, хуҗалыкта "уф" дип өрсәң, егылып китәрлек, аякларында көч-хәл белән басып торган арык атлар гына калган. Ирләр кулы тимәгән каралты-кура череп, бер якка янтая башлаган. Мескен карт-корылар, гөнаһсыз (күбесе ятим) сабыйлар ач –ялангач. Менә боларны күреп торган кеше рәхәтләнеп ял итә алмый шул инде. Аерым алганда, биш бала анасы Рәисә Фарукшинаның хезмәт җимешләренә сокланмый мөмкин түгел. Ул Бөек Ватан сугышы елларында гына түгел, ул тәмамлангач та әле хәләл җефете белән тракторда эшләвен дәвам итә.



*Ленинград блокадасын кичергән Зөлкагыйдә апа*

Берничә елларга сузылган, авырлык белән башкарылган хезмәтләр дәүләтколлыларны янә яшәүгә, тормышка алып килә. "Кызыл көч" колхозының, авыл кешеләренең хәлен экономик яктан баета. Озакламый яңа өй салып, өйләнешүче яшьләр, бәби туйлары белән башка бәйрәмнәрдә үзара кунакка йөрешүләр, Мәдәният йортында төрле кичәләр үткәреп, телгән хезмәт белән шөгыльләнеп яшәгән тормышлы, аягында нык басып торган хуҗалыкны 1950 ел азагында Камышлы авылындагы "Яңа тормыш" колхозына китереп кушалар. Аннан соң ул "Мир" колхозына әйләндерелеп,



*Сугыш һәм хезмәт ветераны Ризаэтдин бабай*

актыктан бөтенләй таркалып юк куя. Кызганычка, шушы елларда башланган, хәзерге көндә дә дәвам иткән оптимальләштерүнең тискәре җилләре, мәсәлән, язучы, Татарстанның халык шагыйре, Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Рөстәм Мингалимне, заманында Мәскәүдә үткәрелгән 19 съездда делегат буларак катнашып, Ленин орденына лаек дип табылган, авыл хуҗалыгында озак еллар колхоз рәисе булып хезмәт иткән Нәгыйм Абдулловларны җир йөзенә бүләк иткән Камышлы районындагы Йолдыз авылы бөтенләй юкка чыккан. Менә шулай итеп, татар авыллары күзгә күренеп таркалып барган вакытта Дәүләткол авылы кешеләре куркуга калган булсалар, соңрак авыл өчен яңа дәвер башлана. Хәзер сүзем аның бүгенге хәле, тормышы турында булачак.

Юк, үлми әле, Дәүләткол авылы! Картадан да сызып ташланмый. Чөнки моның өчен аны саклап калучы, ватанпәрвәр йөрәкле, авыл өчен җанын фида кылырга әзер булучы авыл кешеләре бар. Бүгенге көндә авылда барлыгы 50дән артык йорт хуҗалыгы бар. Биредә 200гә якын кеше яши. Унбиштән артык яшь гаилә сабыйлар тудырып, үстереп тәрбияли. Авыл халкы күп итеп терлек асрый, яшелчә, җиләк-җимеш үстерә. Үзләреннән артып калганын базарга сатуга чыгара. Умартачылык белән шөгыльләнә. Ямьле җәй көннәрендә урман җиләген, баланын, гөмбәсен җыеп, шуны сатып, акча эшләүчеләре дә бар. Иренмә генә, авыл табигате бик бай. Ул ашата да, яшәтә дә.

Тагын шуны әйтеп үтәсем килә. Берничә еллар элек Камышлы районы администрациясендә җитәкче булып эшләгән Сәҗит ага Галимуллинга авыл халкы әле дә рәхмәт укый. Чөнки аның тырышлыгы белән Дәүләткол авылына асфальт юл салынган, газ үткәрелгән.

Табигать язгы, яшелләнеп килүче гүзәллеккә төренеп утырган бер көндә мин шушы авылның уңган-булган кешеләре белән очрашу өчен, иртән-иртүк юлга кузгалдым. Дәүләткол авылына барып җитәргә берникадәр ара калгач, минем игътибарымны зиратлар өстендә мәш килеп эшләп йөрүче кешеләр җәлеп итте. Соңыннан ишетеп, аңлавымча биредә өмә үткәрелгән икән. Бихисап күп кешеләр бирегә килеп (хәтта читтә яшәүчеләр дә), якыннарының



*Фәнис Гыйззәтов үз куллары белән ясаган әйберләре янында*

каберләрен зыярәт кылып, чистартып, корыган агачларны кисеп, тирә-якны чүп-чардан арындырганнар. Бу матур күренеш дәүләтколлыларның ата-бабаларына, якыннарына һәм башка әрвахларга карата зур ихтирамын, игътибарын чагылдырып кына калмый, аларның мәңгелек тормышка булган мөнәсәбәтләрен дә тасвирлый сыман тоелды миңа. Өстәп шуны әйтәсе килә: ул көнне зират тирәли 120 данә нарат агачлары да утыртылган икән.

Самар белән Саранск шәһәрләре арасы 300 километрга сузыла. Тик аралар ерак булса да, без Вәли белән бүгенге көнгә кадәр дус булып, аралашып яшибез. Менә аңардан тагын бер хат килеп төште әле.

Вәли хатыны Сара белән ике малай тәрбияләп үстерделәр. Егетләр, әтиләре эзеннән китеп, үз тормышларын Россиянең иминлеген саклау белән бәйләделәр.





Сәхаб Урайский:

*Камалетдин углы Сәхаб Урайский 1907 елда Ульяновск өлкәсенең Татар Урайкино авылында туа. Мәктәптә җиде ел укыганнан соң, ул Куйбышев татар-башкорт педагогия техникумына укырга керә.*

*Тырышып укыган егет шигырьләр иҗат итә. Аның беренче шигыре Мәскәүдә нәшер ителә торган «Игенчеләр» гәҗитәсендә басылып чыга. Куйбышевта, Казанда басылган гәҗитә-журналлар редакцияләре белән дә тыгыз элемтәдә тора шагыйрь.*

*30нчы елларда Сәхаб Казан педагогия институтында белем ала. Аннары «Яшь сталинчы» гәҗитәсендә эшли.*

*1941 – 1945 елларда Урайский Совет Армиясе һәм Эчке эшләр министрлыгында хезмәт итә. Яхшы хезмәте өчен ул медальләр белән бүләкләнә.*

*1933 – 1956 еллар эчендә Сәхаб Урайскиның 14 китабы дөнья күрә.*

*Аның берничә шигырен укучыларыбызга тәкъдим итәбез.*

Материалны Минзакир НУРЕТДИНОВ әзерләде

# «ҖЫРЛАРЫМ ХАЛЫК КҮҢЕЛЕНӘ ЯКТЫ НУР СИПСЕН ИДЕ...»

## Мөмкин түгел

*Поезд ыргый, аксыл төтеннәрен*
*Иркен басуларга таратып.*
*Мин ашкынып тәрәзәгә карыйм,*
*Сабыйлыгым шунда күмелеп калган*
*Кырларымны сөеп-яратып.*

*Ильич туган бу мөкатдәс яклар –*
*Туган ягым алар минем дә.*
*Шул кырларда шигъри хисләр үсте,*
*Көтү көтеп балачагым үтте*
*Киң тугайлы Идел җирендә.*

*Сабый чакның күпме хатирәсе*
*Күмелеп калган шушы кырларга.*
*Шул кырларга булган мәхәббәтне,*
*Туган җиргә булган зур хөрмәтне*
*Мөмкинме соң сыйдыру җырларга?!*

*Әй, туган ил, синең туфрагыңның*
*Һәр бөртеге, һәрбер тузаны*
*Шундый якын тоела күңелгә.*
*Мөмкинме соң шушы изге җирне*
*Килмешәкләр кулына бирергә?!*

*Юк, юк!*
*Без ант иттек туган илебезнең*
*Тик бер генә карыш җирен дә*
*Бирмәбез дип ятлар кулына,*
*Җимерелмәс корыч стенадай*
*Каршы төшик дошман юлына.*

*Халкыбызны кол итәргә килгән*
*Дошман бәрелеп шушы кыяга,*
*Таш маңгаен ярсын безнең илдә,*
*Тузан булып көле очсын билгә,*
*Без китерик яшәү дөньяга!*

*Поезд ыргый сугыш барган якка,*
*Төтеннәрен җилгә таратып,*
*Мин ашкынып тәрәзәдән карыйм,*
*Сабыйлыгым шунда күмелеп калган*
*Кырларымны тиңсез яратып.*

*Әй, туган ил, синең туфрагыңның*
*Һәр бөртеге, һәрбер тузаны*
*Шундый якын тоела күңелгә,*
*Мөмкинме соң шушы изге җирне*
*Талаучылар кулына бирергә?!*

## Теләк

*Алсу таң ата ерактa,*
*Алтын нурларын сибеп.*
*Сандугач сайрый куакта,*
*Шатлык иртәсен сизеп.*

*Таң куа төннең карасын,*
*Таң бирә көнгә урын,*
*Шулчак җыр җилпи канатын,*
*Каршылап таңның нурын.*

*Җырларым халык күңеленә*
*Якты нур сипсен иде,*
*Һәр юлы туган илемә*
*Файдага китсен иде.*

*Алсу таңнарның җырымда*
*Нуры чагылсын иде,*
*Һәр сүзендә, һәр юлында*
*Яшәү табылсын иде.*

*Җырларым илем күгендә*
*Бер йолдыз иде,*
*Сүнмичә көндез, кичен дә,*
*Гел янып торсын иде!*

## Син кайтмыйсың

*Бакчадагы гөлләр чәчәк атты*
*Тормышыбыз кебек ямьләнеп,*
*Урман күлләренә аккош кайтты,*
*Сандугачлар килде әйләнеп.*

*Сандугачлар килде, аккош кайтты,*
*Син кайтмадың киткән җиреңнән,*
*Аккош китәр урман күлләреннән,*
*Син китмисең минем күңелемнән.*

*Аккош китәр килгән якларына,*
*Һаваларда канат кагынып...*
*Бик ямансу булган чакларымда*
*Кемгә карыйм сине сагынып?*

*Дошман явын тар-мар иткән*
*чакта*
*Йөрәгеңнән кайнар кан тамды,*
*Үзең үлсәң, матур исемең калды,*
*Туган илгә даның таралды!*



# ЛЕЙСЯ, ЛЕЙСЯ, ДОЖДЬ!

## О НЕКОТОРЫХ ТРАДИЦИОННЫХ ОБРЯДАХ

***Традиционные праздники, а также связанные с ними обряды и обычаи являются важным компонентом духовной культуры любого народа. Они дают яркое представление о хозяйстве народа, о его мировоззрении, о связях с другими этносами.***

***КРЖИЖЕВСКИЙ Михаил Владиславович,***
*кандидат исторических наук*

Многие татарские праздники и обряды имеют аналогии у других народов, но, вместе с тем, были различия в их проведении в разных татарских поселениях. Сегодня, благодаря плодотворной деятельности активистов татарского общественного движения, широкую известность как в Самарской области, так и далеко за ее пределами получили праздники Сабантуй, Сембеле и некоторые другие, которые проводятся в нашей области с большим размахом и собирают много зрителей. Для дальнейшего возрождения традиционной культуры следует обратить внимание и на другие обряды, бытовавшие в прошлом у татар.

О различных традиционных праздниках и обрядах татар приводятся сведения в коллективной монографии «Татары Среднего Поволжья и Приуралья» (Москва, 1967).

В работах самарских этнографов, посвященных этнической истории и традиционной культуре народов Урало-Поволжья, содержатся сведения и о татарах Самарской области. Так, в книге Т.И. Ведерниковой «Этнография и праздничная культура народов Самарского края» (Самара, 1991), в разделе, посвященном татарам, есть и описание основных праздников и обрядов.

Традиционным татарским праздникам и обрядам посвящены работы Рауфы Каримовны Уразмановой. Ее материалы публиковались, в частности, в вестнике «Самарская область: этнос и культура».



Книга Р.К. Уразмановой «Обряды и праздники татар Поволжья и Урала (Годовой цикл. XIX – нач. XX вв.)» вышла в свет в 2001 г. в серии публикаций «Историко-этнографический атлас татарского народа». В ней представлен комплекс традиционных татарских праздников, а также связанных с ними обычаев и обрядов. Книга написана на основе многолетних полевых исследований автора. Так, Р.К. Уразманова указывает, что за период с 1971 по 1989 г. ею было обследовано более двухсот деревень Поволжья и Урала, в том числе татарские поселения Камышлинского и Похвистневского районов Самарской области.

Сведения о некоторых традиционных обрядах получил и автор этих строк во время поездок в татарские села Самарской области.

Основные праздники и обряды проводились в весеннее и летнее время. К ним относится обряд вызывания дождя. Дождь необходим земледельцу для того, чтобы созрел хороший урожай, чтобы люди и домашние животные были сыты.

Обряд вызывания дождя был характерен для всех татар, но имел свои локальные отличия. В одних случаях организаторами и главными действующими лицами были взрослые, в других – дети. Обряд вызывания дождя проводился летом или поздней весной, во время засушливой погоды, которая могла погубить урожай. Р.К. Уразманова зафиксировала



около тридцати терминов, обозначающих указанный обряд. В татарских поселениях Камышлинского района он бытовал под названием янгыр аши (янгыраш) – «угощение дождя». Дети ходили по домам и собирали продукты, а затем вместе с пожилыми женщинами шли в поле к роднику, где варили из собранных продуктов кашу. Женщины совершали моление, потом происходило коллективное угощение кашей, а завершалось мероприятие массовым обливанием водой.

В некоторых других татарских поселениях, например, в селе Алькино Похвистневского района данный обряд назывался янгыр ботка (янгыр боткасы) – «каша дождя». Со слов жителей данного села автор этих строк в 2010 г. зафиксировал такое описание обряда: весной или летом дети ходили по улице и обливали друг друга и всех встречных водой, а затем вместе с взрослыми варили кашу и ели – все эти действия должны были вызвать дождь.

Похожий обряд зафиксирован и у кряшен Назаровки, о чем автор уже писал на страницах данного журнала.

Отмечено также проведение в летнее время, с целью повышения плодородия,



обеспечения хорошего урожая обрядов, сопровождавшихся принесением в жертву домашних животных. Такие обряды в разных татарских поселениях тоже назывались по-разному: например, в селах Мочалеевка и Ново-Мансуркино они получили название «янгыр келеве» – «моление дождя». На средства местного населения покупалась овца или другое жертвенное животное, совершалась молитва, жертвенное животное забивали, варили и ели, а затем также обливались водой.

Аналогичные мероприятия имели место и у других народов. Например, жители башкирских поселений Большечерниговского района рассказывали автору о том, как раньше, в летнюю жару сельчане вместе с муллой выходили за село, к водному источнику. Совершалась молитва с целью вызвать дождь, сельчане резали барана, варили его и ели, а затем обливались водой и бросали в воду котел, в котором варили мясо.

Весной самарские башкиры, как и башкиры других регионов, отмечали Каргатуй – праздник, посвященный прилету грачей и пробуждению природы, который также был связан с почитанием предков. Считалось, что вместе с пробуждающейся природой на какое-то время оживали и умершие предки. Смысл праздника сводился к торжествам по случаю обновления окружающей природной среды, и обращению к духам предков и силам природы, с которыми были связаны грачи, сделать этот год благополучным. Раньше в нем участвовали только женщины и дети. Традиционно Каргатуй проводили около водоема, обливали друг друга водой, что должно было способствовать выпадению дождя. Во время праздника также водили хороводы, варили кашу, угощались ею, а остатки этой каши оставляли для грачей. Сегодня этот праздник возрожден благодаря усилиям активистов башкирской общественности. Такой праздник отмечен и у некоторых групп татар, живущих по соседству с башкирами.

Весна и лето – это и время молодежных игрищ. У самарских татар они были разных видов: вечерние, пятничные, встречные.

Что же касается осени и зимы, то в это время проводились гостевания, а также помочи – коллективные мероприятия, устраиваемые с целью более быстрого проведения определенных работ (например, девичьи помочи по изготовлению пряжи, по обработке заколотых гусей и др.), которые также проводили в праздничной атмосфере.

Возрождение традиционных обрядов обогатит современную духовную культуру и должно способствовать наполнению событийного туристского пространства, т.е. комплекса мероприятий, используемых для развития событийного туризма.



# КЕШЕНЕ ХЕЗМӘТ ЯШӘТӘ

***“Тырышкан – табар, ташка кадак кагар”, дип ничек дөрес әйткән икән халык! Хезмәт сөюче кешеләр гомер-гомергә мактау-хөрмәткә лаек булганнар. Тырышып эшләсәң, тормышта зур уңышларга казанырга, югары үрләр яуларга була.***

*Миләүшә ГАЗИМОВА*

Менә Галиевлар гаиләсе дә, Үзбәкстаннан кайтып, Самарның Кинельский бистәсенә урнашкач, тормышларын өр-яңадан башлап җибәрәләр. Һәм, иң беренче чиратта, моңа аларның эш сөчән булулары ярдәм итә.

Наилә апа Галиева әле кечкенә булганда, аның гаиләсе Үзбәкстандагы Андижан өлкәсенең Курган Тепа шәһәренә барып урнаша. Анда алар 38 ел гомер итәләр. Биредә Наилә Рафаэл исемле татар егетенә кияүгә чыга, аларның өч баласы туа.

Әңгәмәбез Наилә ханым Галиева белән.

**– Самарга ничә ел элек килеп урнаштыгыз һәм яңа җирдә нинди авырлыклар кичерергә туры килде? Кинель бистәсе сезне нәрсәсе белән җәлеп итте?**

– 1989 елда, Үзбәкстанда милләтара низаг (конфликт) килеп чыккач, әнием, ике абыем һәм мин гаиләләребез белән Кинель бистәсенә килеп урнаштык.

Башта туган якларыма, Ульян өлкәсенә, барып карагач, андагы тормыш шартлары безне канәгатьләндермәде. Шуннан икетуган энебез Рафаэл Уразаев яшәгән Кинельгә барып карарга булдык.

Монда 11еллык мәктәп тә, янәшәдә генә институт та булуы ошады. Бигрәк тә биредә безне эш белән дә, торак белән дә тәэмин итәргә вәгъдә иттеләр.

Икетуган энем Рафаэлгә һәм аның хатыны Сәвиягә рәхмәтләребез чиксез. Беренче мәлләрдә без аларда яшәдек, аннан соң да алардан һәрвакыт ярдәм тойдык.

Тора-бара олы абыема ташландык кибет бирделәр. Без бергәләп аңардан өч бүлмәле фатир ясадык һәм икетуган абыемнан барыбыз да - өч гаилә - анда кучеп урнаштык. Аннан икенче абыема шулай ук начар гына өй бирделәр. Башка кешеләр мондый ташландык торактан баш тарталар иде. Ә без нәрсә бирәләр – шуңа ризалаштык, чөнки уртак көч белән ремонт ясап, төзекләндереп, аны сафка бастырдык, һәм әниебез белән ике гаилә анда күченде, ә олы абыем теге фатирда калды.

Аннан инде минем иремә дә шундый бәхет елмайды. Ул авырып, инвалидлык алгач, миңа өч эштә эшләргә туры килде - картларга социаль ярдәм күрсәтүче хезмәткәр, хастаханәдә шәфкать туташы һәм санитар. Аллага шөкер, хәләл җефетем терелеп, яңадан эшкә кереште. Рәхмәт инде үзенә, гаилә башлыгы булarак, ул лаеклы ир. Бирегә күчеп килгәч, ул башта прораб булып эшләде. Аннары аны авыл хуҗалыгы институтына капиталь төзелеш бүлеге җитәкчесе итеп билгеләделәр.

Өч балабыз бар бит, аларны аякка бастырырга кирәк. Ә Үзбәкстаннан кайтканда безнең акчабыз юк иде, хәтта андагы фатирларыбыз дәүләтнеке булганга, аларны киткәндә тапшырырга туры килде.

Аллага шөкер, балаларыбыз да кечкенәдән эшләп үстеләр, безгә ярдәм иттеләр. Без шикәр чөгендере, бәрәңге кырлары алып эшкәрттек. Өч гаиләгә гараж төзедек, баз казыдык. Мин, барыбызга да җитсен дип, дүртешәр йөз банка кыяр-помидор тозлый, варенье кайната идем.

Без куплап бәрәннәр дә тоттык. Улларым Альберт белән Илдар төшкә кадәр авыл хуҗалыгы институтында укыйлар, аннан соң бәрәннәр көтүче көтәләр иде. Шулай ук үгезләр дә, өчәр йөз каз да үстердек.

Ә сыерны сатып алырга улларым



үгетләде. Мин ул чакта инфаркттан соң инде ул кадәре нык эшли алмадым. Шулай да малайлар, үзебез карыйбыз, савабыз дип, сыер алдырттылар. Иртән аны кече улым сауса (ул моны тизрәк эшли иде), кичен олысы сауды.

Аннан без ирем белән йорт салып кердек. Шулай һәрбер гаилә аерым яши башлады.

Улларым институтта укыганда шулай ук кичләрен төзелештә дә эшләп йөрделәр. Ә олы кызыбыз Әлмирәне 18 яшендә Үзбәкстанда яшәгән татар дусларыбызның улына кияүгә бирдек. Алар бүгенге көндә Татарстанның Уруссу шәһәрендә яшиләр, ике уллары - Тимур һәм Рәшит.

Авырлыклар арасында, акча булмаудан тыш, климатны да атар идем. Үзбәкстанда кыш булмагач, биредә башта салкыннарны бик авыр кичердек без.

Аллага шөкер, Үзбәкстаннан күчеп килгәч, Кинельский бистәсендә тормышыбызны өр-яңадан башлап, хәзер мул тормышта яшибез. Хәзер балаларыбыз Альберт белән Илдар - эшкуарлар. Ирем Рафаэл дә уллары белән гаилә бизнесында актив катнаша. Алар сәүдә йорты, автомобиль запчастьләре, төзү материаллары кибетләре, машиналар юдыру бинасы, шиналар куючы сервис тота-лар, көнбагыш белән шөгыльләнәләр. Шунысы куандыра – без балаларыбыз белән дә, туганнарыбыз белән дә һәрвакыт бердәм, дус булып, бер-беребезгә булышып яшибез. Хәзер инде кызымның олы улы Тимур да бирегә күченеп, безнең гаилә бизнесында катнаша.

**– Менталитет дигән нәрсә бар. Үзбәкстандагы һәм Самардагы менталитетның аермасы нидә?**

– Үзбәкстанда олыларга хөрмәт күбрәк беленә. Шулай ук анда гореф-гадәтләрне төгәл үтиләр. Әйтик, кеше үлгәч, 40 көн буена өйдә кемдер булырга тиеш, чөнки бу дәвердә кешеләр килеп, кайгыны уртаклашалар, догалар укыйлар. Үлек чыккан өйгә шулай ук көн дә мулла килә. Төшкә кадәр хатын-кызлар, ә аннан соң ир-атлар йөриләр. Шушы 40 көн эчендә һәр пәнҗешәмбе (четверг) мә җлес уздырырга тиешле. Хатын кызларга бизәнү әйберләрен тагарга, чалбардан, яулыксыз йөрергә ярамый. Кунакка барырга рөхсәт ителми.

Үзбәкстанда шулай ук халык татурак яши. Әйтик, без чувашларны, мордваларны, татарларны, урысларны беркайчан да аермадык. Хәтта аларның теге яисә бу милләттән булуы турында уйлап та карамый, белми дә идек. Кешеләр Үзбәкстаннан үзләренең кече ватаннарына күчен башлагач кына, боларының чуваш, тегеләренең мордва, өченчеләренең урыс икәнен белдек.

Ә Самарда мондый аерма яхшы сизелә.

**– Үзбәкстан белән чагыштырганда, бирегә күченеп килгәч, тормыш дәрәҗәгез үстеме яисә, киресенчә, түбәнәйдеме?**

– Кинельдә безнең тормыш дәрәҗәсе үсте, шөкер. Без бик яхшы яшибез хәзер, Үзбәкстанда алай булмас иде. Мәсәлән, минем бер абыем Ташкентта яшәп калды. Анда бик хәерче халык яши. Яисә газы юк, яисә суы юк. Гомумән, тормыш шартлары начар анда. Үзбәкстаннан Кырымга күчеп урнашкан татарларның да бик начар шартларда яшәгәнен беләбез.

**– Бизнеста төрле милләт кешеләре белән аралашырга туры килә. Кайсы милләт кешеләре ышанычлырак?**

– Безнең гаилә бизнесында төрле милләт кешеләре эшли – урыслар да, әрмәннәр дә, чувашлар да, татарлар да. Шатлыкка, барысы да тәртипле, ышанычлылар. Без милләт буенча аермыйбыз, һәр халыкта яман да, яхшы да кешеләр булырга мөмкин.

**– Наилә ханым, балаларны тәрбияләгәндә берәр серегез булдымы?**

– Кинельдә бездән еш кына: "Сез ничек шушындый акыллы балалар тәрбияли алдыгыз?" – ди кызыксыналар. Без улларыбызны, кызыбызны кечкенәдән олыларны хөрмәт итәргә өйрәтеп үстердек. Ә иң мөһиме – аларны хезмәт аша тәрбияләдек. Балачактан эш тәмен белеп, аны сөеп үскән бала акыллы була.

Әле улым Илдарның хатыны Илсөяр дә: "Әни, сез әти белән балаларыгызны шулкадәр яхшы тәрбияләгәнсез. Мин улымның да шундый ук булуын телим", – дип, уллары Камилне еш кына безнең тәрбиягә калдыралар. Дүрт яшьлек бу малай уенчык сусипкечен (лейка), күрәген ала да, мине үзе бакчага эшләргә чакыра (көлә). Кызымның беренче улы Тимур ике яшендә безнең белән беррәттән бәрәңге ала иде инде. Һәм хәзер, 19 яшендә дә, аның тырышлыгына, шулкадәр эш сөючән булуына исебез китә. Әле Уруссуда яшәгәндә үк ул умарта, гөмбә үстерү белән шөгыльләнде.

Олы улым Альберт белән киленем Ирина да биш яшьлек уллары Эмильне еш кына бездә калдыралар.

**– Гаиләдә татар рухын саклап яшисезме?**

– Әйе, Аллаһыга ышанабыз, дини мәҗлесләрне үткәреп киләбез, ел саен корбан чалабыз. Үзебез татара сөйләшәбез, тик менә оныкларыбыз гына ана телен начар беләләр.

Татар җырларын яратып тыңлыйбыз, мәчеткә йөрибез. Сүз уңаеннан шуны әйтәсем килә. Безнең Кинель бистәсендәге мәчетне үзенең ярдәмчеләре белән икетуган энебез Рафаэл Уразаев салдырды. Төзүче буларак, кече улым Илдар да бу игелекле гамәлгә үз өлешен кертте.

**– Хаҗга барырга насыйп булса, Аллаһы Тәгаләдәнниләр сорар идегез?**

– Дөньяларыбызга тынычлык, сугыш, хәвеф-хәтәр булмасын, барыбызга да, бигрәк тә балаларыбызга, исәнлек-саулык бир Ходаем, дип сорар идем. Иң мөһиме – исәнлек һәм тынычлык, алар булса, калганына ирешеп була.

**– Үзбәкстаннан күчеп киткәнегезгә үкенгән чакларыгыз буламы?**

– Үзбәкстанны бик сагынсак та, аннан китеп, биредә урнашуыбызга үкенмибез. Тормыш авырлыклары кешене чыныктыра гына ул. Башта елаган чаклар да күп булды - башка климат, башка менталитет, башка кешеләр. Тик тора-бара күндек. Аллаһыга шөкер, җиң сызганып эшләдек, тырыштык һәм нәтиҗәдә лаеклы тормышта яшибез.





# УЙНАГЫЗ, ГАЛИ ГАРМУННАРЫ!

***Камышлы районының Мәдәният йортында Иске Ярмәк авылының гармун ясау остасы Гали Гәрәевнең тууына 102 ел тулуга багышланган икенче регионара «Уйнагыз, Гали гармуннары!» фестивале булып узды.***

**Рәисә ТӨХБӘТШИНА.**

Иртәнге сәгать 10 да сайлап алу туры башланып, ул төшке ашка кадәр дәвам итте. Программаны бик матур, эчтәлекле, саф татар телендә район мәдәният бүлеге хезмәткәре Алсу Шәкүрова алып барды.

Дөрес, бу юлы гармунчылар үткән гармун ясау остасының 100 еллыгына багышланган фестивальдә катнашучылар санынннан азрак иде. Белмим, бу гармун белән кызыксыну кимүме, әллә башка бүтән сәбәбе бармы?

Киләсе фестивальләргә кадәр бу мәсьәлә буенча җитди эш алып барырга кирәктер, мөгаен.

Сайлап алу турында гармунчыларның чыгышын хөрмәтле жюри әгъзалары – өлкә «Туган тел» татар җәмгыяте советы әгъзасы Фәрхәт Мәхмүтов, Оренбург өлкәсенең Северный районы балалар сәнгать мәктәбе мөдире Фәрит Мифтахов, Камышлы районының социаль ярдәм оешмасы җитәкчесе Наилә Галимова, Самар социаль-педагогия көллияте укытучысы Альбина Мәхмүтова һәм Камышлы районы мәдәният бүлеге җитәкчесе, жюри рәисе Раилә Сафина бәяләделәр. Бәя кую ансат булмагандыр, дип уйлыйм. Тик бәйге бәйге инде ул, аның була җиңүчесе, була җиңелүчесе.

Көндезге сәгать 4тә фестивальнең гала-концерты башланды. Беренче булып сүз Камышлы районы башлыгы Рафаэль Баһаутдиновка бирелде.

*– Бүген безнең Камышлы район Мәдәният йортына төрле төбәкләрдән моң осталары, гармунчылар бәйгегә җыйналды. Бу - бик шатлыклы вакыйга. Тарих битләрен барласаң, элек-электән Россиянең һәр төбәгендә гармун ясаучы осталар булган. Без, камышлылылар да, шундый остазыбыз белән чын күңелдән горурлана алабыз, чөнки Гали аганың тальян гармуннары татар яшәгән бөтен җиргә таралган. Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты белән берлектә оештырылган бу тантанага килгән кунакларга, гармунчыларга бәйрәмдә катнашулары өчен чиксез рәхмәтемне белдерәм. Барчагызга да исәнлек-саулык, иминлек, иҗади уңышлар телим. Бәйрәмебез мөбарәк һәм гомерле булсын! – диде ул.*

Гармунчыларны котларга танылган «Ак каен» һәм «Наз» бию коллективлары, һәвәскәр җырчыларыбыз Рәйхана апа Мөхетдинова, Люция апа Ибраһимова, Фәния апа Гайфул-



лина, Мөдәррис ага Гыйззәтов, Руфия Камилҗанова, Оркыя һәм Наил Галимуллиннар килгән иде. Аларның чыгышларын тамашачы һәрвакыттагыча кайнар алкышларга күмде. Һәвәскәр артистларыбызның чыгышы бәйгедә җиңүче гармунчыларның чыгышы белән үрелеп барды.

10 яшьтән 15 яшькә кадәр бер генә гармунчы булып, аңа беренче дәрәҗә лауреат исеме бирелде. Ул – Шентала районының Татар Әбдекие авылыннан Ирек Мотыйгуллин. Аңа 12 яшь кенә әле. Ирек Идрис улы, яшь булуына карамастан, инде күп кенә бәйгеләрдә катнашып, җиңүләр яулаган егет. Моңлы итеп төрле гармуннарда уйнаудан, җырлаудан тыш, үзенең мөлаемлыгы, сәхнәдә тотышы, зәвыклы милли киемнәре белән үзенә тартып тора. Бер сүз белән әйткәндә, өметле бала, татарның киләчәге ул. Кызганычка, аның белән ярышырдай яшьтәшләре генә юк иде. Хәер, булса да, аңа тиңнәр булмастыр кебек.

Шулай да яшүсмерләр арасында гармунда уйнауга мәхәббәт тәрбияли алмавыбызга офтанып куясың. Әгәр бу эшне шулай үз агымына гына җибәрсәк, гармунда уйнаучыларны якын вакытларда бармак белән генә санарга калмасмы икән?

26 яшьтән 35 яшькәчә гармунчылар номинациясендә беренче дәрәҗә лауреат исеменә Кошки районы, Яңа Фәйзулла авылы егете Азат Туктаров; 36 яшьтән 50 яшькәчә гармунчылар арасында беренче дәрәҗә лауреат исеменә Камышлы районы, Яңа Усман авылы егете Мәгъдән Хәсәншин һәм Чулпан авылыннан Әсхәт Жумалетдинов, икенче дәрәҗә лауреат исеменә Айрат Фәлахов; 51 яшьтән 60 яшькәчә гармунчылар арасыннан өченче дәрәҗә лауреат исеменә Камышлы авылыннан Рәшит Гыйләҗев һәм Татарстанның Әлмәт районы, Минебай станциясеннән Илгизәр Мотыйгуллин, икенче дәрәҗә лауреат исеменә Дәүләткол авылыннан Рәшит Дәрҗеманов һәм Кошки районы, Фәйзулла авылыннан Равил Минебаев, беренче дәрәҗә лауреат исеменә Оренбург өлкәсенең Бакай авылы егете Марат Шәйхетдинов лаек булдылар.



60 яшьтән 65 яшькәчә гармунчылар арасыннан өченче дәрәҗә лауреат исеменә Похвистнево районының Яңа Мансур авылыннан Миргазыян Садриев, икенче



дәрәҗә лауреат исеменә Иске Усман авылыннан Әсфир Нуретдинов; беренче дәрәҗә лауреат исеменә Шентала районының Денис авылыннан Фуат Төхвәтуллин; 65 яшьтән өлкән булган гармунчылар арасыннан Иске Усман авылыннан Мөкатдәс Нуретдинов – икенче дәрәҗә лауреат исеменә, Камышлы авылыннан Әсфәр Галәлетдинов һәм Иске Ярмәк авылыннан Мәдхәт Рәхимов беренче дәрәҗә лауреат исеменә лаек булдылар.

Ансамбльләр арасында өченче дәрәҗә лауреат исеменә Әлмәт районы, Колшәриф авылыннан «Морат» ансамбле; икенче дәрәҗә лауреат исеменә Похвистнево районы, Гали авылыннан гармунчылар дуэты – Дәрҗеман Салихов һәм Әсхәт Гарифуллин; беренче дәрәҗә лауреат исеменә Әлмәт районы, Минебай станциясеннән «Яшь күңелләр» ансамбле лаек булдылар. Барлык җиңүчеләргә дә дипломнар һәм кыйммәтле бүләкләр тапшырылды.

Бәйгедә катнашкан Гали аганың туганнан туган энесе, Оренбург өлкәсенең Богырыслан шәһәреннән Наил Зыя улы Алтынбаев, Балыклы авылыннан өлкән яшьтәге гармунчыларыбыз Хәбибулла Нигъмәтуллин, Габделхәй Ангалышев, Камышлы авылыннан Мөхәммәт Шәкүров, Рәшидә Вафина, Әлмәт районыннан Илтизәр Җамалиев, Әхмәт Мөхәммәдиев, Самар шәһәреннән Гали Гыйльманов, Похвистнево районының Гали авылыннан гармунчылар





ускән, Самар шәһәренең танылган «Идел» ансамбле җитәкчесе Мидхәт Әминев иде. Мидхәт Шакир улы бу көнне төрле гармуннарда, курайда уйнап, тамашачының һәм инде, әлбәттә, жюри әгъзаларының күңелен яулады. Афәрин, Мидхәт!

Гран-при бүләк иясе үзенең чыгышында Камышлы һәм Иске Ярмәк авыллары халкының кунакчыллыгы, бердәмлеге, бергәлегенә исе китүен әйтеп узды.

– *Район башлыгы Рафаэль Камил улына, мәдәният бүлеге калдым. Музей җитәкчесе Әлфия апа Баһаутдинова алдында хөрмәт белән баш иям, – диде ул.*

Иганәчеләр дигәннән... Хәзерге заманда мондый зур фестивальләрне алардан башка уздырып булмый. Менә бу юлы да шушы чараны үткәрүдә Самарның «Ипозембанк»ы, өлкә «Туган тел» татар җәмгыяте (җитәкчесе - Ильяс Шәкүров), «Самар төзелеш компаниясе» (директоры - Вил Мөхәммәтшин), «Итиль» фирмасы (җитәкчесе - Рәшит Сәлахов),



дуэты – Сәгыйдулла Гобәев һәм Рәфкать Әхмәдиевлар да дипломнар һәм махсус бүләкләр белән бүләкләнделәр.

Әтисе хөрмәтенә уздырылган бәйрәмгә Гали аганың улы Җәгъфәр Гәрәев тә килгән иде. Ул район башлыгы Рафаэль Баһаутдиновка, мәдәният бүлеге җитәкчесе Раилә Сафинага һәм бәйгене оештыручыларга, катнашучыларга зур рәхмәтен белдерде, абыйсы Әсфәндияр һәм үзе исеменнән иң яшь (Ирек Мотыйгуллинга) һәм иң өлкән (Габделхәй Ангалышевка) гармунчыларга акчалата бүләк тапшырды.

Менә бәйгенең кульминацион вакыты килеп җитте һәм җиңүченең – Гран-при иясенең исеме аталды. Ул Кошки районының Иске Фәйзулла авылында туып-



*җитәкчесе Раилә Нәгыйм кызына, бәйгенең барлык оештыручыларына, иганәчеләргә шундый зур бәйрәм үткәрүләре өчен зур рәхмәтемне белдерәм. Иске Ярмәк авылы мәктәбенең музееен карап та хәйран*

«Идел буе төзелеш компаниясе», эшмәкәрләр Рөстәм Гаделшин (Тольятти шәһәреннән), Наил Кәлимуллин (Самар шәһәреннән), Рөстәм Хисмәтов, Венера Абрарова, Илшат Каюмов, Булат Җиһаншин (Камышлы районыннан) ярдәм күрсәттеләр.

Рафаэль Баһаутдинов Камышлы район хакимияте исеменнән иганәчеләргә Рәхмәт хатлары һәм истәлекле бүләкләр тапшырды.

Бәйрәм ахырына якынлашты һәм татарларның гимны булган «Туган тел» җырын башкарып тәмамланды.

Тамашачылар да, гармунчылар да киләсе фестивальләрдә дә очрашырга насыйп булсын, дигән теләктә таралыштылар. Амин, шулай булсын!

# Хөрмәтле редакция!

Мин Самар шәһәренең ”Яктылык” мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты дәресләрен укытам. Мәктәбебездә белем алучы укучыларда, аларның нинди милләт кешесе булуларына карамастан, бөек Тукай теленә, күп укучыларның туган телләре булган татар теленә мәхәббәт тәрбияләргә тырышам. Дәресләрдә укучыларның сөйләм һәм язма телләрен үстерү өстендә дә күп эш алып барам. Сыйныфтан тыш та аларны татар телендә төрле темага инша һәм шигырьләр язарга өйрәтәм.

Быелгы уку елында миңа үзем укыткан сыйныфлардан тыш, башлангыч 4 “Б” сыйныфында да татар телен укытырга тәкъдим иттеләр, һәм мин моңа шатланып риза булдым. Румия Әгъзамовна Исмәгыйлева җитәкләгән бу сыйныф укучылары бик тә актив, зирәк акыллылар, татар теле дәресләрендә дә бик тырыш укыйлар.

Уку елы дәверендә 4 “Б” сыйныф укучылары Румия апалары белән бик күп төрле экскурсияләрдә булдылар. Әле күптән түгел генә алар класс җитәкчеләре һәм әниләре белән Казанга да сәяхәткә бардылар. Аннан кайткач, балаларга бу турыда инша язып килергә куштым. Шуларның уңышлы дип табылганнарын сезгә дә җибәрергә булдым.

***Хөрмәт белән “Яктылык” мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы***
***Нурзидә Фәйзуллина***

## «Яктылык» мәктәбендә – Белем бәйрәме

* * *

*Самарада бер мәктәп бар –*
*«Яктылык» дип атала.*
*Ана телен өйрәнергә*
*Килегез сез мәктәпкә.*
*Өйрәтер укытучылары*
*Укырга һәм язарга,*
*Дөрес, матур сөйләшергә,*
*Биергә һәм җырларга.*
*Тәртипкә дә, белемгә дә*
*Мәктәптә өйрәнерсез.*
*Дуслар белән рәхәтләнеп,*
*Татарча сөйләшерсез.*
*Телебезне саклар диеп*
*«Яктылык» өмет бирә.*
*Алмаш буынны үстерә*
*Тукайга һәм Җәлилгә.*
*Мәктәбебез юл күрсәтә*
*Гел алга – яктылыкка.*
*Яшь белгечләр әзерләүдә*
*Хезмәт итә халыкка.*
*Килсәгез сез бу мәктәпкә,*
*Милләтне, телне саклаучы*
*Булырсыз киләчәктә.*
*Онытмагыз шуны да сез:*
*Белемле кешеләр генә*
*Бик тә кирәк милләткә.*

*«Яктылык» мәктәбенең 4 «Б» сыйныф укучысы*
*Аня Бодрягина*




## Мин «Орлёнок» та булдым

Мин 6 яшемнән бирле Самардагы «Заря» Мәдәният йортында эшләүче «Грация» эстрада биюләре ансамбленең «Радуга» («Салават күпере») төркемендә биим. Балетмейстерыбыз – Наталья Юрьевна Бояркина. Шушы елның 24–28 апрелендә Кара диңгез буенда урнашкан Туапсе шәһәреннән ерак түгел булган «Орлёнок» бөтенроссия балалар лагерендә «Цветик-семицветик» исемле Россиядәге барлык иҗади балалар коллективларының конкурсы булды. Бу конкурска безне дә чакырдылар. Безнең 22 кыз катнашкан «Радуга» бию төркеме «Любопытная поездка» дигән бию белән үз номинациясендә беренче урынга чыкты. Безне диплом һәм алтын статуэтка белән бүләкләделәр. Безнең өчен Кара диңгезгә, Туапсе шәһәренең төрле истәлекле урыннарына экскурсияләр дә оештырылган иде. Мин дусларым белән шундый матур җирләрдә булуым, шундый төр конкурсларда катнашуым белән горурланам. Чөнки бу җиңүдә минем дә берникадәр өлешем бар, дип уйлыйм.

***«Яктылык» мәктәбенең 4 «Б» сыйныф укучысы***
***Алсу Тренгулова***

## Казанга сәяхәт

Знче сыйныфта укыганда татар теле дәресендә укытучыбыз Румия апа Исмәгыйлева безгә Казан шәһәрендәге «Әкият» курчак театры турында сөйләгән иде. Интернеттан бу театрның үзен дә күргән идек. Үткән елда Самарда Идел буе шәһәрләрендә эшләүче курчак театрларының фестивале дә булды. Бу чарада «Әкият» курчак театры да катнашты. Менә шул вакыттан бирле минем бу курчак театрын, аның әкияти бинасын үз күзләрем белән күрәсем килгән иде. Ниһаять, минем бу теләгем тормышка ашты. Апрельдә «Самараинтур» туристик фирмасының Казанга укучылар өчен кызыклы экскурсия оештыруын белгәч, минем әнием безнең сыйныфка май башында шунда барырга тәкъдим итте. Шулай итеп, 3 майда без – сыйныфташларым, безнең әниләребез һәм класс җитәкчебез Румия апа – туристик автобуста Казанга юл тоттык. Төш вакытында инде Татарстанның башкаласы, һәр татар кешесе өчен якын булган Казанга килеп тә җиттек. Ул – Идел буендагы бик борынгы шәһәрләрнең берсе. Казан – истәлекле урыннарга да бик бай. Экскурсиябез «Әкият» татар дәүләт курчак театрыннан башланып китте. Ул искиткеч матур архитектуралы бинада урнашкан. Анда килеп керү белән үзеңне әкият дөньясында кебек хис итәсең. Фойеда, бөтен стена буендагы витриналарда әкият геройлары – курчаклар тора. Бу курчаклар монда килгән һәр яшь тамашачыга серле генә карап торалар сыман. Сәхнәдә без «Али Баба һәм кырык юлбасар» әкиятен карадык.



*Курчак театрында*

Театрдан чыккач, безне автобуслар Казан Кремленә илттеләр. Кремль Казанның үзәгендә урнашкан. Аның янында герой-шагыйрь Муса Җәлилгә һәйкәл куелган.

Кремльгә Спас манарасы аша керергә кирәк. Анда алдан без Кремльнең йөзек кашы булган




*Мәрҗани мәчетендә*



*Кол Шәриф мәчетендә*

Сөембикә манарасы янына бардык. Безнең гид – Алсу апа бу манараның тарихы турында сөйләде.

Ерак түгел генә булган һәм 2005 елда ачылган Кол Шәриф мәчете дә безне үзенең сихри гүзәллеге белән таң калдырды. Бу мәчетне күргән һәр сәяхәтче аны «Дөньяның сигезенче могҗизасы», дии атый икән. Аннан соң без Казанның башка истәлекле урыннарына юнәлдек. Казан федераль университетын, Мәрҗани мәчетен карап йөрдек. Икенче көнне без Казан ипподромында булдык. Анда мин Татарстан Президенты Минтимер Шәймиевка бүләк иткән «Лидер» исемле атка атланып йөрдем. Ипподромда атларга багышланган музей да бар икән. Музейдагы ат скульптуралары, башка экспонатлар да бик ошады безгә.

Казанда «Туган авыл» дигән милли-этнографик үзәк тә бар.



*«Әкият» курчак театры*

Анда безнең алда «Сорнай» фольклор ансамбле артистлары чыгыш ясадылар. Аннары без алар белән бергә төрле уеннар уйнадык, җырладык, биедек. Бу 3-4 майдагы ике көн бик тиз һәм күңелле булып узып китте. Казанга сәяхәтебез миңа бик тә ошады.

**«Яктылык» мәктәбенең 4 «Б» сыйныф укучысы**
**Алсу Әбдерәхимова**



Исмәгыйль кызы Шаһидә Галимова (Вагизова) 1934 елда Самар өлкәсе Шенталы районының Денис авылында туа. Аның балачагы Бөек Ватан сугышы елларына туры килә. Кызның башыннан ачлык, ялангачлык уза. Әтисе белән абзые сугышка китәләр. Әнисе алты бала белән кала.

Туган авылында 10 сыйныф тәмамлаган Шаһидәгә китапханәче, балалар бакчасында тәрбияче, мәктәптә укытучы, район комсомол комитетының икенче секретаре булып эшләргә насыйп була.

Ире Минәхмәт белән алар өч кыз үстерәләр. 1967 елда Шаһидәнең гаиләсе Татарстанның Әлмәт шәһәренә күченеп урнаша. Һәм бирелә Шаһидә апа 20 елдан артык Әлмәт эчке эшләр идарәсенең Дәүләт автоинспекциясендә эшли. Яхшы хезмәте өчен милләттәшебез өч медаль, "Милиция отличнигы" түшбилгесе белән бүләкләнә.

Мәрхәмәтле, гадел, ярдәмчел Шаһидәне эшендә яратып, "әни" дип атап йөртәләр. Өлкән лейтенант званиесендә Галимова, инвалидлык алуы сәбәпле, пенсиягә чыга.

Шаһидә җиде яшеннән гармунда уйный башлый, Фәйзулла Туишев исемендәге гармунчылар конкурсы лауреаты була. Кызганычка, каты авыруы аркасында Шаһидә Галимова урын өстендә генә ятып тора. Олы кызы тәрбиясендә үз фатирында яши ул. Кече кызы 46 яшендә сырхаудан вафат була. Ничек кенә булмасын, бер шигырендә "Минем яшисем килә!" - дип язган Шаһидә апа күңел төшенкелегенә бирелми. Ул туган авылын сагынып, күңелендәге хис-тойгыларын шигъри юлларга сала. Аларның берничәсен укуыларыбызга да тәкъдим итәбез.

# «МИНЕМ ЯШИСЕМ КИЛӘ!»

### «Коры елга»да ат баткан

Һәр авылда үзенең тапкыр, зирәк, шук, хәйләкәр, мәзәкчел кешеләре була бит. Шундыйларның берсе урам буйлап өенә кайтып килгәндә, бер йортның капкасы төбендә эскәмиядә авылдашларының сөйләшеп утырганнарын күреп ала да йөгерергә тотына. Болар янына якынлашкач, тегеләр күреп алалар да: «Галиулла абзый, кая шулкадәр ашыгасың, кил әле безнең янга, берәр нәрсә ялганлап китәр идең, хет» — диләр.

Галиулла абзый исә йөгерүен дәвам итеп: «Егетләр, вакытым юк, коры елгада атым батып калды, шуны чалырга пычак алырга кайтуым», — дип, җан-фәрманга йөгереп үтә болар яныннан.

Теге эскәмиядә гәп сатып утыручылар да сикерешеп торалар. «Әйдәгез, егетләр, без дә барыйк. Җәй уртасында ит һәркемгә дә булмый бит әле ул, ярдәм дә итәрбез, итле дә булырбыз», — диләр.

Көтәләр, көтәләр болар Галиулла абзыйның пычак алып өеннән чыкканын. Ә ул һаман юк та, юк.

Шуннан соң боларның берсенең башына барып җитә бит. Үзе «Коры елга»да булсын, шунда ат та батсын. Анда бит коп-коры, ат батардай урын юк! Исеме дә шуның өчен «Коры елга» бит аның!»

«Эх, егетләр, егетләр... Монда да безне Галиулла абзый алдап китте бит», — дип, бераз уңайсызланып алсалар да, шаркылдашып көлделәр.

### Онытылмас еллар

*Авылыбызда гөрли Сабан туе*
*Күп җыелган халык бәйрәмгә.*
*Җигүле атлар читән буйларында*
*Куелганнар иде бәйләүгә.*

*Милли уен кыза барган мәлдә*
*Килде йөрәк өзгеч бу хәбәр:*
*«Фашист бәреп кергән илебезгә,*
*Бомбаларын коя бик хәтәр!»*

*Ыгы-зыгы, чабыш, елашулар,*
*Мәйдан бушап калды тиз ара.*
*Авыр хәбәр өзде үзәкләрне,*
*Шомлы сулар акты елгада.*

*Янып торган кояш сүрелде дә,*
*Күкне кара болыт каплады.*
*Ил өстенә төшкән бу афәтне*
*Табигать тә шунда аңлады.*

*Иртәгесен ирләр, яшь егетләр,*
*Хатын-кызлар китте фронтка.*
*Кайгы булып исте сугыш җиле,*
*Тальяннар да тынды озакка.*

***

*«Кичү тавы» на сөйримен*
*Утын төялгән арба.*
*Никадәр арсаң-талсаң да,*
*Үрләрең әле алда.*

*Аякларда чабата да,*
*Ә өстемдә бишмәтләр.*
*Әй, ачып беткән язмышлар!*
*Күп күрсәтте михнәтләр.*

***

*Никадәр тирән булса да,*
*Күлләр диңгез түгел.*
*Бәхетле бар, бәхетсез бар,*
*Дөньялар тигез түгел.*

## Диагноз

Авыл кешесенең шәхси тормышындагы йорт хайваннарыннан, сыердан да кадерлерәк терлеге бармы икән? Гаиләне тукландыручы, аның сөенече, куанычы да шул сыер бит инде.

Шулай, көтмәгәндә, ялгыз, тол хатын Зәйнәп апаның сыеры чирләп китә. Зәйнәп апа бик каты кайгыга төшә. Ул, нәселдән килгән белем буенча, «Мал врачы» дигән исем алган Рахимҗан абзыйга йөгерә.

Рахимҗан абзый килеп сыерның барлык әгъзаларын җентекләп тикшерә. Зәйнәп апа да аның белән сыер тирәсендә әйләнә: «Рахимҗан абзый, нәрсә генә булды икән, ә?» — дип кабатлый.

Мал духтыры исә, үзенә генә хас булган җитдилек белән, игътибарлап, сыерны карап бетергәч: «Моңарга, Зәйнәп, нәрсә булса да бер нәрсә булган инде»— дип, диагноз куя.

## Тальянлы күңел

*Их, бер сузып җибәрәсең,*
*Тальянны тезгә куеп.*
*Шахта, авыл көйләреннән*
*Булмый беркайчан туеп.*

*Күрекләрен тартып, сузып,*
*Чумып сихри моңнарга,*
*Мин яратам айлы кичтә*
*Гармунымда уйнарга.*

*Уйный-уйный кызасың да,*
*Китә бию көйләре.*
*Дәртле тальян тавышлары*
*Күтәрә күңелләрне.*

*Йөрәгемнән китми һич тә*
*Наласа, Шөгерләрем.*
*Җанга якын көйләр уйнап,*
*Үтәдер гомерләрем.*

*Авылым минем*
*Денис авылында җиде чишмә,*
*Сулары да тәмле, шифалы.*
*Җиде чишмә, җиде мәчетле,*
*Авылыбыз бик чал тарихлы.*

*Син халкымның горурлыгы бүген,*
*Балкып яшә әле, авылым.*
*Синдә туып, синдә үскәнгәме,*
*Күкрәк тулы минем шатлыгым.*

*Яшик әле, яшик, авылдашлар,*
*Каралтмыйча авылыбыз йөзен.*
*Җәен Сабантуйда күрешик без,*
*Бахатайда күрешик көзен.*

***

*Чәчләремә инде чаллар төште,*
*Тирән җыерчыклар йөземдә.*
*Яшьлегемне сагынып утырганга*
*Кайнар яшьләр минем күземдә.*

## Урманнар

*Истә һаман, сагынамын бик нык*
*Туган якның басу-кырларын.*
*Сукмакларын, «Каенлы юл чаты»н,*
*«Борын арты» куе урманын.*

*Аланнары яшел келәм кебек,*
*Бизи аны гөлләр-чәчәкләр.*
*Еллар үткән саен онытылмый,*
*Җир җиләге тәме, хуш исләр.*

*Чишмә буйларында ал бөрлегән,*
*Куакларда — көрән чикләвек.*
*Җитлеккәннәр, җый да аша гына,*
*Ә бүре җиләген читләп үт.*

*Сугыш ятим итте күбебезне,*
*Интектек без яшьләй, юклыктан.*
*Балтырганы, кузгалагы — барсы*
*Саклап калды безне ачлыктан.*

*Урман һаман матур, шаулап тора,*
*Яшеренә төлке, куяннар.*
*Табигатьнең бер бай кочагы ул,*
*Саклыйк аны, дуслар, туганнар!*

*Авылымны нигә сагынам мин?*
*Авылымны нигә сагынам мин?*
*Шунда туып, шунда үскәнгәме?*
*Әллә туып үскән туфрагымны*
*Җәлләмичә ташлап киткәнгәме?*

*Чишмәләрнең суын эчкәнгәме?*
*Таң суларын коенып үскәнгәме?*
*Җылы, йомшак җилләр исеп,*
*Шуны хәтерләтеп киткәнгәме?*

*Балачагың исеңә төшкәнгәме,*
*Шул вакыттан нужа күргәнгәме?*
*Әллә якыннарың исеңә төшеп,*
*Туган җирнең кадерен белгәнгәме?*

*Язмыш сине ялгыз иткәнгәме,*
*Яшьлек үтеп картлык килгәнгәме,*
*Түземлегең бетеп, синең өчен*
*Әллә дөнья яме беткәнгәме?*

## Җиңү көненә багышлап

*Җиде яшьтә кулыма гармун алдым,*
*Сузып-сузып аны уйнадым.*
*Җиз телләргә сагышымны кушып,*
*Әтиемне сагынып җырладым.*

*Авыр сугыш бетте. Җиңү килде!*
*Миңа унбер тулды шул елда,*
*Әтием, абыем — сугыш*
*корбаннары –*
*Күзләрдә яшь кипми быел да.*

*Ходай күрсәтмәсен иде бер дә*
*Сугыш дигән ачы афәтне.*
*Бары шатлык белән тынычлыкта*
*Яшисе иде күреп рәхәтне.*

*Сузып-сузып уйныйм гармунымны,*
*Еракларга чыңы таралсын.*
*Хәтер яраларын яңартсын да,*
*Кайгы -хәсрәтләрне таратсын.*

*Гел тынмасын иде минем гармун,*
*Һаман уйнасын да уйнасын.*
*Кан коешлар бетсен җир йөзендә,*
*Беркайчан да сугыш булмасын!*

## Һаман да килеп җиәлми шул әле

Авылыбызның Миннурый абыстай шаян, тапкыр, шук сүзләргә шулкадәр бай иде. Әйтерсең лә бөтен нәрсәгә җавабы тел очына төймә кебек тезелеп куелган диярсең.

Күп нәрсәләр минем исемнән чыкса да, берсе һич тә онытылмый, чөнки аны ел да килә торган Рамазан ае искә төшереп тора.

Бервакытны шулай Миннурый абыстай белән өстәл артында икәүдән-икәү чәй эчеп утырырга насыйп булды. Мин, күп белгәнгә салынып: «Миннурый абыстай, ураза да килеп җитә торгандыр инде» — дидем. Ул миңа тиз генә күзен төшереп алды да, тыныч кына: «Әйе, килеп җитә инде». Әз генә тыныш алып: «Әле ул сезгә хәтле килеп тә җитә алмас» — диде. Мин бу сүзләрдән соң шаркылдап көләм, ә ул миңа тыныч кына елмаеп карап тора, гүя: «Менә, бик күп белсәң» — дигән кебек. Дөрес, ураза кайберәүләребезгә һаман да килеп җитә алмый шул әле.



Где вы живёте?
Сез кайда яшисез?

- в городе - шәһәрдә

- в деревне - авылда

- в посёлке - бистәдә

- в райцентре - район үзәгендә

Какой ваш адрес? - Адресыгыз ничек?

Я живу на улице Гагарина, дом 3, квартира 33 –

Мин Гагарин урамында, өченче йортта, утыз өченче фатирда яшим

В каком доме вы живёте? –
Сез кайсы йортта яшисез?

# НАШ ДОМ
# йортыбыз





Ваш дом новый? – Йортыгыз яңамы?

Нет, наш дом старый – Юк, йортыбыз иске

На каком этаже ваша квартира?
- Фатирыгыз ничәнче катта?

На шестом – Алтынчы катта

Сколько комнат? – Ничә бүлмә бар?

Какие комнаты? – Нинди бүлмәләр?

– прихожая – алгы бүлмә

– кухня – аш бүлмәсе

– гостиная – кунак бүлмәсе

– спальня – йокы бүлмәсе

– ванная – юыну бүлмәсе



Окно – тәрәзә

дверь – ишек

пол – идән

потолок – түшәм

стол – өстәл

стул – урындык

кровать – караваt

кресло – кәнәфи

полка – киштә

шкаф для одежды – кием шкафы

полка для обуви – аяк киеме киштәсе

холодильник – суыткыч

газовая плита – газ плитәсе







# ТАЛАНТЫ «МУЗЫКАЛЬНОГО РОДНИКА»

**27 апреля в ГКУ СО «Дом дружбы народов» прошел второй областной караоке-конкурс татарских песен «Монлы чишма» («Музыкальный родник»). Организатором мероприятия выступило Самарское областное татарское общество «Туган тел» при финансовой поддержке ООО «ИПОЗЕМбанк».**

**Римма НУРЕТДИНОВА**





Конкурс проводился с целью популяризации классической и современной татарской песенной культуры среди широких кругов населения Самарской области, воспитания эстетической культуры населения, выявления лучших исполнителей и талантливой молодежи для привлечения в татарские творческие коллективы Самарской области.

Организовали и провели музыкальный конкурс члены СОТО «Туган тел» - супруги Фархат и Альбина Махмутовы и их дочь Фарзана.

Участники конкурса соревновались в трех возрастных номинациях: от 7 до 13 лет, от 14 до 17 лет и от 17 и старше. Им предстояло показать свое певческое мастерство, исполняя два вокальных произведения: в первом туре одну песню без инструментального сопровождения, во втором - выбрать из 50 песен одну и исполнить её караоке.

19 участников конкурса, несмотря на волнение, сумели подарить зрителям настоящий праздник.

Жюри, куда вошли доцент кафедры хорового дирижирования и сольного пения ПГСГА Алия Амирова, солистка ансамбля «Ялкынлы яшьлек» Айсылу Абдеева, преподаватель вокала Самарского социально-педагогического колледжа Альбина Махмутова и президент СОТО «Туган тел» Ильяс Шакуров, оценивало выступления участников по 10-балльной системе. По сумме набранных в обоих турах баллов и выявлялись победители.

В младшей возрастной группе

первое место заняла 10-летняя Камиля Минахметова (г. Самара). 12-летняя Алсиня Давлетбаева (г. Самара) и 7-летняя Азалина Туктарова (Кошкинский район, с. Новое Фейзуллово) заняли 2 и 3 места соответственно.

В средней возрастной группе победительницей стала 14-летняя Альбина Мингалиева (г. Самара). Второе место у 17-летнего Наиля Исхакова (г. Тольятти), а третье – у 17-летнего Альберта Минатдинова (с. Камышла).

В старшей возрастной группе лучшей стала 20-летняя Алсу Валиуллина (г. Самара). 51-летняя Амина Ибятуллина (г. Самара) и 42-летняя Светлана Исхакова (г. Тольятти) заняли 2 и 3 места соответственно.

Гран-при получила студентка СГАСУ Лилия Бикмаева. Всем участникам конкурса были вручены дипломы «Туган тел» и призы. Обладателям призовых мест вручались ноутбуки, планшетные компьютеры, смартфоны, сотовые телефоны. А Лилия Бикмаева стала обладателем главного приза – телевизора.

# «МОҢЛЫ ЧИШМӘ» СӘЛӘТЛЕЛӘРЕ

**Самарның Халыклар дуслыгы йортында икенче тапкыр “Моңлы чишмә” караоке-конкурсы булып үтте. Аны “Ипозембанк” җаваплылыгы чикләнгән оешма ярдәме белән өлкә “Туган тел” татар җәмгыяте үткәрде.**

**Римма НУРЕТДИНОВА**

Бу бәйгене “Туган тел” оешмасы әгъзалары — ирле-хатынлы Фәрхәт һәм Альбина Мәхмүтовлар уйлап чыгарганнар һәм тормышка ашырып киләләр. Быелгы чараны оештыруга һәм алып баруга аларның кызлары Фәрзәнә дә килеп кушылды.

Конкурс татар җырын популярлаштыру, халкыбызда эстетик культура тәрбияләү, татар яшьләре арасыннан җырга сәләтлеләрен эзләп табу һәм сәнгать төркемнәренә җәлеп итү өчен эшләнә.

Бәйгедә, өч төркемгә бүленеп, 19 конкурсант катнашты. Самар һәм Тольятти шәһәрләре, Камышлы һәм Яңа Җүрәй авылларыннан килгән башкаручылар баштa музыкасыз, аннары караоке көенә җырлап, тамашачыларга чын бәйрәм ясадылар.

Җиңү яулау өчен матур итеп татарча җырларга, сәхнәдә үз-үзеңне тота белү осталыгыңны күрсәтергә, тамашачыларның алкышларын яулый алырга кирәк иде. Әлбәттә, барысы да шәп җырлады, дип әйтеп булмый: кемдер артык дулкынланды һәм сүзләрен онытты, кемнеңдер көе ноталарына килеп бетмәде. Шулай да башкаручылар барысы да татар җырын яратуларын күрсәттеләр, онытылып баручы халык көйләрен сәхнәгә чыгарып, татар җырын белүләрен расладылар.

Бәйгедә катнашучыларның осталыкларын мәртәбәле жюри – Идел буе дәүләт социаль-гуманитар академиясенең музыка кафедрасы доценты Алия Әмирова, Самараның социаль-педагогия колледжында музыка дәресләрен укытучы Альбина Мәхмүтова, «Ялкынлы яшьлек» җыр, бию һәм шигърият халык ансамбле солисты Айсылу Әбдиева, өлкә “Туган тел” татар җәмгыяте президенты Ильяс Шәкуров бәяләде.

Конкурстан тыш, чыгышлар арасында өлкә “Туган тел” оешмасының аксакалы Азат абый Надиров җырлавы искиткеч яңалык булды. Аның көр һәм моңлы тавышы тамашачыларның күңелен яулап, алкышларга күмелде.

Менә конкурсантларның түземсезлек белән көткән мизгелләр дә җитте. 7 – 13 яшьтәге җырчылар арасында беренче урын – Самара кызы Камилә Минәхмәтовага, икенче – «Яктылык» мәктәбе укучысы Алсинә Дәүләтбаевага, өченче урын Кошки районының Яңа Җүрәй авылыннан килгән Азалинә Туктаровага бирелде

14 – 17 яшьтәгеләр төркемендә “Яктылык” укучысы Альбина Мингалиева җиңеп чыкты. Тольяттилы Наил Исхаков һәм камышлылы Альберт Минатдинов икенче-өченче урыннарны бүлештеләр.

Олы яшьтәгеләр арасында самарлылар Алсу Вәлиуллина – беренчелекне, Әминә Ибәтуллина – икенче, тольяттилы Светлана Исхакова өченче урыннарны алдылар.

Самар дәүләт архитектура төзү университетында укучы Лилия Бикмаеваның чыгышы иң югары бәягә лаеклы, дип табылды һәм аңа Гран-при һәм киң экранлы телевизор бүләк ителде.

Бәйгедә катнашучыларның барысы да өлкә “Туган тел” җәмгыяте дипломнары һәм ноутбуклар, планшетлар, смарт-фон һәм телефоннар белән бүләкләнделәр.



*Нурсинә Хәкимова*

# ГӨЛЛӘР КОЯШКА ҮРЕЛӘ

*(Повестьтан өзек)*

***Язмамны әнием Мәрьям белән әтием Хәсәншаның якты истәлегенә багышлыйм***

...1954 елның май ае. Күктәге кояш үзенең җылы нурлары белән җир йөзен иркәли. Елга тирәсендә үсеп утырган тал агачы сарылы-яшелле чәчкә аткан. Әнә, күрше Минхәер бабайларның бакчасындагы оялар өстендә бал кортлары безелдәшеп оча.

Ә Мәрьям рәт–рәт булып, яңа гына тезелешеп чыгып килүче бәрәңге араларын чүп үләннәреннән арындыра. Бүген аның күңеле күтәренке, чөнки озакламый мәктәптә соңгы имтиханнарны тапшырып бетерәчәк ул. Биредәге эшен кызурак тәмамларга кирәк аңа, чөнки яраткан укытучысы Сәлиха апа алар сыйныфын өстәмә дәрескә чакырды бит. Менә шулай итеп, яшь кыз үзалдына уйланып кына бакчада кайнаша иде, шул вакыт якында гына кемдер:

– Исәнме, Мәрьям! Әллә бүген син мәктәпкә бармыйсыңмы? – дип сорады. Мәрьям күтәрелеп карады, үзе исә оялудан кып–кызыл булып, тиз–тиз генә бөрмәсенә кыстырган күлмәк итәген тартып төшерде. Билгеле инде, яңа гына мыек төрткән егет берни дә күрмәмешкә салынып, сөйләнүен дәвам итте. Кыз:

– Ибраһим! Ни эшләп йөрисең соң әле биредә?! – дип сорады .

– И, Ходаем! Әнкәй белән әткәй күрсә, ни дип җавап бирермен икән? – дип өзгәләнгән кызга батыраеп киткән егет:

– Курыкма, Мәрьям! Мине беркем дә күрмәде ич. Ишегегездә йозак булгач, монда килдем инде, – дип җавап кайтарды.

Ибраһим белән Мәрьям мәктәптә беренче сыйныфтан ук бергә укыдылар. Ибраһим кызны бик яратса да, рәнҗетермен дип, аңа аны-моны сиздерергә курка. Ләкин башка егетләр күз салмасын дигәндәй, үзе Мәрьямне бөтенләй күз уңыннан җибәрмәскә дә тырыша.

Яшьлек матурлыгына уралып, гомер атлары алга чаптылар. Мәктәпне тәмамлагач, Ибраһим авылда калды, көзен аны армиягә алдылар. Ә Мәрьям исә дусты Мөнирә белән Урта Азия якларына китеп бардылар. Биредә яшь кызлар мамык заводына эшкә урнаштылар. Мәрьямнең эштә тырыш, тормышка җитди карашлы икәнлеген күреп алган җитәкчеләр аңа юллама биреп, лаборантка һөнәренә укытып кайтардылар. Тормыш шулай үз җаена әкрен генә ага бирде. Тик заводта эшләүче Мөхтәр исемле егет кенә Мәрьямгә тынгылык бирмәде. Кыз аның белән сөйләшергә теләмәсә дә, әллә кайдан, көтмәгәндә каршысына килеп чыга иде.

Беркөнне шулай Мәрьям, эченнән генә әрсез егетне тирги–тирги, өенә кайтып бара иде, аның аягы нигәдер эләгеп, яшь кыз җиргә мәтәләде. Ул исенә килергә өлгермәде, аны кемдер көчле куллары белән күтәреп алып, җиргә бастырды. Кыз күтәрелеп караса, алдында өстенә комбинезон кигән, озын буйлы, шомырт кара чәчле егет басып торганлыгын күреп алды.

– Гүзәлкәй, сез гел шулай уйланып, аяк астына карамыйча йөрисезме?! – дип сорады ул, ап–ак тешләрен күрсәтеп, балкып елмаеп. Ә үзе кызга тын алырга да ирек бирмичә:

– Таныш булыйк! Мин Хәсәнша исемле булам. Ташчы. Менә шушы кулларым белән өйләр төзеп, кешеләрне бәхетле итәм.

Аннан соң ул кыздан кич белән бию мәйданчыгына килүен үтенеп, яңа гына салынып ятучы йортлар арасына китеп югалды.

Мәрьям тулай торакка кайткач, бүлмәсендә, үз караватында уйланып ятып тора иде, шулчак Мөнирә кайтып керде. Дустының уйчан, аптыраулы күз карашын күреп:

– Нәрсә, дустым! Әллә берәрсе үлгәнме, кара кайгыга баткансың, – дип сорады һәм кычкырып көлеп җибәрде. Мәрьям барысын да бәйнә–бәйнә сөйләп биргәч, Мөнирә:

– Нәрсә! Әллә шушы киребеткән горурлыгың хакында ирсез калма келисеңме? Карт кызга әйләнгәч, син кемгә кирәк?! - дип, тиргәргә керешә. Ләкин Мәрьям егетне беренче күрүдән үк ошатты ич. Чөнки чибәр егет күз карашы белән аны буйсындырып өлгергән иде инде. Ә мәхәббәт дип аталган очар кош бер йөрәккә кереп оялагач, аны аннан берничек тә куып чыгарып булмый шул.

Кич җитеп, караңгы төшә башлагач, кызлар матур итеп киенешеп, бию мәйданчыгына юнәлделәр. Биредә матур музыка уйный, егетләр, кызлар парлашып бииләр. Шул чагында әллә кайдан гына бер егет ияртеп, Мәрьям каршысына Хәсәнша килеп басмасынмы! Хәсәнша иптәшен Мәхмүт , дип таныштырды.

Менә шушы матур ике яшь парны бию мәйданчыгы үз эченә бөтереп алды.

Биеп арыгач, егетләр кызларны өйләренә озатып куйдылар.

Вакыт сиздерми генә алга барды. Мәрьям белән Хәсәнша бер–беренә үлеп гашыйк иделәр. Тик Мәрьямнең сыйныфташы Ибраһимнан гына хатлар килүдән туктамады.

– «Минем адресымны кайдан эзләп таптың соң, Ибраһим?» – дип аптыраганнан хат язып салгач:

– «Үзеңә кирәк булгач, йөрәгеңне мәңге сүнмәс мәхәббәт уты көйдергәч, табасың инде аны, Мәрьям! Синнән башка яши алмыйм бит мин!» - дип җавап язды яшь егет.

«Мине бүтән эзләмә, Ибраһим! Мин башка егетне яратам, озакламый тормышка чыгам. Йөрәгеңне яралавым өчен, зинһар, кичер, Ибраһим!» – дип хат язып салды кыз авылдашы, бергә уйнап, бер сыйныфта белем алган Ибраһимга.

Озак та үтмәде, Мәрьям Хәсәншага тормышка чыкты, Ибраһимнан хатлар килүе дә тукталды. Аның дусты Мөнирә дә Мәхмүткә кияүгә чыгып, «башлы-күзле» булды.

Тормыш дәвам итте. Мәрьям белән Хәсәншаның тормыш бизәге булып, бер–бер артлы өч кызлары туды. Тик менә көннәрдән бер көнне аларның өченче кызлары (мин булам инде) авырып китте. Нинди генә табибларга күрсәтеп карамадылар нәни сабыйларын яшь әти белән яшь әни! Кызганычка, беркайдан да ярдәм булмады.

Беркөнне Хәсәнша эшеннән иртәрәк кайтып килде һәм яраткан хатынына:

– Әйдә, җаным! Җыен! Балабызны үтереп булмый әле. Рәсәйгә кайтабыз!

Беравык ул хәләл җефетенә карап торгач:

– Кайтарып калдырыйм инде сезне туган илгә, – дип тә өстәде. Ә үзенең күзләре бик сагышлы, моңсу иде аның.

И, язмыш, язмыш! Адәм баласына бигрәк күп чишелмәгән сораулар бирәсең инде син! Нилектән шулай сезне кайтарып калдырыйм инде, дип әйтте икән ул чагында, дөньяда яшәп туймаган, баһадирдай ир солтаны?!! Хәер, бу сорауга җавапны киләчәк үзе әйтер.

Менә алар утырган поезд кузгалып китте. Озата килүчеләр артта кала башлады. Поезд көпчәкләре тизлекне арттырды. Мәрьям белән Хәсәншага гомерлек саф мәхәббәт бүләк иткән Джалал–Абад шәһәре артта калды.

Тик Рәсәй җиренә якынлашкан саен, дөньяга күзен дә ачып карарлык хәле булмаган, коры сөяккә калган авыру сабый күзен ачып, беравык әти–әнисенә карап торгач, елмаеп: «Әттә!» – дип эндәште. Аннан соң «Әннә, мә–мә» – диде. Бичара ана шатланып, тиз–тиз генә сабыена имиен чыгарып каптырды. Ә йомшак күңелле әти кешенең күзләрендә яшь бөртекләре ялтырады...

Яшь гаилә авылга кайткач, йорт сатып алды.

– «Монда яңа өй салам, менә монда абзар, әнә тегендә мунча булыр. Биредә кое казырмын. Их! Мәрьямем минем! Безнең тормыш бакчабызда гөлләр чәчәк атар әле», – дип хыялланды яшь ир хәләл җефетен иңбашларыннан кочып алып.

Ләкин ни кызганыч! Бу матур хыялларның ник берсе тормышка ашсын! Авылга кайтып, өч ай үтүгә, Хәсәнша авырып, түшәккә егылды. Табиблар аңа: йөрәкне алмаштырып булмый шул, дип аңлаттылар. Баштан аякта йөреп торса, соңыннан ул ятып кына тора башлады. Нибары өч көн ятты Хәсәнша. Кем генә уйлый соң шундый яшь, яшәүгә көче–дәрте ташып торган ир әҗәлгә авырый дип! Бер көнне ул хәлсез генә яраткан хатынын үз янына чакырып алды да:

«Бәгырем! Балаларыбызны сиңа калдырып китәм. Рәнҗемә миңа, бәхил бул. Миңа матур тормыш, бәхет бүләк итүең өчен зур рәхмәт сиңа! Кызларыбызны дөрес итеп тәрбияләргә тырыш инде!» – дип әйтте. Һәм шуннан соң озак та тормады, җан бирде. Сөйгәненең янында басып, кулын тотып торган Мәрьям түзеп кала алмады, һушы китеп егылды.

1962 елның зәмһәрир суык январь аеның күз ачкысыз бураннары Хәсәншаның гомерен суырып алып киткәч, аның гәүдәсен җирләргә бик күп кешеләр җыелды. Аны, яхшы кеше буларак, авыл халкы бик яратып өлгергән иде инде.

– «Хәсәнша, җаным! Мин синнән башка яши алмыйм!» – дип, өзелеп–өзелеп елап, ире җеназасы артыннан йөгерде нибары 26 яшен тутырган, сөйгән ире белән барлыгы алты гына ел торып калган яшь тол хатын Мәрьям. Моңа каршы:

«Синең ирең әманәт итеп тапшырып калдырган өч кыз балаң бар. Алар өчен яшәргә, бик көчле булырга кирәк сиңа, Мәрьям», – дип юаттылар аны туганнары.

Менә шулай итеп, кар–буранлы, әрнүле, хәсрәтле кыш үтеп, ямьле яз да килеп җитте. Тирә–юнь яз көне була торган шау–шуга күмелде. Сыерчыклар кайтты ерак илләрдән. Алар Хәсәнша ясап калдырган ояларга кунып, өздереп сайрап җибәрделәр. Озак та үтмәде, бала чыгарырга җыендылар. Ярларына сыеша алмыйча, елгаларда боз кузгалды. Озакламый шомырт, алмагачлар тирә-юньгә хуш исләр таратып, ап–ак чәчкә аттылар. Табигать–Анабыз язгы җырын сузды.

Бер көнне Мәрьям югары очта яшәүче әниләреннән ашыга–ашыга кайтып килә иде. Көтмәгәндә, аның каршысында, ул тормышка чыккач, армиядән соң чит җирләрдә төпләнеп, беркайчан да туган авылына кайтып аяк та басмаган, үзен шашып яраткан Ибраһим пәйда булмасынмы! Үз күзләренә үзе ышанмаган хатын телсез калгандай, аңа текәлеп карап калды.

– Исәнме, Мәрьям! Хәлләрең ничек?

– Исәнме, Ибраһим! – дип, авыр гына аның сәламен алды Мәрьям.

– Гафу ит инде. Синең хәсрәтең турында ишеткәч, кайтмыйча булдыра алмадым. Бик кызганыч! Тик ни эшлисең бит, язмыштан узмышлар булмагач.

Мәрьям, мин бит сине һаман да өзелеп яратам. Сине оныта алмагач, гаиләм дә юк. Чык миңа тормышка, әйдә, бергә булыйк! – дип инәлде Ибраһим.

Хатын бераз аңа текәлеп карап торгач:

– Булдыра алмыйм, Ибраһим! Кичер мине! Хәсәншамны оныта алмыйм. Минем балаларым бар. Алар турында уйларга кирәк миңа. Хуш! Бүтән минем юлларыма чыкма! – дип, китү ягына борылды.

Әйтерсең лә Табигать–Анабыз үз балаларының йөрәк кичерешләрен аңлап, тоеп тора! Кинәт күк күкрәп, яшен яшенләп, актарып яңгыр яварга тотынды.

Ибраһим коеп яуган яңгыр астында, җиде юл чатында басып калды.

– Яратам бит мин сине, Мәрьям! - дип, аннан гомерлеккә ерагаеп китеп баручы хатын артыннан өзелеп кычкырды ул. Мәрьям әллә ишетеп, әллә ишетмичә, аның бу сүзләренә каршы җавап кайтармады. Ул хәләл ире – Хәсәншасының дәвамчылары булган өч сабые турында уйлап алып, адымнарын тизләтте. Ә яңгыр чиләкләп койды да койды гына. Урамда чокыр–чакырларга су тулып, гөрләвекләр ага башлады.

Бик озак та үтмәде, ишеп яуган яңгыр туктап калды. Кисәк кенә җыелган болытлар таралып, ялтырап, матур булып, кояш чыкты. Күк йөзендә аллы–гөлле булып, салават күпере сузылды. Тирә-юнь кошлар моңына күмелде. Якты кояш нуры җир йөзен иркәләде, яшәү яменә буйсынып, бакчадагы гөлләр кояшка үрелде...









# XXI ЖУРНАЛИСТСКИЙ ФЕСТИВАЛЬ «ПРЕССА-2014» ПРОШЕЛ В САМАРЕ



**Традиционный, уже 21 по счету, фестиваль прессы прошел в Самаре в субботу 31 мая. Девиз фестиваля самарских СМИ этого года – «Сделаем мир прекрасней!».**





В мероприятии приняли участие национальные СМИ региона. На площадке Дома дружбы народов было представлено впечатляющее разнообразие печатных СМИ. В их числе «Бердэмлек» («Единство») – татарская газета, журнал «Самарские татары» – журнал Самарского областного татарского общества «Туган тел» («Родной язык»), «Самарен» («Самарский край») – чувашская газета, «ВалдоОйме» («Светлая душа») – газета Самарской региональной общественной организации «Мордовский национально-культурный центр «Масторава», «Наири» – журнал общественной организации «Самарская городская Армянская национально-культурная автономия «НАИРИ», «АК ЖОЛ» («Светлый путь») – газета самарской региональной казахской национально-культурной автономии «АК ЖОЛ», «Единство» – журнал Самарской областной общественной организации «Русско-Белорусское Братство 2000», «VOLGA- KURIER» («Волга-курьер») – газета самарских немцев, «Ыргыз» («Иргиз») – газета общественной организации «Курултай (Конгресс) башкир» города Самары, «Энетил» («Родной язык») – газета благотворительного фонда «Помощь киргизскому народу «Манас-Ата».



Пришедшие на фестиваль горожане смогли многое узнать об интернет-ресурсах, представляющих национально-культурное многообразие Самарского края. Это сайт «Самарские татары» по адресу: http://samtatnews.ru, сайт Самарской региональной творческой общественной организации «ДУСЛЫК» («ДРУЖБА»). Был достойно представлен сайт Дома дружбы народов Самарской области http://www.samddn.ru/, подробно и разносторонне информирующий о реализации национальной политики и межнациональных отношениях в Самарской области.

*Римма НУРЕТДИНОВА*
*Фото Аняса МИНГАЛИЕВА*



# ЗУР БАЛИШ

Говяжьи голяшки - 600 г
Картофель - 1,5 кг
Бульон говяжий - 1 стакан
Сметана - 1 стакан
Лук - 2 штуки
Масло топленое - 8 ст. л.
Мука пшеничная - 2 стакана
Лавровый лист - 2 штуки
Сода гашеная - 1/2 ч. л.
Соль, перец - по вкусу

Смешать большую часть муки с солью, затем с растопленным маслом, добавить сметану, перемешать, добавить соду, остальную муку, вымешивать до однородного состояния 5 минут, накрыть плёнкой и отставить на час.

Мясо и картофель нарезать кубиками размером с горошину (5-7 мм), почистить и мелко нарезать лук, всё смешать, посолить, поперчить.

Тесто разделить на 2 неравные части. Раскатать большую до 4-5 мм, выложить в смазанную сковороду, положить лавровый лист, сверху — начинку и несколько ломтиков топлёного масла. Раскатать второй кусок теста, накрыть начинку, защипать. Сделать в центре дырку, прикрыть её шариком из теста. Выпекать 20 минут при температуре 200°С, до румяной корочки.

Накрыть фольгой (или крышкой), выпекать ещё 40 минут при температуре 170°С. Через отверстие влить горячий бульон, заткнуть шариком, снова закрыть фольгой, выпекать 2,5 часа при температуре 150°С. Выключить духовку, дать постоять 30 минут. Подавать.



# СУП

## ИЗ БАРАНИНЫ С САЛМОЙ

Баранина на кости - 600 г
Морковь - 1 штука
Лук репчатый - 1 головка
Картофель - 3 штуки
Мука пшеничная - 200 г
Соль, перец, зелень - по вкусу
Яйцо - 8 штук
Бульон мясной - 200 г

Баранину промыть, залить водой и варить 3 часа. Посолить и варить еще 30 минут.

Приготовить салму. Для этого смешать муку с яйцами и, подливая остуженный бульон, замесить тесто. Готовое тесто разрезать на небольшие куски и раскатать в тонкие жгутики. Затем разорвать жгутики на маленькие кусочки.

Мясо вынуть, бульон процедить и снова поставить на огонь.

Очистить и нарезать овощи – картофель, морковь, лук. Добавить овощи в суп и варить 20 минут. Затем добавить салму и варить до готовности.

Посыпать суп рубленой зеленью.



# ТУНТЭРМА

## ОМЛЕТ ПО-ТАТАРСКИ

- Яйцо - 4 штуки
- Молоко - 250 мл
- Мука пшеничная - 100 г
- Масло сливочное - 100 г
- Соль - по вкусу

В глубокую посуду разбить яйца, взбивать до однородной массы. Добавить молоко и растопленное масло. Добавить соль, муку и взбивать до консистенции жидкой сметаны.

Массу перелить в сковороду, смазанную любым растительным маслом или жиром, и поставить на огонь. Как только масса загустеет, поставить в духовку на 5-10 мин. Надо, чтобы омлет поднялся.

Готовую тунтэрму вынуть из духовки и подать на стол.

# Книжные новинки





Хакимов Р.С.

**Татарский дух**

В книгу вошли сочинения, статьи и публицистические записи, посвященные вопросам политики, межнациональных отношений, истории ислама и федерализма, вышедшие в свет в течение последних 17 лет.



Валеев Р.К.

**Прерванная молитва**

После Октябрьской революции большевики начали проводить череду репрессий. Новое правительство сделало все, чтобы заставить татарский народ отказаться от своих идеалов, оставить его без государства и языка. В итоге исторические события и судьбы многих личностей остались неизученными. Это отразилось в описании движения ваисовцев, событий «Забулачной республики» и судеб известных татарских ученых и писателей. Личности канули в лету, события были переписаны. В книге рассматривается трагическая судьба татарского народа, основанная на изучении архивных материалов. Описываются правительство, партия, отношения отдельных личностей. Автор рассматривает не понятные до сегодняшнего дня или вовсе не изученные проблемы. Книга адресована широкому кругу читателей и всем, кто интересуется историей Татарстана.



Набиуллин Т.Н.

**Буртасы**

В книгу писателя, автора исторических произведений, вошли его повести «Буртасы» и «Амат, сын Гисы».



Альманах

**Полуденный закат**

В сборник вошли произведения известных татарских писателей. Книга дает довольно полное представление о жанровом многообразии современной татарской прозы. Все произведения, вошедшие в сборник, издаются на русском языке впервые.



Гаффар А.Г.

**Глазок иглы**

В представленных повестях и рассказах одного из лучших татарских писателей – Ахата Гаффара – рассказывается о жизни татарского народа после Второй мировой войны. Писатель сурово, но в то же время с сожалением изображает действительность, он борется за моральную ответственность, описывает душевные переживания своих героев в контексте эпохи.



Сагди Р.Н.

**Амазонки**

В книгу вошли два произведения Радифа Сагди. Роман «Мир с двумя солнцами» относится к жанру фантастики. В нем через изображение параллельных миров описывается современная жизнь России и Татарстана. Роман «Амазонки» написан по запискам «отца истории» – Геродота, жившего в 490–425 гг. до н.э.



Галиев Г.Г.

**Буранная зима**

В сборник вошли произведения Г. Галиева, написанные им за последние годы. В рассказах и повестях, отличающихся простым, близким народу языком, описываются интересные и поучительные события.



Сабиров Р.Р.

**Беглец**

Книга казанского писателя Рустема Сабирова состоит из двух повестей. Они совершенно разноплановы: криминальная драма «Лесопарк» и историческая фантазия «Беглец». Но некая внутренняя общность странным образом соединяет их под одно общее название — «Беглец».



Харисов Р.М.

**Безымянные**

В книге народного поэта Татарстана, лауреата Государственной премии Республики Татарстан Рената Хариса оригинально описываются трагические события эпохи, неповторимые истории любви наших современников, ветер «смутного времени», затронувший многие жизни…



Хабибуллин М.М.

**Сказание о Казани и дочери хана**

Книга включает в себя два романа М. Хабибуллина. В первом автор рассказывает о зарождении города Казани как будущей столицы булгар. Это времена удельных княжеств и эмиратов, междоусобных войн, становления тюркской культуры. Роман «Чертово городище» сюжетно продолжает начатую тему. В нем выводится образ гениального Кул Гали, описана история отношений ханской дочери и зодчего и, наконец, рассказано о начале нашествия монголо-татар. Все эти события далекого XIII века становятся зримыми благодаря ярким характерам, захватывающему сюжету.



Мустафин Я.М.
**Бешеная**
В сборник вошли лучшие рассказы известного писателя Ямиля Мустафина. Книга дает довольно полное представление о его творчестве. Издание подготовлено к 80-летию Я. Мустафина.



Сафин Р.Г.
**Миссия татар: эзотерический анализ судьбы татар**
Мы не зря пришли в этот мир – и у отдельной личности, и у целой нации есть своя миссия, определенная Аллахом. Если народ будет понимать и выполнять свою геоисторическую функцию, он проживет долгую и свободную жизнь. В чем же заключается миссия татар? Понимаем ли мы свою ответственность в определении безопасности человечества XX века? Каким образом наша нация должна выполнить свой долг? Автор призывает читателя задуматься об этом.



Гилязов А.
**В чьих руках топор?**
В романе «В чьих руках топор?» описываются отрицательные явления, развившиеся в эпоху застоя, судьбы людей разных сословий, вопросы чести и совести.



Хасанов А.Х.
**Анисовые яблоки**
Повести, вошедшие в книгу Анаса Хасанова, рассказывают о первой любви юношей и девушек. Будучи преданными этому чувству, герои достигают духовного совершенства. Книга будет интересна молодежи, собирающейся вступить во взрослую жизнь.



Лерон Л.Л.
**Язык без костей**
В книгу вошли пародии, эпиграммы и посвящения автора, написанные за последние годы.



Амирханов М.А.
**Моя молитва**
Любовь – суть бытия. Она никого не обойдет стороной: ни царей, ни цариц, ни пленных… В произведениях, вошедших в этот сборник, эта вечная истина отражена в судьбах известных людей, о которых не писали ранее.



Минлебаев К.
**Мудрый хвалит коня…**
В романе Кияма Минлебаева, всю жизнь служившего развитию национальной культуры, описываются события, которые могут быть воспоминаниями для взрослых и поучительными рассказами для молодежи.



Замалетдинова Ф.И.
**Молитва червя**
В книгу Фирузы Замалетдиновой вошли повести «Слышишь, филин?», «Молитва червя» и рассказы, написанные за последние годы. В них описываются переживания, мысли и чувства, моральные потери и находки наших современников в контексте общественных изменений.



Закиров Р.З.
**Татары в меняющемся мире**
Книга посвящена рассмотрению этнополитической истории татар в XX в. Автор подробно анализирует процессы, происходившие в татарском обществе в начале XX столетия, выявляет важнейшие факторы и тенденции, которые сыграли определяющую роль в формировании татарской нации. В монографии особое внимание уделяется анализу тенденций, характеризующих современное состояние татарского этноса, а также раскрытию роли Всемирного конгресса татар в консолидации нации и рассмотрению положения татар в регионах России, в странах СНГ и дальнего зарубежья.



Миннуллин Т.А.
**Альмандар из Альдермеша**
В книге представлено одно из самых лучших и известных произведений Туфана Миннуллина – грустная комедия «Альмандар из Альдермеша» на татарском, русском и английском языках.



Хабутдинов А.Ю.
**От общины к нации**
Книга посвящена процессу рождения и эволюции татарской нации в конце XVIII – начале XX вв., основным направлениям развития татарского общественного и политического движения, созданию общенациональных институтов, роли исламского фактора в истории татар, реформе системы образования, зарождению и эволюции идеологических доктрин. Книга адресована ученым, преподавателям, студентам вузов, всем, кто интересуется историей татарской нации в частности и российских мусульман в общем.



Ганиева Ф., Яруллина Р.
**Татарские драматурги**
В книге рассказывается о жизни и творчестве 108 писателей – драматургов, прозаиков-драматургов, поэтов-драматургов, артистов-драматургов.



Мустафин Р.А.
**Силуэты**
В новой книге известного литературного критика, писателя и публициста Рафаэля Мустафина приводятся литературные портреты наиболее видных татарских писателей: от Кул Гали до Равиля Файзуллина. Читатель найдет в книге также портреты некоторых русских писателей Татарстана, оригинальные заметки о творчестве Беллы Ахмадулиной и пребывании Марины Цветаевой в Елабуге.

Лицензия ЦБ РФ № 3026
ИПОЗЕМБАНК

Туган Тел

# КТО, ЕСЛИ НЕ МЫ САМИ?...

Самарское областное татарское общество «Туган тел», НКО «Ассоциация содействия татарским предпринимателям» и ООО «ИПОЗЕМбанк» готовы рассмотреть социальные проекты, направленные на улучшение социально-экономического положения татарского населения нашего региона, развитие национальной культуры и образования.

Задача нашей программы – создать условия для увеличения числа активных граждан из числа татар, способных самостоятельно решать как свои проблемы, так и отдельные проблемы татарского сообщества. Именно поэтому мы считаем необходимым стимулировать социальные инициативы «снизу». Любой человек и любая общественная организация могут обратиться к нам со своим проектом и получить нашу поддержку.

По условиям программы, его участники должны представить обоснование своих проектов, пояснить, как будут расходоваться выделенные средства и что это даст в конечном счете непосредственно татарскому населению Самарской области.

Наши организации готовы участвовать в софинансировании проектов, лоббировании бюджетного финансирования для реализации представленных проектов.

## ПОЖЕЛАНИЯ К ПРОЕКТАМ:

- Проект должен реализоваться на территории Самарской области и способствовать достижению позитивных культурных и социальных изменений в татарском обществе.
- Проект должен быть направлен на решение/смягчение существующих социальных проблем; на появление долгосрочных, устойчивых позитивных социальных изменений, улучшение качества жизни татарского населения, региона в целом и/или представителей социально незащищенных слоев/групп населения и людей, нуждающихся в особой поддержке для развития своих способностей и самореализации.
- Проект должен иметь потенциал к масштабированию в других регионах РФ.
- Бюджет проекта должен быть частично обеспечен собственными средствами заявителя.

**По всем вопросам обращаться по тел. 331-47-77, 956-34-33 или электронной почте: Samartatarlary@bk.ru**

# ДНИ РОЖДЕНИЯ ДРУЗЕЙ И КОЛЛЕГ

## Июнь

**2 июня** – Салахов Дамир Абдрахманович
**5 июня** – Идеал Мусинович Галяутдинов
**6 июня** – Сафарова Румия Анвяровна
**10 июня** – Тренгулов Илдар Сирачевич
**14 июня** – Ямалетдинов Мансур Садретдинович
**17 июня** – Галимов Равиль Мухаметгалеевич
**18 июня** – Гафарова Наиля Хамзиевна
**21 июня** – Илингин Усман Анврович
**24 июня** – Хабибуллова Наиля Абдулхаковна
**25 июня** – Галиев Ильдар Зинятуллович
**26 июня** – Сабиров Равиль Искандерович
**27 июня** – Насыбуллин Наиль Камилович
**28 июня** – Салахов Ришат Акрямович

## Июль

**1 июля** – Горланов Анвар Имранович
**4 июля** – Валиуллин Ямиль Ахмадуллович
**8 июля** – Вагапова Дания Завдатовна
**9 июля** – Насыров Рашид Абдуллович
**9 июля** – Сафина Марбия Ахметовна
**10 июля** – Фаткуллин Раиль Хайдарович
**11 июля** – Гизатуллин Рамиль Шамилович
**13 июля** – Киямов Наиль Зайнетдинович
**16 июля** – Гильманов Ильсур Гаязович
**16 июля** – Семыкин Шамиль Юрьевич
**18 июля** – Бирюков Раиль Шамилович
**19 июля** – Аюпов Талиб Салихович
**23 июля** – Валиуллов Ринат Талипович
**23 июля** – Рахимов Ибрагим Якубович
**23 июля** – Салахов Рашит Ахметович
**24 июля** – Замальдинов Гамаль Рафаилевич
**27 июля** – Хасанов Максум Мирзаевич
**31 июля** – Мухаметшин Виль Сабирович

## Август

**1 августа** – Замальдинов Дамир Наилевич
**2 августа** – Назмиев Риф Хабибуллович
**3 августа** – Гайсин Джавдат Исхакович
**3 августа** – Хисамутдинов Шамиль Салимгереевич
**4 августа** – Мингачев Юсуп Фоатович
**6 августа** – Насыбуллина Наиля Мавлютовна
**8 августа** – Алаев Сергей Маратович
**12 августа** – Махмутова Альбина Харисовна
**21 августа** – Шарипова Динара Ильдаровна
**22 августа** – Сайфуллин Фоат Талгатович
**22 августа** – Хакимова Фания Файзулловна
**24 августа** – Мухаметшин Вазых Гатович
**25 августа** – Низамов Маулет Вазыхович
**25 августа** – Рахматулин Анвар Бахитжанович
**25 августа** – Ягудин Ринат Идрисович

# 75 «Ялкынлы яшьлек» җыр, бию һәм шигърият халык ансамбленең алыштыргысыз җитәкчесе, өлкә “Туган тел” татар җәмгыяте вице-президенты Илгиз Колючевка - 75 яшь!



Хөрмәтле Илгиз әфәнде!

Сезне чын күңелдән юбилеегыз белән тәбриклибез.

Сез “Ялкынлы яшьлек” җыр, бию һәм поэзия ансамбленең җитәкчесе буларак, милли мәдәният өлкәсендә бәяләп бетергесез эшләр башкардыгыз һәм башкарып киләсез, үзегезнең эчкерсезлегегез, ихласлылыгыз, ягымлылыгыз белән Самарда яшәүче татарларның күңелен яуладыгыз. 44 иҗат елы эчендә Сез җитәкчелек иткән ансамбль башкаруындагы җыр-биюләрдән ләззәт табып, берничә буын үсте, коллективны татар илендә белмәгән кеше юктыр.

Без Сезне кайнар йөрәкле милләтпәрвәр буларак беләбез. Сез - танылган җәмәгать эшлеклесе, татар милләте, мәдәнияте өчен янып яшәүче шәхес, рухи мәркәзебез Казанда олуг хөрмәткә ия булган, өлкә түрәләре тарафыннан җитди бүләкләргә лаек булган ир. “Дуслык” ордены кавалеры, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре исемнәрен йөртәсез, мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә губерна, татар халык мәдәниятен тергезүдә зур көч куйганыгыз өчен Бөтендөнья татар конгрессы бүләкләре лауреаты да булдыгыз. Үзегезне аямыйча, әйләнә-тирәдәгеләр өчен тырышасыз, милләттебез, халкыбыз, дип янып яшисез. Шуңа да Сезгә зур рәхмәтләребезне җиткерәбез.

Киләчәктә дә Сезгә хәерле исәнлек, иҗади уңышлар, гаилә бәхете телибез. Яшәү дәфтәрегезгә озын, тыныч гомер язылсын иде.

**Самар өлкә “Туган тел” татар җәмгыяте.**


## ГБУЗ «Самарский областной кожно-венерологический диспансер»

ГБУЗ «СОКВД» является медицинским учреждением Министерства здравоохранения Самарской области.Оказывает амбулаторно-поликлиническую и стационарную помощь взрослому и детскому населению по профилю «Дерматовенерология». Кожно- венерологический диспансер – современное высокоспециализированное, лечебно–профилактическое учреждение, в котором используется современные отечественные и зарубежные медицинские технологии, стандарты и протоколы диагностики, лечения, профилактики и реабилитации и оказывается комплекс медицинских услуг в рамках территориальной программы государственных гарантий оказания жителям Самарской области бесплатной медицинской помощи, а также по ДМС и на платной основе.

ДИСПАНСЕРНОЕ ОТДЕЛЕНИЕ включает в себя следующие центры (кабинеты):

- Центр по лечению псориаза и хронических аллергодерматозов (псориаз, атопический дерматит, экзема).
- Центр по диагностике и лечению хламидиоза и неспецифических уретритов и простатитов (хламидиоз, гонорея, трихомониаз, микст-инфекции с уреаплазмами и микоплазмами, кандидоз, ВПЧ и др.).
- Центр по лечению кожи стоп и ногтей (грибковые поражения стоп, онихомикозы, кандидозы).
- Герпес-центр (герпесвирусная инфекция).
- Лечебно-диагностический центр «Здоровые волосы» ( все виды облысения, выпадения волос, компьютерная диагностика «Hair lain»).
- Центр лечебной косметологии (лечение угревой болезни и ее последствий, рубцов, удаление новообразований кожи, коррекция возрастных изменений кожи).
- Лабораторная диагностика, в том числе ПЦР-диагностика.
- Подростковый центр «Доверие».
- Центр по изучению сексуальных проблем.
- УЗИ-диагностика, физиотерапия, озонотерапия.
- Стационар дневного пребывания.
- **Круглосуточный пункт индивидуальной профилактики ИППП.**

**Прием ведут** высококвалифицированные специалисты – доктора и кандидаты медицинских наук, врачи высшей и первой категорий, имеющие сертификаты по дерматовенерологии, клинической микологии, урологии, акушерству и гинекологии, сексологии, УЗИ, физиотерапии, инфекционным болезням и др.

Пациенты имеют возможность **анонимного** и кодированного обследования и лечения при соблюдении принципов конфиденциальности и приватности (анонимности).

Возможна запись на прием врача дерматовенеролога on-line на сайте ГБУЗ «СОКВД» **www.samara-okvd.ru,** а также через СОЦИАЛЬНЫЙ ПОРТАЛ ГОСУДАРСТВЕННЫХ УСЛУГ - СУПРЕМА 63 (**www.suprema63.ru**).

Венцека
**www.samara-okvd.ru**

Наш адрес: ул. Венцека, 35 (пл.Революции),
Тел.: **333-57-06, 332-23-67, 333-26-79**

Часы приема: с 8.00 до 20.00. Субб., воскр.: с 9.00 до 15.00

Дерматовенерологическое отделение № 1 - пр.Кирова, 242, тел. 959-79-53
Дерматовенерологическое отделение № 2 - ул. Революционная, 138, тел. 260-57-33
Дерматовенерологическое отделение № 3 - ул. Н.Панова, 8, тел. 334-79-42

Лиц. №ФС 63-01-001233 от 11.04. 2011г. выд. фс. По надзору в сфере здравоохр. и соц. развития.

НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТА



Самарские татары
Самар татарлары
информационный медиа-портал
www.samtatnews.ru
E-mail: samtatnews@bk.ru Тел. (846) 2120645


## Состав редсовета и редколлеги сайта «Самар татарлары» («Самарские татары»)


**Редакционный совет медиа-портала «Самар татарлары» («Самарские татары»)** возглавляет учредитель президент СОТО «Туган тел» Ильяс Шакуров, редакционную коллегию медиа-портала главный редактор сайта Римма Нуретдинова.

**В редакционный совет входят:** Рафгат Набиуллович Аглиуллин, Гумар Мулланурович Батршин, Ильгиз Исмаилович Колючев, Фархад Сабирзянович Махмутов, Азат Камилович Надиров, Ильгизар Ягфарович Сагдеев, Иршат Халилович Сафин, Наиля Фаридовна Тагирова, Рифгат Туктарович Хузин, Рамиля Халитовна Хабирова.

**В редакционную коллегию входят:** Наиль Данисович Биктаев, Эльмира Мугаммаровна Варфоламеева-Шавалеева, Шамиль Хайдарович Галимов, Искандер Фуадович Мифтахов, Данияр Ирекович Сайфиев, Рустам Ильясович Файзуллов, Фарид Хамитович Ширияздданов, Руслан Кабирович Шарипов, Жанна Валерьевна Султанова.

### Уважаемые родители!

Татарские национальные общественные организации Самарской области предпринимают попытки к созданию в городе Самара второй общеобразовательной школы с национальной компонентой. Для изучения спроса со стороны родителей, желающих обучать своих детей на родном татарском языке, ведения более продуктивных переговоров по данному вопросу с представителями городских и областных властей, просим вас заполнить заявление в соответствии с приведенной формой и выслать его на адрес Самарского областного татарского общества «Туган тел» («Родной язык») по адресу:

**443009, г. Самара, ул. Воронежская, 9. Дом дружбы народов, офис 203 в СОТО «Туган тел».**

**Заявления также принимаются:**

1. В отделе клиентского сервиса и развития ООО «ИПОЗЕМбанк» (пр. Кирова, 206);
2. В редакции газеты «Ислам-Нур» (здание медресе).
3. В офисе СОТНКА (ул. Санфировой, д.91 А офис 8).
4. В дирекции школы «Яктылык» (ул. Александра Матросова, д. 11А).
5. В ДК «Чайка» ( для И.И.Колючева).

Просим отозваться людей, имеющих педагогическое образование и в совершенстве владеющих татарским языком.

Главе администрации
г.о. Самара
Азарову Д.И. от
_______________,
проживающего по адресу:
______________________

**ЗАЯВЛЕНИЕ**

Прошу предоставить моему ребенку ________ ____________Ф.И.О. ____ возраст ___________ возможность обучения на родном (татарском) языке, согласно Статье 68 Конституции Российской Федерации.

Дата ________ Подпись_________

ОБРАЗЕЦ

## ТАТАРСКИЕ ИНТЕРНЕТ-РЕСУРЫ В САМАРЕ:

САЙТ НКО «АССОЦИАЦИЯ СОДЕЙСТВИЯ ТАТАРСКИМ ПРЕДПРИНИМАТЕЛЯМ САМАРСКОЙ ОБЛАСТИ»
www.samtatdelo.ru

САЙТ ИСТОРИЧЕСКОЙ МЕЧЕТИ
www.tarihi-mechet.ru

САЙТ ВСЕМИРНОЙ АССОЦИАЦИИ СОДЕЙСТВИЯ ТАТАРСКИМ ПРЕДПРИНИМАТЕЛЯМ
http://tat-business.ru/

tatarile
«ТАТАР ИЛЕ» МӘГЪЛҮМАТИ-РЕСУРСЛЫ ТАТАР СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЕ
www.tatarile.org

САЙТ ВСЕМИРНОГО КОНГРЕССА ТАТАР
http://tatar-congress.org

TATAR ZAMANI
ИНТЕРНЕТ-ГАЗЕТА
www.tatartime.com

САЙТ РЕГИОНАЛЬНОГО ДУХОВНОГО УПРАВЛЕНИЯ МУСУЛЬМАН САМАРСКОЙ ОБЛАСТИ ПРИ ЦЕНТРАЛЬНОМ УПРАВЛЕНИИ МУСУЛЬМАН РОССИИ
www.islamsamara.ru

ЗВЕЗДА Поволжья
www.zvezdapovolzhya.ru

Самарские татары СамарТатарлары
МЕДИАПОРТАЛ на русском и татарском языках
www.samtatnews.ru

ОФИЦИАЛЬНЫЙ САЙТ ТАТАР САМАРСКОЙ ОБЛАСТИ.
САМАРСКАЯ ОБЛАСТНАЯ НАЦИОНАЛЬНО-КУЛЬТУРНАЯ АВТОНОМИЯ
www.tatarlarsamara.org

www.tatarlarsyzran.ru



# Как пройдут Самарские областные Сабантуи



Парк им. Ю.А. Гагарина остается наиболее оптимальной в условиях города площадкой для проведения 21 июня областного Сабантуя в Самаре.

Возможно, и в этом году, как и в предыдущий юбилейный 25-й Сабантуй, в состав оргкомитета по подготовке и проведению мероприятия войдут представители органов исполнительной власти.

Праздник должен пройти масштабно, он разделен на множество зон. На стадионе будет установлена главная сцена. На ней будут работать татарстанские артисты, выступят популярная группа «Казан егетләре», коллективы художественной самодеятельности Заинского района. Здесь же будет проходить и национальная борьба – куреш. Будут работать детская площадка с аниматорами, зона со свободным творческим микрофоном, «пятачок» - специальная площадка песен и плясок под тальянку и гармонь.

Также будут организованы традиционные спортивные соревнования и состязания, аттракционы. Все это вместе сделает массовое гулянье зрелищным.

Завершится праздник молодежной дискотекой: на одной из площадок Сабантуя до глубокой ночи будет звучать татарская танцевальная музыка.

На Сабантуе планируется поощрить активных членов СОТО «Туган тел» в рамках празднования 25-летия организации.

В подготовке праздника примут активное участие все общественные организации.

### Самар өлкәсе Сабантуйлары графигы ( 2014 ел)

*1 июнь - Тольятти шәһәре;*
*31 май - Байтуган авылы;*
*31 май - Балыклы авылы;*
*31 май - Иске Усман авылы;*
*7 июнь - Гали авылы;*
*7 июнь - Яңа Усман авылы;*
*7 июнь - Яңа Мансур авылы;*
*7 июнь - Мәчәләй авылы;*
*7 июнь - Иске Ярмәк авылы;*
*12 июнь - Камышлы авылы;*
*14 июнь - Новокуйбышевск шәһәре;*
*15 июнь - Сызрань шәһәре;*
*21 июнь - Самар шәһәре.*





Лицензия ЦБ РФ № 3026

ИПОЗЕМБАНК

Каждый клиент – партнер!

**Центральный офис:**

443087, г. Самара, пр. Кирова, 206.
Тел.: **(846) 331-47-77, 956-34-33**

**Филиал «МИЧУРИНСКИЙ»**

443110, г. Самара, ул. Мичурина, 64,
тел.: **(846) 270-26-94, 270-26-95**